1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН
№ 6 / 2022

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

АМАЗОНКАЛАР
яман шеш – хөкем түгел

ТИРАМИСУ
итальян десерты

гомер күзләремдә – ЯЗЛАР
хәтер-хатирә

Динара САДЫЙКОВА:
«Авыру баланы яратырга, хөрмәт итәргә кирәк!»

PRESSA

Әниемнең туй күлмәге...



Әниемнең туй күлмәге...
Сезнең гаиләнең матур
бер ядкаре.
Кадерле кешегезнең
яшьлегеннән бер кайтаваз.
Аның иң бәхетле бер көненең
шаһиты.
Сакланамы ул сездә?
Аны кулга алгач, йөзе балкып
киткән әниегез нәрсәләр искә
төшерә, нинди истәлекләр
сөйли?
Бездә яңа проект: әниегезнең
туй күлмәген киеп көзге
алдында бөтерелгән
мизгелне сурәтләгән
фотосурәтләрегезне көтәбез.
(«Минем кыз чагым син,
кызым!» – дип әйтәдер
әниегез сезгә карап.
Яратып, сөенеп, аз гына
моңсуланып...)
Тагын – аларның туй көненнән
бер мизгел дә көтәбез!

■ «Безнең чорда 25 яшьтән соң гаилә кору соң дип кабул ителә иде, – ди әни, туй күлмәге турындагы истәлекләрен барлап. – Яшемнән кыенсынып, туй үткәрәсем килмәвемне хәтерлим әле. Бераздан кире уйладым, әлбәттә. Шулай да туй күлмәген сайлаганда аның гадилегенә, күзгә артык ташланып тормавына өстенлек бирдем. Безнең заманда да сайлау мөмкинлеге зур, кибетләрдә матур, төрледән-төрле күлмәкләр күп иде. Минем күзем исә менә шушы тыйнак кына булганына төште». «Соңлап кияүгә бардым, сезне дә олыгаеп кына алып кайттым. Миңа охшамагыз, оягызны иртәрәк корыгыз», – дия иде ул безгә һәрвакыт. Әнигә кияүгә чыкканда 28 яшь кенә булган югыйсә.

Зөһрә САДЫЙКОВА.
Казан.

Фото: Анна Арахамия.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2022




Фото: Анна Арахамия

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зәлия Ахунова, Ирада Әюпова, Зилә Вәлиева, Гөлүсә Батталова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Альбина Насыйрова, Алсу Нәбиева, Сәрия Сабурская, Гүзәл Сәгыйтова, Нурия Һашимова, Рафаэль Шәвәлиев.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Алсу Шакирова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррире
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Динара Садыйкова
Фото: Анна Арахамия

Мөхәррирләр
Чулпан Галиәхмәтова
Сөмбел Гаффарова
Лилия Гәрәева
Фәгыйлә Шакирова
Верстка
Резеда Галиуллина
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәрләр
Ильмира Сөләйманова
Павел Фадеев

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 24.05.2022 ел.
Чыгу көне: 31.05.2022 ел.
Заказ О-1496
Тираж 9096

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы
ПАП рәсми каталогы буенча:
Татарстанда П2204 (ярты еллык),
П8299 (берьеллык)
Татарстаннан читтә: П0279

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+



Фото: Анна Арахамия

Баш мөхәррир сүзе



Кадерле укучым!

Дөньяга яңа кеше килү – бала туу зур бер могҗиза!.. Бу хакта гел сөйләп, язып торабыз. Әмма барыбер кабат-кабат шаккатабыз. Әйтик: «Инде юк, син башка әни була алмыйсың», – дигәннән соң да хатын-кызның бала табуы могҗиза түгелмени?! Унлата, йөзләтә могҗиза лабаса! «Амазонкалар» дигән язманың героиняларының берсе – Люция ханым әнә, «табигатьне алдап», балага узган, тагын бер кат әни булу бәхетен татыган.

Ел саен шулай гадәтләнгән инде – Халыкара балаларны яклау көне уңаеннан июнь санныбызда күпчелек язмалар балаларга багышлана. Ә бу юлы алар – аерым игътибарга мохтаҗ балалар турында. Әнә Саба апалары җитлекмичә туган сабыйларга – үзләре бөтенләй күрмәгән, белмәгән балаларга – изге теләкләр тели-тели, оекбаш, башлыклар бәйлиләр.

Яхшылык эшләүнең юллары меңдә бер аның... Дәлия Гайнанова балалар церебраль параличы белән авыручы улы Тимурга җайлы киемнәрне үзе тегә башлый. Ә бүген инде аның тегү производствосы башка илләрдә яшәүче үзенчәлекле балалар тәрбияләгән гаиләләргә дә таныш. Тагын бер героинябыз – Татарстан Республикасының атказанган табибы Динара Илгизәр кызы Садыйкова республикада яңалык кертергә – бала тууга аның электрон медицина көндәлеген булдырырга хыяллана. «Бала сәламәтлеген кайгыртуның иң җайлы юлы булыр иде», – ди.

Әйе, бар да әйбәт кебек. Балаларыбызны берәүдән дә яклыйсы юк шикелле.

Әмма санныбыз әзерләнеп беткәндә генә, җанны өшетеп, тагын бер күңелсез хәбәр килеп ирешә. Казан янында урнашкан бистәләрнең берсендә әнисе белән яшәүче ир ДЦП белән авырган 6 яшьлек кызның гомерен өзгән... Күңелдә туган сорауларның очы-кырые юк. Беренче чиратта, аларны, әлбәттә, ул кызчыкның әнисенә бирәсе килә. Иренең балага булган мөнәсәбәтен күрми, сизми калмагандыр бит инде. Әни ләбаса ул! Ә туганнар, дуслар, күршеләр?!. Мондый тетрәндергеч хәлләрдән соң яңадан: «Балаларыбызны саклыйк! Игътибарлырак булыйк!» – дип әйтәсе килә. Үзебезнекеләргә карата гына түгел!..

Яратып,
Лариса МАЛИКОВА



Безнең тышлыкта

«Бик сирәк очрый торган авыруларны дәвалау буенча да тәҗрибәбез бар. Безгә бөтен Россиядән шалтыраталар, көн саен консультацияләр бирәбез. Сыктывкар, Әстерхан, Ростов, Мәскәү, Санкт-Петербурглардан киләләр.»

10
Табиб булу – зур җаваплылык!
Эльмира Закирова







14
«Бала белән горурлана белергә кирәк»
Чулпан Галиәхмәтова

16
Улыма рәхмәт
Алсу Шакирова

24
«Бер сәгатемне дә бушка уздырмыйм»
Лилия Гәрәева

Заман һәм без

Амазонкалар — 6
Чулпан Галиәхмәтова

28 күзәнәк — 20
Гөлнур Сафиуллина

Дин эшлеклеләрен берләштергән җыен — 23

Татар дөньясы

Безнең әни – дөньяда бер! — 28
Фәнзилә Хәйриева

Сабан туе – уртак туй! — 32
Лилия Гәрәева

Мәдәни тормыш

Газизләрдән газиз кемнәр газиз? — 36
Эльмира Шәрифуллина

Бәби исе — 38
Миләүшә Каһарманова

Яшәеш

«Финанс өе»нең нигезе — 47
Фәнзилә Мостафина

Вакытсыз киттең, балачак... — 51
Рухия Ахунҗанова

Гүзәлем Измир — 52
Фәнзилә Мостафина

Хуҗабикә


Яшь әни: сорау—җавап — 56

Чәчләрне кояштан саклыйбыз — 58

Телегез дөрес ятамы? — 59


Өйнең яме — гөлләрдә — 62

Надиянең сабырлык касәсе — 64
Зилә Нигъмәтуллина

44

«Гомер көземә язлар китердең...»
Венера Ибраһимова

48

Йөрәк тибеше көенә бию
Гөлнур Сафиуллина

60

Тирамису
Венера Арсланова тәкъдим итә















АМАЗОНКАЛАР



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Яман шеш авыруы белән очрашкан хатын-кызлар, гадәттә, үз диагнозы турында кычкырып сөйләми. Россиядә миллион ярым гүзәл зат әлеге диагноз белән яши. Аларның 80 процентына психологик ярдәм кирәк. Бу авыруга тарыган хатын-кызларга теләктәшлек максатыннан, Россиядә «Химия булды, әмма без аерылыштык» дигән фотопроект гамәлгә ашырыла башлады. Яман шеш авыруын җиңгән фотограф Ольга Павлова үзе кебек үк волонтер фотографлар белән бергә, әлеге авыруны җиңеп, киредән яшәргә көч тапкан хатын-кызларга фотосессия үткәрә. Геройлар үз тарихларын бәян итә. (Аларны «Моя фототерапия» дип аталган сайтта укып була.) Алия Әсхәдуллина тырышлыгы белән Казан да әлеге проектка кушылды. «Бу хакта социаль челтәрләрдән белдем. Фотосессия онкопациентлар өчен бәйрәмгә әйләнгән иде. Мин аларны аңлыйм, дәваланган вакытта башка тормышта яшисең. Бу чорда уңай эмоцияләр бик кирәк. Ә хатын-кыз, нинди генә хәлдә булса да, матурлыгын югалтмый. Аның бөтен матурлыгы – күзләрендә. Аклы-каралы фотолар нәкъ менә күзләргә акцент ясый. Фототерапияне авыру белән көрәшкән барлык хатын-кызлар да алсын иде. Башкача хис итәргә, үзеңне кабат хатын-кыз итеп тоярга нык ярдәм итә ул. Миңа булышкан фотографларга, визажистларга изге эштә катнашканнары өчен зур рәхмәт», – ди Алия.

Инде кайбер геройларның тарихы белән танышыйк. Аларны укып чыкканнан соң тормышыгыз яңа төсмер алмый калмастыр, мөгаен...

Ул вакытта миңа 28 яшь иде. Башка гап-гади хатын-кызлар кебек яшәдем. Кияүдә идем, җитез тиен кебек тәгәрмәчтә әйләндем, зур фирмада җитәкче ярдәмчесе булып эшләдем. Мин – әнинең бердәнбер баласы. Шулай булса да, аннан еракта – Мәскәүдә яшәдем, мөнәсәбәтләребез дә әллә ни җылы түгел иде. Аллаһы Тәгалә миңа бу авыруны, чапкан җирдән туктап калып, бераз тирә-ягыма күз салыр өчен биргәндер, мөгаен. Башкортстанга әни янына кунакка кайткач, мунчада юынганда күкрәгемдә шеш барлыгын сиздем. Әмма артык игътибарга алмадым, хастаханәгә дә бармадым, бәлки, курыкканмындыр. Мәскәүдән Казанга күчендем. Шәһәр мине кабул итте. Тиз арада эш тә, торыр җир дә таптым. Ул вакытта ирем белән аерылган идем инде. Шеш бетмәгәч, клиникага белгечкә күренергә бардым. Онколог-маммолог Ирина Овчинникова мине онкодиспансерга чакырды. Шундук пункция алдылар. Диагнозымны белгәч, бушлыкка чумгандай булдым. Бушлык һәм башка берни юк! Эшкә кайткач кызлар белән елашып алдык та шуның белән бетте. Әмма өйгә кайтып ишекне ябуга, миндә истерика башланды. Кычкырдым да кычкырдым... Ул кичне скайп аша танышым шалтыратты, һәм без дүрт сәгать буе сөйләштек. Икенче көнне эшкә барганда тынычланган идем инде. Кызлар, бар да яхшымы, дип сорады хәтта. «Әйе, миңа терелергә көч кирәк. Шуңа күрә энергиямне юк-барга түгәсем килми», – дидем. Авыруым турында шул ук көнне әнигә шалтыратып әйттем. Операциягә керер алдыннан килде ул. Мине күрүгә үк автобус баскычында баскан килеш елый башлады. «Әгәр синең бер яшь бөртегеңне булса да күрәм икән, шушы ук автобуска утырасың да, кире кайтып китәсең», – дидем. Әни башка еламады. Операция ясаганда күкрәк бизләремне алдылар да шунда ук имплант куйдылар. Наркоздан айнуга күкрәгемне капшадым. Күкрәкле килеш йоклап киткән идем, күкрәкле килеш уяндым – беренче уем шул булды.

Үземне беркайчан да жәлләмәдем. Үз хәлемне кабул иттем, үземне яратырга өйрәндем. Шуннан соң миңа ир-атлар игътибары артты. Алар өчен күкрәкле булу-булмавым мөһим түгел иде. Бу миңа тагын да көч һәм ышаныч бирде. Бернинди комплекслар калмады. Хәтта үзем яраткан кеше белән бергә яши башладык. Әмма авыру миннән китмәгән икән... Дүрт елдан соң рецидив булды: метастазлар китте. Кабат операция, химиотерапия, нурланыш терапиясе... Психологик яктан бик авыр булды ул. Чөнки беренче операциядән соң табибым белән килешкән идек: бу чорны куркыныч төш кебек онытам һәм биш елдан соң бала табу йортына барам. Әмма кабат онкодиспансерга килдем. Ә ике ел элек үпкәмдә метастазлар барлыгы ачыкланды. Хәзер мин таргетлы химия кабул итәм. Күкрәгемнән имплантны да алдылар, икенче күкрәгемне дә кечерәйттеләр. Ай саен компьютер томографиясе узам. Әлегә уңай динамика күзәтелә. Әни белән бик якынайдык. Иң авыр вакытымда янымда бер ул гына калды. Башкалар минем өчен чүп-чарга әйләнде. Әни Татарстанга күченеп килде. Без авыл җирендә яшибез. Өй түбәсеннән су үткәнгә дә борчылмыйбыз, һәр ел саен кредит алып, Россия буйлап сәяхәт итеп кайтабыз. Гомер бер генә һәм аның кыска икәнен икебез дә аңлыйбыз. Мин инде бала таба алмыйм. Балага бирәсе мәхәббәтемне әйләнә-тирәдәгеләргә бүләк итәм. «Без бергә» оешмасында волонтер булып торам. Анда минем кебек яман шеш авыруына тарыган кызлар белән ниләр генә эшләмибез. Кул эшләренә өйрәндем. Өстемдәге күлмәгемне үзем тектем, сумканы да үзем чиктем. (Күз явын алырлык сумка иде ул! – *Ч. Г.*) Мин – оптимист кеше, кабер тактасыннан кала, бар җирдән дә чыгу юлын табып була дип саныйм. Тормышымны авыруга кадәр һәм аннан соңга бүлеп карамыйм. Гомеремнең яңа бер чоры дип кенә кабул итәм. Әйе, әллә ничә елга планнар төземим. Хәер, ул планнарны беркем дә төзи алмаганын бүгенге вазгыять күрсәтте инде.



Айгөл ХАҖИЕВА, 37 яшь.
Күкрәгендә яман шеш авыруы.

Чынлыкта мин авыру белән көрәшмим, ә аны кабул иттем. Аллаһы Тәгалә яшәр өчен яңа мөмкинлек бирде. Мин шуны аңладым һәм тормышка башкача карап гомер итәм.



Люция ИОНОВА, 39 яшь.
Күкрәгендә яман шеш авыруы.

«Яман шеш диагнозы куелганнан соң бала таптым. Авырга узуымны белгәч, табиблар шаккатты. Бу бала миңа Аллаһы Тәгаләнең бүләге. Мин аны инде 1 нче сыйныфка алып бардым...»

Яман шеш авыруының дүртенче стадиясе миндә, беренче группа инвалидмын. Диагнозны куйгач, озак яши алмассың, диделәр. Шуңа бизнесымны саттым. Аннан соң ике ел узды инде. Риэлтор булырга укыдым. Шәһәрнең иң зур милек агентлыгында эшлим. Иң яхшы риэлтор исемлегендәмен. Әле менә химиотерапия алып кына чыктым, бер-ике көннән кабат онкодиспансерга кереп ятам. Аңа кадәр сату-алу килешүләре уздырасым бар... Тормыш дәвам итә икән ул...

Ә бит нәкъ 12 ел элек тормышым тәгәрәп барган җирдән туктап калып, дөньям чәлпәрәмә килгән иде. Күкрәгемдә шеш барлыгын чамалап, табибка киттем. Ул миңа мастопатия дип әйтте. Бераз йөргәч, УЗИ тикшерүе үттем. Анда инде мине онкодиспансерга җибәрделәр. Бер-бер артлы әти-әниемне җирләгән идем, стресс кичергәннән килеп чыккандыр дип уйлыйм. 12 ел элек мондый зур онкология хастаханәләре юк иде әле ул. Кремль астында ике катлы онкодиспансерга онколог-маммолог Альберт Гыймрановка йөрдем. Хастаханәдә безнең катта яман шеш белән авыручылар арасында иң яше мин идем – нибары 27 яшь. Кызыма 5 яшь. Диагнозымны белгәч, бик курыктым. Якыннарым белән хушлашырга да өлгермәм кебек иде. Ә бит минем авыруым бары икенче стадиядә генә иде. Ул вакытта бик күп дуслар миннән борылды. Берәр нәрсә сорармын дип уйлаганнардыр инде. Әмма соранып йөрмәдем. Әйе, хәлем җиңеләйгәч, киредән барлыкка килделәр, ләкин аларны үземә якын җибәрмәдем инде. Ирем янәшәмдә булды. Операциядән соң да янымда утырды. Күкрәгемне иремә күрсәтү түгел, үземне көзгедән дә карый алмадым. Бик озак кабул иттем үземне. Хәтта психологлар белән эшләдем. Беренче химиотерапия курсы бик авыр булды. Чәчләрем коелгач, парик алып кидем. Ул вакытта яман шеш авыруы белән авыручылар күп түгел иде әле. Кайбер тәрбиясез кешеләр хәтта бармак төртеп күрсәтте. Яман шеш авыруы таралмасын өчен, күрем күрүне вакытыннан алда туктаттылар. Ике ел буе махсус препаратлар кададылар, ә мин авырга уздым. Климакс вакытында авырга ничек узуымны бер табиб та аңлата алмады. Моның табигатьтә булганы юк, диделәр. Авырлы икәнемне бишенче айда гына белдем. Эчемдә нидер селкенгәч, бавырым таралыдыр йә кортлар бардыр дип уйладым. Табибка да эчемдә кортлар бар, дип бардым. Ул мине гинекологка җибәрде. Табиблар консилиум җыйды. Онкологлар баламны төшертергә киңәш итте, ә генетиклар моның өчен бер сәбәп тә юклыгын әйтте. Баланы табасым килде, әлбәттә. Иремнең ул беренче баласы иде, аннан мин бит инде аның белән сөйләшеп йөри идем... Ничек бала гомерен өзәсең?! Ходай биргән сау-сәламәт балама Богдан дип исем куштым. Балалар үстердем, бизнес ачтым. Үземнең матурлык салоны, косметика, хушбуйлар сата торган кибетләрем бар иде. Ун ел бер кайгысыз яшәдем шулай. Менә ике ел элек, сулыш алырга авырлаша башлагач, кабат тикшерелергә тотындым. Метастатазлар күкрәк куышлыгына, сөяккә киткән. Диагнозымны белгән көннәрдә истерика булды. Балаларым өчен курыктым. Кечкенәсенә – 6, олысына 15 яшь. Анысы дөм ятим кала дип уйладым, әтисе үлгән иде. Балаларны мәктәпкә дә, бакчага да җибәрмичә, көне буе кочаклап утырдым. Соңгы көннәремне яшим дип уйладым. «Подари жизнь» фондының психологлары мине тормышка кайтарды. Алар белән интернет аша бик озак эшләдем. «Табиблар Аллаһы Тәгалә түгел, барыбыз да Аллаһы канаты астында», – дип тынычландырдым үземне. «Мин яшәячәкмен» сүзләрен үземә шигарь итеп алдым. Һәр иртәне уянам да догалар, аффирмацияләр укыйм. Хәзер химиотерапия алып яшим. Бу юлы чәчем коелгач, оялу да булмады. Бик тыныч кына, башыма кимичә дә йөрдем. Кабат әкренләп хушбуйлар сата башладым. Миңа бит яшәргә кирәк. Тормыш өчен кирәк булган препаратларны сатып алырга пенсия акчасы гына җитми. Онкопациент булгач эшкә алырга теләмәгәннәр иде, әмма директор уңай хәл итте. Мин аларның өметләрен йөз процентка акладым. Үзебез яшәгән подъездтан кызыма фатир алып куйдым, улымның исә әтисе бар. Балаларым өчен хәзер тыныч мин. Шатланып яшим. Гап-гади яшәүнең олы бер бәхет икәнен аңладым инде... Мин яшим! Моннан да зур шатлык юк!

Узган ел май аенда култык астында, капшагач, шеш барлыгын сизеп, УЗИга киттем, һәм шуннан башланды… Диагнозымны белгәч, барысына да өлгерергә кирәк дигән уй баштан китмәде. Иң беренче куркуым балаларым өчен булды. 4 һәм 6 яшьлек улларым әнисез кала дип уйладым. Әмма соңрак аңладым: алар минсез дә үсәчәк. Шуңа кем өчендер түгел, үзем өчен яшәргә тиешмен дигән нәтиҗәгә килдем. Күкрәгемне алдырырга озак әзерләндем. Моның турында өйдә дә сөйләштек. Безнең ситуациядә бу иң кечкенә югалту дип уйладык. Әмма табибым Альберт Гыймранов медицинаның хәзер алга китүен, операция барышында күкрәккә имплант куячакларын әйтте. Беләсезме, гомерем буе күкрәкләремнең кечкенә булуын теләдем. Бик зур иде алар минем. Хыялым менә шул рәвешле чынга ашар дип кем уйлаган? Шеш булган күкрәгемне кисеп алып имплант куйдылар, икенчесен дә кечерәйттеләр. Наркоздан уянгач, үземне онкодиспансерда итеп түгел, ә кыйммәтле клиникада пластикага яткан кебек хис иттем. Йөри ала башлауга көзгедән барып карадым. Күкрәкләрем бинт белән бәйләнсә дә, җиңеллек тойдым. Шуңа күрәдер, күңел төшенкелегенә бирелмәдем. Метастазлар киткәнлектән, химиотерапия билгеләделәр. Ярты елга сузылды ул. Дәвалану барышында үлем, үләм дигән уй бер тапкыр да күңелемә килмәде. Яшәячәгемә шуның кадәр нык ышанган идем. Бөтен куркуым: минем өчен борчылып якыннарымда ул авыруның барлыкка килүе иде. Аларга бер-бер хәл булса, үземне гаепле санар идем. Авыруның сәбәпчесе, генетикадан кала, стресс икәнен бик яхшы аңладым. Соңгы елларда бер-берт артлы туганнарыбызны, аннан соң әтиебезне җирләдек. Әти үлгәч, яшәүнең мәгънәсен югалттым. Үз эчемә бикләндем. Ирем белән дә мөнәсәбәтләребез начарайды. Әти минем җирдәге кояшым иде. Балалар дип яшәде ул. Балаларым кайда, Ватаным шунда дип, пенсиягә чыккач, әни белән монда күченеп килделәр. Зур җир кишәрлеге сатып алды. Анда өч йорт тора: әти-әнинеке, сеңлем Әлфиянеке һәм безнеке. Күз алдыгызга китерәсез инде минем өчен нинди зур югалту булганын. Күрәсең, киредән яшәргә өйрәнер өчен шушы авыруны узарга кирәк булгандыр. Бу авыру безнең гаиләне тагын да ныгытты. Ирем белән мөнәсәбәтләребез җылынды. Дөрес кеше сайлаганымны аңладым. Ул мине бер дә җәлләмәде. Баштарак хәтта хурландым да, әмма соңрак аның бик көчле кеше икәнен аңладым. Терелгәч: «Синең терелячәгеңә бер секунд та шикләнмәдем», – диде. Дәвалануның беренче көннәрендә әллә нинди каршылыклы хисләр белән йөрисең, чөнки организмыңны агулап дәваланганыңны аңлыйсың. Әмма ул халәт өчдүрт көн генә дәвам итә һәм элеккәчә яши башлыйсың: балаларны мәктәпкә илтәсең, өй эшләренә күмеләсең… Әмма башта әле бер өч көнгә тормыш арбасыннан төшеп каласың. Мин ул көннәрдә күземне йомып ялгызым гына ятып тордым. Иң аянычы: химиотерапия августта башланды, ә сентябрьгә инде чәчләрем коелып бетте. Баламны беренче сыйныфка башыма чалма киеп алып бардым. Баш киемен озак сайладым. Ул иң матуры булырга тиеш иде. Психосоматикага бик ышанам. Дәвалану курслары узганнан соң, УЗИ икенче күкрәгемдә дә шеш күрсәтте. Үз-үземне ышандыра башладым. Һәрвакыт шешнең бетүен күз алдыма китердем. Бер айдан соң шеш кечерәйгән иде, тагын бер айдан соң пункциягә баргач, аны тапмадылар. Хастаханәдән чыккач, югалып калдым. Хәтта үземнең диагнозымны белгәч тә андый хисләр кичермәгән идем. Рухи яктан бу авыру белән көрәшергә әзер идем чөнки.

Авыруым тормышыбызны үзгәртте. Элек барысын да үзем тартырга тырыша идем. Һәрнәрсәне контрольдә тотарга теләү – хатын-кызларның иң зур хатасы. Миңа һәрвакыт өйдә тәртип булу кирәк иде. Аунап яткан уенчыклар, киемнәр чыгырымнан чыгара иде. Хәзер мин аның ише вак-төяккә игътибар да итмим. Ирем, улларым белән куанып яшим. Чәч коела башлагач, сеңлем аларны кырды. Кечкенә улым да, әни кебек булам дип, чәчен шулай алдыртып йөрде. Яман шеш белән очрашкач, үзеңне җәлләп елап утыру мәгънәсезлек икән. Бу авыруны җиңәр өчен, тормышымны кайсы якка үзгәртергә икән дип уйлагыз. Ярдәм итми калмас…

Фото: Ирина Волобуева, Игорь Глазырин, Диана Гарипова.



Алия Әсхәдуллина, 32 яшь.
Күкрәгендә яман шеш авыруы.

«Әниегезнең пеләш булуына хурланмыйсызмы?» – дип сорадым малайлардан. «Әни, син иң матуры», – диделәр. Ирем дә, пеләшемнән сыйпап, матурым, дип әйтә иде. Гаиләдәге җылы мөнәсәбәтләр – иң шәп дару ул…

ТАБИБ БУЛУ – ЗУР ҖАВАПЛЫЛЫК!



Фото: Анна Арахамия

Яшеллеккә, чәчәкләргә күмелгән шушы республика балалар клиник хастаханәсе шәһәрчегe буйлап ул көн саен ашыгып атлый. Һәр көнне ул кемнәргәдер бик кирәк. Аңа гел шалтыраталар, аны гел көтәләр. Менә бу юл күрсәткеч ук үзе утыра торган 7 нче терминалга алып китә. Ике катлы шул гади генә бина да диварларындагы яшел, зәңгәр, сары, кызыл шакмаклары белән балаларны үзенә җәлеп итә, кәефләрен күтәреп җибәрә. Чөнки ул башка биналар кебек түгел, ул – башкача. Яктылык, җылылык, өмет, ышаныч төсләре ул шакмакларда. Ә эчтәге бүлмәләрдә балалар рәсемнәре көлеп тора: яшел агачлар, зәңгәр һава, сары кояш, кызыл гөлләр...

– Исәнмесез, Динара Илгизәровна!

– Без сезнең янга...

– Бар өмет – Сездә!

Көн саен шулай. Һәр авыру балага, аларның әти-әниләренә кирәк ул! Игътибар белән тыңлап, һәркайсына ярдәм итәргә әзер. Кечкенә пациентларын авыр чирләрдән коткару юлларын эзли. Төн йокыларын калдырып, шулар турында уйлый, шуларны савыктыру өчен төрле яңа дәвалау төрләрен куллана, инновацион технологияләргә таяна. Журналистлар белән узган матбугат конференцияләрендә дә ул – Казан дәүләт медицина университетының госпиталь педиатриясе кафедрасы мөдире Динара Илгизәр кызы САДЫЙКОВА – уйландыра, сагайта торган мисаллар китереп сөйли.



Эльмира ЗАКИРОВА

Балалар да гипертония белән авырый икән. Ләкин күп очракта алар аны сизмиләр, ди. «Ул тумыштан ук килә яки үсмерлек чорында үзен сиздерә. Сәбәпләре зурларныкы кебек: артык авырлык, аз хәрәкәтләнү, стресс, гаджетлар, фастфуд һәм газлы сулар...» «Россия балалар кардиологлары ассоциациясе» Бөтенроссия иҗтимагый оешмасының генераль директоры, медицина фәннәре докторы Динара Садыйкова сөйләгәннәрдән аерым фикерләр кагыйдә булып яңгырый. «Бала начар йокласа, баш авыртудан зарланса – сагаерга кирәк...», «Балалар белән үзегез шөгыльләнегез. Аларны гаджет һәм интернет түгел, әти-әниләре тәрбияләсен...», «Югары кан басымы инсультка, инфарктка китерә, бөергә, баш миенә, күзләргә зыян сала...»

Татарстанның атказанган табибы Садыйкова Динара Илгизәр кызы әнә шулай сүзләрен үтемле итеп әйтә дә белә. Ул балаларда тумыштан күзәтелә торган патологияләрне алдан ук белү буенча республика табиблары тарафыннан булдырылган уникаль система турында сөйләп китә, бала имезүнең никадәр мөһим булуына туктала, гаджетларның тискәре яклары турында кат-кат искәртә.

...Аның белән әңгәмәне эшендә дәвам итәбез. Минем өчен ул – кызыклы шәхес. Медицина дөньясында билгеле табибә. Табиблар династиясеннән булуы белән дә аерым игътибарга лаек әле ул. Әти-әниләр дә, килен-кияүләр дә, кода-кодагыйлар да, балалар да – барысы да табиблар!

– Динара Илгизәровна, Сез республикабызның танылган табибы. Ничек килдегез бу эшкә?

– Әтием Зыятдинов Илгизәр Галимҗан улы гомер буе Казан медицина университетында педиатрия кафедрасы доценты булды. Әнием Луиза Абдрахмановна да – табибә, ул РКБда фонопед: опера җырчылары, эшләре тавыш белән бәйле кешеләр аңа мөрәҗәгать итә. Безнең гаиләдә бөтенесе врачлар, табиб булмаган бер генә кеше дә юк. *(Көлә.)* Энем Айрат Илгизәр улы Зыятдинов – Республика балалар клиник хастаханәсенең баш табибы, ул шулай ук медицина фәннәре кандидаты. Ирем Садыйков Марат Наил улы шулай ук врач, ул бүгенге көндә республикабызның сәламәтлек саклау министры. Аның сеңлесе Гүзәл Наил кызы – 7 нче клиник хастаханәнең физиотерапия бүлеге мөдире. Кайнатам Садыйков Наил Сәлах улы Россиянең атказанган табибы, озак еллар Татарстан Республикасының сәламәтлек саклау министры урынбасары булды, кайнанам Назирә Ислам кызы 18 нче клиник хастаханәдә рефлексотерапевт булып эшләде. Менә шундый гаилә без... Минем алда киләчәктә кем булырга дигән сорау тумады да. Әти үзенең ни өчен врач булганын да сөйли иде. Ул кечкенә вакытта әнисе – дәү әнием пневмония белән авырый башлаган. Олы Нырсыдан районга алып киткәннәр. Әти бик кайгырган: үзе дә мәктәп баласы гына бит! Һәм шунда, врач булам, дип, үзенә сүз биргән. Мәктәпне тәмамлагач, медицина институтына укырга кергән. Хәтерлим әле: дәү әти белән дәү әни әз генә чирләп китсәләр дә, әти авылга ашыга иде... Мин дә һич икеләнмичә медицинаны сайладым. Медуниверситетка кергәч инде, әти гомерлек укытучым булды. Ул минем фән белән дә шөгыльләнүемне тели иде. Врач фәнни яктан да әзерлекле булырга тиеш, дип, гел әйтә килде. Башта ординатурада укыдым, аннары аспирантураны тәмамладым.

– Педиатриянең аерым бер юнәлешен сайлау авыр булдымы?

– Диссертациямнең темасы балаларның төрле авыруларга каршы тора алуына, ягъни иммунитетка багышланган иде. Бик проблемалы өлкә, бүген дә актуаль. Әти фәндәге юлымны алга таба да дәвам итүемне хуплады: мине докторлык эшенә юнәлтте. Ул вакытта әле балалар авырулары барысы да зур бер бүлеккә – педиатриягә карый, балалар кардиологы дигән бердәнбер белгечлек бар иде. Әти аның бик перспективалы булачагын алдан ук күрә белде, миңа шул юнәлештән китәргә тәкъдим итте. Элегрәк кардиоревматолог дип йөртелә иде. Хәзер икегә бүленде: кардиологиягә һәм ревматологиягә. Фәнни эшем дә кардиология белән бәйле булып чыкты: темам артериаль гипертониягә карый иде. Казанда кардиология белән профессор Альберт Сәрвәрович Галявич шөгыльләнә. Балаларда артериаль гипертония темасын ул тәкъдим итте.

– Балаларда артериаль гипертония?!.

– Әйе! Андый авыруга тарыган балалар чынлап та күп иде! Мәскәүгә конгресска бардым. Профессор, педиатрия фәнни-тикшеренү институтының балалар кардиологиясе һәм аритмологиясе бүлегенең баш фәнни хезмәткәре, профессор Ирина Леонтьева безнең җитәкчебез булды. Миңа бу өлкәдә эшләү кызык иде. Моңарчы әле бу проблема белән беркем дә шөгыльләнмәгән бит. Нульдән башладым дисәм дә була. Гипертензия темасын Татарстанда әле өйрәнгән кеше юк иде. Шул тематиканы үстерә башладым. Мәскәүдәге коллегаларым да бик булышты. Ирина Викторовна, мәсәлән, андый авыруларны ничек дәваларга, ничек диагноз куярга, ничек кан басымын дөрес үлчәргә, нинди препаратлар кулланырга кирәген өйрәтте. Шунысы да бар: күп даруларны балаларга бирергә ярамый, шуңа күрә дәвалау шактый катлаулана. Диагностика һәм дәвалауның яңа методларын кулланабыз.

– Димәк, сез теория белән практиканы бергә бәйләп алып бардыгыз?

– Әлбәттә! Һәм берничә елдан инде Мәскәүдә докторлык диссертациясен якладым. Гипертензиядән тыш, мин балалар липидологиясе врачы да. Липид алмашы бозылу, склероз турында ишеткәнегез бардыр инде. Зурлардагы атеросклероз бик җитди проблема, ул йөрәк-кан тамырлары авыруларына китерә. Ә липид алмашындагы тайпылышлар нәкъ менә бала вакыттан башлана. Алар беренчел, ягъни нәселдән килә торган авырулар булырга яки диабет, бөер авырулары кебек икенчел дә булырга мөмкин. Казанда Россиядә беренче балалар липидологиясе үзәген ачтык. Ул липид клиникаларының Европа челтәренә кергән, 2018 елга кадәр безнең пациентларга әле андый диагнозны куючы да булмаган, андый балалар барын да белмәгәннәр. Бу – яңа юнәлеш. Ә хәзер бездә гаилә диагностикасы буенча махсус программа эшли. Әлеге программа балаларга һәм өлкәннәргә генетик тикшеренүләр узарга һәм бушлай диагностикадан файдаланырга мөмкинлек бирә. Балалар үзәге һәм зурлар үзәге ачылды. Һәм алар үзара бәйләнештә. Безнең команда, безнең врач-

Күп авырулар ата-аналарның ваемсызлыгыннан да килә.





■ Имтихан-зачетларны һәрчак үзем алырга тырышам, һәм ярыйсы гына кырыс, таләпчән дә булам. Соңыннан инде төзәтелмәслек хаталар килеп чыкмасын өчен шулай кирәк. Чөнки ул, университетны тәмамлап врач булып эшли башлагач, авырулары белән үзе генә кала: нәрсәнедер сорап алырга курсташлары да, укытучылары да янәшәдә булмый. Шуңа күрә медуниверситет студентлары авыру янында озаграк булсын иде, аларга практика кирәк дим мин.

лар яңа дәвалау методлары ярдәмендә пациентлардагы сирәк очрый торган чирләрне дә ачыклый алалар. Әйтик, плазмаферез – канны механик фильтрацияләүне кулланып, иң кечкенә – алты айлык балаларны да дәвалыйбыз.

– Сез бит әле медицина университетында госпиталь педиатриясе кафедрасын да җитәклисез...

– Безнең кафедра 5-6 нчы курс студентларына лекцияләр укый. Кафедра мөдире булып килгәч, башта бер идея туды: кафедраның тарихы белән кызыксынырга, кайчан оешканын ачыкларга. (*Илһамланып.*) Кызыклы фактларга юлыктык. Университетта балалар авырулары буенча лекцияләр укый башлауга киләсе елда 200 ел тулачак.

– Сез кемне үзегезнең остазыгыз дип саныйсыз?

– Беренче чиратта, әтиемне!

– Балаларыгызны үзегез дәвалыйсызмы?

– Алар инде зурлар. (*Елмая.*) Аллага шөкер, алар сирәк авырды балачакта. Үзем балалар врачы, ә үз балаларым авырып китсә, бик борчыла идем. Хәтта кирәгеннән артык та кайгырдым кебек. Миндә паника башлана иде. «Зинһар, син кара әле», – дип, педиатр дус кызыма мөрәҗәгать итәм. Улыбыз Марсель хәзер үзе доктор, КФУ клиникасында баш табиб урынбасары. Кызыбыз Камилә медуниверситетның дәвалау факультетында IV курста укый.

– Табиб эшендә язылмаган кагыйдә нинди икән?

– Үзеңнең авыруларыңны яратырга кирәк! Еш кына күп авыруларның сәбәбе, кызганыч, ата-аналарның ваемсызлыгына барып тоташа. Алар үз балаларының сәламәтлегенә игътибарсыз кала. Бала – үз гаиләсенең чагылышы ул. Соңгы вакытта бик күп балаларда психологик проблемалар барлыгы күзгә ташлана. Без шуның белән көн саен очрашабыз. Шундый очраклар да була: стационарда яткан кайбер балаларның өйләренә кайтасы килми. Бу бит инде гайре табигый хәл! Температура, нindидер авыру симптомнары уйлап чыгаралар... Күреп торабыз: димәк, өйләрендә рәхәт түгел; димәк, игътибар җитми аларга.

– Эшегезгә бәйле кыен хәлләр булганы бармы?

– Кайчак шулай да була. «Бу балага ярдәм итә алам бит мин, аякка бастырам, чирен җиңәм!» – дип уйлыйсың. Тик әти-әнисе синең дәвалау белән килешми: «Ә интернетта болай язылган», – дип үзбелдекләнә. Яисә шундый очрак: без дәвалау курсы билгелибез, ә алар авылга китеп баралар, андагы туганнары сүзен тыңлап, дәвалануны үзләре үк өзә. Балалар кызганыч! Аларга булышасым килә, әмма әти-әнисе карышып, бөтен эшне боза. 15 яшьлек бер кызны ничекләр дәвалавыбыз бүгенгедәй күз алдымда. Ул беренче пациентыбыз иде. Плазмаферез ясадык аңа. Мәскәүдәге, Италиядәге коллегаларыбыз, танылган белгечләр белән киңәшләштек. Операция уңышлы үтте! Үпкә гипертонияле пациентыбызны да гел искә алам. Әйе, дәвалап булмый торган авыру... Яшәүгә шанс юк дигән сүз. Препаратлар табу да җиңел түгел. Ул малай өчен дарулар юллап, дәвалаганда яңа алымнар кулланып, безнең врачлар аны өлкәннәр үзәгенә күчерә алды. Артистларның хәйрия концертында катнашудан кергән акчасына препаратлар кайтартылды. Шушы дәва аны үлемнән коткарды... Диагностикадагы яңа методлар ярдәмендә йөкле хатын тудырасы баланың авыруларын да билгели алабыз. Кайбер операцияләрне ана карынындагы сабыйга да ясыйбыз. Ул балалар тугач инде, үзләре белән ешрак очраша башлыйбыз. Аннары гипертензия кебек хроник авырулылар терелә хәзер. Ә элек кайбер авырулар бала вакытта ук үлә барган. Бүген андыйлар исән кала, үсә, гаилә кора...

– Иң шәп тандем: әти-әни, табиб, бала үзе, димәк?

– Әлбәттә! Медицинада берүзең генә эшләү мөмкин түгел, белгечләр командасы, күп врачларның хезмәте ул. Чирне шулай гына җиңеп була. Без – чын профессионаллар командасы. Студентларыма гел әйтеп киләм: авыруны берүзен генә калдырырга ярамый. Поликлиника дәрәҗәсендә ярдәм итә алмасаң, больницага җибәр, анда да ярдәм итә алмасалар, федераль үзәккә озат. Авыру кеше үзенең чире белән берьялгызы калырга тиеш түгел.

– Сез эш урынында булмаган чакта да беренче медицина ярдәме күрсәтергә туры килгәне булдымы?

– Самолетта очканда булды андый хәл. Марат Наилевич белән ялдан кайта идек берчак. «Пассажирлар арасында врачлар бармы?» – дип сорый борт капитаны. Без врачлар, дибез. Бер хатынның кинәт хәле начарлан-

ган, аңын югалткан. Баласы куркудан кычкырып-кычкырып елый, ире шок хәлендә... Марат Наилевич шундук хәлне аңлап алды, тиешле беренче ярдәмне күрсәттек. Хатын исән-сау Казанга кайтып җитте... Машинада бакчадан кайтканда исә куркыныч юл һәлакәтен күреп тукталдык. Дүрт машина бәрелешкән иде. Гел яшьләр! Коточкыч күренеш! Без Марат Наилевич белән машинадан чыктык. ДРКБның балалар реанимациясе бүлеге мөдире Игорь Илдусович Закиров та шунда иде. Өчәүләп әле бер, әле икенче машинага йөгерәбез. Андагы кан, җәрәхәтләр... «Ачык реанимация» юнәлешендә эшләүче врач буларак, Игорь Илдусовичның бик алга киткән аппаратуралары бар иде. «Ашыгыч ярдәм» килеп җиткәнче, бер кешедән икенчесенә күчә-күчә, йөрәк-үпкә реанимациясе ясап, үлем хәленнән чыгарырга тырыштык. Ул чакта мин Игорь Илдусовичка бик рәхмәтле калдым. Һәркем йөрәк-үпкә реанимациясе үткәрерлек база белемнәренә ия булсын икән ул. Теләсә кем шундый хәлдә калырга мөмкин. Йөрәк-үпкә реанимациясен һәркем белергә тиеш, әнә шулай кешене коткарып кала аласың. Ул көндәге куркыныч авариядән соң мин шундый нәтиҗәгә килдем. Сәламәтлек саклау министрлыгы белән бергә йөрәк-үпкә реанимациясе программасын эшләдек һәм республиканың бөтен районнарын йөреп чыктык, барлык врачларны укыттык. Безнең махсус автомобилебез дә бар хәзер. Аны да үзебез уйлап таптык, Түбән Новгородта заказ буенча җыеп бирделәр. Менә шундый укыту комплексы дисәң дә ярый аны. Чөнки автомобильгә йөрәк-үпкә реанимациясе өчен махсус манекеннар урнаштырылган, ә алар компьютерга тоташтырылган. Авыру турында укып белү – бер нәрсә, ә манекенда эшләү – бөтенләй башка. Дөрес эшлисеңме, юкмы, кеше тереләме, юкмы икәне шундук күренә.

– Хыялыгыздагы медицина нинди ул?

– Безнең медицинага цифрлаштыру җитми. Чит илләрдәге клиникаларда еш булырга туры килгәне бар. Төркиядә, Германиядә, башка илләрдә... Анда сабый тууга ук бала үсешенең электрон медицина көндәлеген ачалар. Һәм анда бөтен мәгълүмат туплана. Пациент нинди генә хастаханәгә килсә дә, табиб аның бөтен медицина тикшеренүләре, авырулары тарихы турында белеп тора. Бездә дә эш шулай оештырылса, авыруга да, дәвалаучы врачка да җиңелрәк булыр иде. Кайчак бик җитди авырулы пациентлар килә. Ә бит алар бер көндә генә шулай авырып китмәгән. Мәсәлән, йөрәк авырулы бала. Ләкин ул, кызганыч, никтер 15–16 яшьләрдә генә табибка мөрәҗәгать итә. Һәм без берни эшли алмыйбыз – йөрәк күчереп утыртып кына коткарып калып була. Ә без аның авыру тарихын белә алмыйбыз. Йә документлары югалган, йә башка сәбәпләр... Әгәр баланың электрон медицина көндәлеге булса, бөтен тишеренүләр, дәваланулар сакланып калган булыр иде.

– Кыен чакларда кемнәргә таянасыз, Динара Илгизәровна?

– Гаиләмә! Ул минем өчен барыннан да өстен. Өйдә гел медицина турында сөйләшәбез дисәм дә, ялган булмас.

– Ә министр хатыны булу кыенмы?

– (*Көлеп җибәрә.*) Бер караганда, катлаулы, әлбәттә. Ә икенче яктан, кызык та. Чөнки күп проблемалар, яңа идеяләр турында һәрчак өйдә сөйләшәбез, һәм ул уңай чишелешләргә китерә. Кайбер яңалыкны, фәнни проектларны республика күләмендә кертү турында сүз алып барабыз. Эш аркасында бәхәсләшеп беткән, үзара килешә алмаган чаклар була. Хакыйкать тә бәхәстә туа бит! Кайчак Марат Наилевич, син дөрес уйламыйсың, ди. Ярар, дәшми калам. Ләкин барыбер үз фикеремнән кайтмыйм. Икенче көнне инде ул: «Уйладым-уйладым да, хатын, син хаклы булгансың бит!» – дип куя.

– Ничек танышуыгыз турында да сөйләрсез, бәлки?

– Икебез дә медицина институтының педиатрия факультетына укырга кердек. Дуслаштык, аралаша башладык. Дөрес, башта төрле группаларда укый идек әле. 5 нче курста укыганда эксперименталь төркем оештырдылар. Фәнни-педагогик резерв төркеме дип атала иде ул. Әнә шулай бер төркемдә уку тагын да якынайтты безне. Ләкин без – төрле! Мавыгуларыбыз, кызыксынуларыбыз бер-беребезнекенә гел дә охшамаган. Мин бакчада казынудан тәм табам. Шуннан да шәп ял юк! Шуңа Марат Наилевич: «Синең бакчаң», – дип кенә җибәрә. (*Көлә.*) Китаплар укырга, Россия тарихына, хатын-кыз сәясәтчеләр тормышына кагылышлы китаплар, тарихи романнар укырга яратам. Спорт, хәрәкәт, тизлек – минеке. Чаңгылар, тимераяклар булсын миңа. Ә Марат Наилевичның артык исе китми. Алай да чаңгыга бергә чыгабыз. Сәяхәт итәргә менә аңа куш инде! Аннары бик гаилә җанлы ул. Безнең гаиләдә Марат – әни урынындадыр. (*Көлә.*) Балаларга бик игътибарлы, кайгыртучан. Аларның кайда, ниләр эшләп йөрүен белеп тора. Мин – бик кырыс әни, ә ул йомшак күңелле, җайлы әти.

– Сезнең өчен эшегездә иң кыены...

– Иң кыенымы... (*Уйланып тора.*) Хаталар ясаудан куркудыр, мөгаен. Табиб булу – зур җаваплылык ул! Башкалар тормышы, башкалар сәламәтлеге өчен җаваплылык аласың үзеңә. Авыру баланы караганнан соң өйгә кайтасың, ә шул бала турындагы уйлар һаман баштан чыкмый. Дөрес эшләдемме? Бөтен төр дәваны да билгеләдемме? Кинәт башыңа бер фикер килеп, хастаханәгә шалтыратасың. «Менә бу метод белән дәвалауга күчик әле», – дисең. Юлда да, өйдә дә һаман шул авыру баланы уйлап йөрисең. Җаваплылык хисе, ялгышулардан курку хисе гел үзем белән. Мин авыруларыма һәрчак үз телефонымны бирәм. Хезмәттәшләрем кайчак җиңелчә шелтәләп тә куялар: «Динара, чикләрне узасың. Алай артык киң күңелле булма инде», – диләр. (*Елмая.*) Әйе, чаманы да оныталар кайчак. Ял көнне төнге унбердә дә шалтыраталар, ватсаптан анализларын җибәрәләр. «Минем анализларны карагыз әле», – диләр. «Әйдәгез, иртәгә иртәдән карарбыз», – дигән сүзләр генә канәгатьләндерми инде аларны. Аларга тиз, хәзер үк булсын! Кайчак машинага утырам гына – моң-зарлары белән шалтыратырга тотыналар. «Гафу итегез, мин рульдә», – дим. «Ә сез туктап тыңлагыз», – диләр. Менә шулай! (*Үзенә бер ярату белән сөйли.*) Аларга һәрчак ярдәм итәргә тырышам. «Шалтыратыгыз», – дим. Кардиологиядә ятучы хәле авыр балаларның барысында да минем телефон номеры бар. Аларның көр тавышын ишетсәм дә сөенәм!

«БАЛА БЕЛӘН ГОРУРЛАНА БЕЛЕРГӘ КИРӘК»

Үсмерлек чоры. Ата-ана өчен иң зур сынау вакытыдыр бу, мөгаен. Сүзеңне тыңлап, һәрвакыт янында сырпаланган бала көннәрдән бер көнне бөтенләй үзгәрә дә куя. Аның инде үз дөньясы... Бала белән бәйләнешне ничек саклап калырга? Үсмер белән үзеңне ничек тотарга? Бәлки, безнең геройларыбыз тәҗрибәсе дә сорауларыгызга җавап табарга ярдәм итәр. Рубрикабызның кунаклары – Татарстан Республикасы законнарының татар һәм рус телләрендәге текстлар тәңгәллеген билгеләү буенча Дәүләт Советы комиссиясе рәисе Римма РАТНИКОВА һәм аның улы АЛЕКСЕЙ.



Лёша, син интернет киңлекләрендә үз аудиториясе булган үсмер-блогер. Треклар яздыртасың. «Мин – йолдыз» дигән тәкәббер хис юкмы?

– Популярлык түмен беренче трегымны яздыртып, интернетка чыгаргач сиздем. Урамда таный башладылар, минем белән фотога төштеләр. Хәтта фанатларым белән очрашу уздырдым. Трекны танылу өчен яздырмаган идем үзе, ул күптәнге хыялым иде. Әйе, популярлык белән тәкәбберлек хисе бергәрәк йөри шул. Хайп тоткач миндә дә булып алды ул, әмма һәр хайп кебек бик тиз узды. Әти белән әни трек яздыруыма теләктәшлек кенә белдерделәр. Моның хыялым икәнен беләләр иде. Популярлыкның нинди икәнен аңладым инде. Ошады.

Син яшьтәшләреңә нинди бәяләмә бирер идең?

– Миңа калса, хәзер әхлакый яктан бик авыр чор. Яшьтәшләрем арасында дорфалар, кимсетеп, башкалар хисабыннан үз шәхесләрен расларга яратучылар күп. Трек яздыртып, билгеле бер мохиттә популярлык казангач, көнләшүчеләр булды. Алар үзләре берни эшләми, ә синең тырышлыгыңны юкка чыгарырга тели. Башкаларның уңышлары алга барырга мотивацияләгән яшьтәшләрем дә күп. Алар инде чын күңелдән синең өчен шатлана белә. Үзләрен даими камилләштерәләр, максатлары бар. Шундыйлар уңышка ирешә дә ул.

Ә үсмерләр хәзер нәрсә белән кызыксына?

– Күбрәк популярлык казану юллары белән кызыксыналардыр. Без бит Z буыны балалары. Безнең заманда кемгә кызык түгел инде ул?!

Әниең белән бер-берегезне аңлыйсызмы?

– Әлбәттә. Яшь аермабызның гадәттәге гаиләләрдән зуррак булуы бервакытта да комачауламый. Без әни белән бик якыннар. Ул – миңа, мин аңа ышанам.

Конфликтлар булгалыймы соң?

– Алар бар гаиләдә дә бар инде. Гадәттә, минем нидер дөрес эшләмәвем, тыңламавым аркасында чыга. Бер үк сүзне берничә тапкыр кабатлаулары чыгырымнан чыгара, шул вакытта әнигә тавыш күтәрергә мөмкинмен. Соңыннан якын кешем алдында бик оят була. Барып гафу үтенәм. Ә гафу үтенү минем өчен авыр түгел. Дусларым белән аралашканда башкалар өчен дә гафу сорый алам. Минем өчен бөтен кешенең дус яшәве бик мөһим.

Өлкәннәрнең акыл өйрәтүләренә ничек карыйсың?

– Дөрес юнәлештә икән, тыңлыйм. Әмма башка кешедән үзен үк ясарга теләүләренә мин каршы. Без һәрберебез индивидуаль, һәрберебезнең үз юлы бар. Бер үк язмышны кабатлый, бер үк тормыш юлын үтә алмыйбыз. Әти-әниләр шуны аңласын иде. Үзеңә уңайлы итеп тәрбияләүне хупламыйм. Мәктәптә яхшы уку белән генә чикләнми бит әле ул үсмер дөньясы... Бәлки, аның башка юл белән барасы киләдер.

Әниеңнең кайсы киңәше гомерлеккә истә калыр?

– Бернигә карамыйча үзең булып кал, үз юлың белән бар, кеше сүзенә карама, шул вакытта гына уңышка ирешерсең.

Сөйләшкәндә дус кызым дип берничә кат әйттең. Әниең кызлар белән йөрүеңә ничек карый?

– Әйткәнемчә, әнигә барысын да сөйлим. Кызлар турында да. Ул бервакытта да кызлар белән дус булуыма каршы булмады, хәтта шатлана гына бугай. Әни белә: ялгызлыкны яратмыйм, үз эчемә бикләнәм, үземне кирәксез итеп саный башлыйм. Йөргән кызым барлыкка килгәч, бик үзгәрдем. Хәтта минем дөньям башка кебек. Яраткан кешең булу рәхәт бит! Ә миңа беренче тапкыр аерылышуны бик авыр кичердем... Бу хакта әнидән башка тагын кемгә сөйлисең?! Ул кызга багышлап җыр да яздырдым. Әни сүзләрен язды.

Искиткеч! Чынлап та әниең белән бик җылы мөнәсәбәттә икән сез. Ә әти-әниең алдында үзеңне бурычлы итеп тоясыңмы?

– Әйе. Беләм: мин гаилә корырга, киләчәктә аларга тыныч һәм куанычлы картлык булдырырга тиеш. Әти белән әни миңа бик күпне бирде. Шуның өчен зур рәхмәтлемен. Алар мине үстерде, тәрбияләде. Әйе, ачуланышабыз, әмма ярату низагтан көчлерәк!

Ә үзеңне киләчәктә кем итеп күрәсең?

– Дәүләт аттестациясен узгач, ныклап музыка белән шөгыльләнә башлармын дип уйлыйм. Реп-индустриягә тартылам. Егор Крид кебек буласым килә. Шулай ук видеомонтаж эшләрен үз итәм. Бу өлкәдә хәтсез тәҗрибәм бар. Курыкмыйча теләсә нинди монтажга тотына алам. Акча эшли башлыйсым килә инде.

Римма Атласовна, сез нинди үсмер идегез һәм хәзер нинди әни?

– Без идеаль үсмер идек. Башкача мөмкин дә түгел: әти – Кукмара районының беренче секретаре, әни – укытучы. Тугарылып китмәс өчен безне ныклы кулларда тоттылар. Әнинең: «Кеше алдында тәкәбберләнеп йөрмәгез, сезнең артта – әтиегез», – дигән сүзләре миңа, гаиләдәге иң олы балага бик нык тәэсир итте. Безнең өйдә әти культы, укытучы культы иде. Һәр яктан камил булырга тырыштым. Без бик яхшы укыдык. Һәм яхшы укуны абруйга санадык. Белемне чынлап та әйбәт биргәннәр, әле дә улыма дәрес әзерләгәндә ярдәм итәм. Кечкенәдән эшләп үстек. Тормыш өчен шәп чыныгу иде ул. Балаларны җәлләми тормышка әзерләргә кирәк тә соң, әмма, кызганыч, мондый тәрбия соңгы елларда онытылып бара. Мин дә үземне артык таләпчән әни дип әйтә алмыйм, кирәк чакта кырыс була беләм. Аллага шөкер, безнең Лёша күндәм бала. Әмма һәрвакыт сүз тыңлый дип әйтә алмыйм. Аларның яшьләре шундый инде. Кушкан эшне эшләмим дими, әмма аны башкаруны суза. «Хәзер яныңа тапочка белән киләм», – дим кайвакыт. «Ярар, аңладым, әни», – дип эшләп куя тиз генә. Безнең өйдә иң куркыныч «җанвар» – тапочка. (*Көлә.*)

Улыгыз белән сезнең яшь аермасы 50 яшь? Зур аерма сиздерәме? Хәзерге үсмерләрне аңлап бетереп буламы?

– Яшь аермасы зур булу әллә ни тәэсир итмәде кебек. Яшьләр газетасында эшләвем, хәзергә кадәр яшьләр сәясәтендә кайнап яшәвем дә ярдәм итми калмагандыр. Ул аерма сизелсә, Лёша миңа ачылмас иде. «Әни, әйдә, сөйләшеп ятыйк әле», – ди ул. Без аның белән шулай сөйләшергә яратабыз. Хәзер үсмерләр үзләре дә, кызыксынулары да башка. Бәлки, мин бүгенге тормыш вазгыятендә яшәр өчен улыма дөрес тәрбия бирмәгәнмендер дә. Башканы да күрсен дип, интернеттан да чикләмим. Әмма бик ышанам: без анда көчле рух тәрбияли алганбыздыр. Каршылыкларга каршы тора алыр дип өметләнәм. Әгәр сынса, бу минем өчен иң зур фаҗига булачак...

Римма Атласовна, хәзер үсмерләр безгә караганда да күбрәк белә. Алар каршында абруйны ничек саклап калырга соң?

– Алардан күбрәк белергә. Башка юл юк. Әмма нидер белмисең икән, моны танырга, сорарга оялмаска. Ул рәхәтләнеп аңлатачак. Мин дә сорыйм. Ул аңлаткач: «Молодец, горурланам», – дим. Бу сүзне бик еш кабатларга кирәк. Бәлки, ул аңа лаек та түгелдер, шуңа да карамастан. Кочаклау, назлау, үбеп алу – даими булсын. Чөнки балалар, ә үсмер вакытта бигрәк тә, әти-әниләренең үзләрен яратуына шикләнәләр. Игътибар итсәгез, кечкенә балалар, гел син мине яратасыңмы, дип сорый. Үсмерләр ул сорауны бирмәсәләр дә, күңелләрендә тумый калмый. Алар безнең яратуны тоеп, горурланып яшәргә тиеш.

Үсмерләрне тәрбияләргә соң түгелме?

– Кешенең холкы 14 яшькә кадәр салына. Эмоциональ һәм психологик нигезе дә формалаша. Шуңа күрә үсмерлек чорына кадәр биргән тәрбиягә төзәтмәләр генә кертеп буладыр. «5 яшькә кадәр бала – хан, 14 яшькә кадәр – хезмәтче, 18 яшькә кадәр – дошман, аннан соң – дус», – ди японнар. Мин, әлбәттә, балаларның хезмәтче булуына каршы. Бу вакытта да аларга теләктәшлек, ярдәм бик кирәк. Бала дошманга да әйләнмәсен иде инде ул. Җитмәсә, үсмерлек вакытында ата-аналар абруй булудан туктый, яшьтәшләр фикере өстенлек ала башлый. Ата-ана өчен ун тапкыр мөһимрәк чор бу. Бала алдында үз бәяңне югалтмау мөһим. Юкса син аңа дус була алмаячаксың. Гомер буе әни булып кына калачаксың.

Без балалар алдында үзебезне еш кына гаепле итеп хис итәбез: яратуымны биреп бетерә алмадым, вакыт табып бетерә алмадым, тәрбия бирә алмадым.... Сез – әни булудан тыш, җәмәгать эшлеклесе, мөһим вазыйфада. Ул хис сездә бармы? Булса, аны ничек компенсациялисез?

– Иркәләп инде. Хәтта артык та булды бугай ул иркәләү. *(Көлә.)* Киемен дә алып бирдек, сәяхәтләргә дә алып бардык... Җитди итеп әйтсәк, бала белән якын булу өчен тәүлегенә 10 минут булса да аның белән утырып сөйләшергә кирәк, диләр. Ә мин үземне артык битәрләмим. Лёша бик бәхетле бала дип саныйм. Без аңа дөньядагы иң мөһим әйбер – гаилә җылысын бирдек. Аның гаиләсе бар! Ул аны аңлый. Ул – картлык көнебездә безгә су бирәсе кеше, психология фәне әллә ни өметләнмәгез дисә дә. «Сезнең картлыгыгыз матур булсын өчен тырышачакмын», – ди инде. «Егор Крид кебек җырчы-блогер булам», – ди. Треклар яздыра. Хәтта үзенең фанатлары да бар. Әмма һәр консерватив әни кебек үк, мин дә аның блогерлык белән мавыгуы бетәр, тормыш өчен кирәкле һөнәр сайлар дип уйлыйм. Бик тә журналист итеп күрәсем килә.

Улыгызга киләчәк тормышында ярдәм итәчәк иң кыйммәтле киңәшегез?

– Яхшы күңелле, кешелекле булырга өйрәтәм! Хәзер бит Z буыны яшьләре башка хисләр белән яши. Бәлки юкка өйрәтәмдер. Әмма башкача булдыра алмыйм. Баланы бит үз үрнәгеңдә тәрбиялисең.



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Фото: Анна Арахамия

PRESSA

УЛЫМА РӘХМӘТ



Алсу
ШАКИРОВА

**Барысы да 2009 елда башлана.
Беренче баласын – газиз улын көтеп узган тугыз айлык йөклелек чоры тәмамланып килә. Дәлия Гайнанова бала табу өстәлендә. Баланың башы зур, булачак әнинең оча сөяге тар, өстәвенә, кендек бавы сабыйның муенына өч кат чорналган. Дәлиянең баланы ярып алулары турында үтенүләрен кире кагып, үзенә таптыралар...
Тимур нибары 1 балл белән туа. Аппаратлар ярдәмендә генә сулый алган сабый янына җиденче көнне мулла чакырталар. Коръән сихәте белән шул көнне бала беренче тапкыр үзе сулыш ала. Тимурның бу дөньяда зур эшләр башкарасы була әле...**

Тарттырылган кыл

Тормышының иң авыр көнен искә төшерә Дәлия ханым... Ханым дип әйтергә тел дә әйләнми. Яшәү көче ташып тора, тормыш ямен югалтмаган, чая, гел елмаеп йөри – ять-яшь кыз баладан бер аермасы да юк кебек. Барлык уңышлары, яулаган үрләре, алда көткән биеклекләре улы Тимур бәрабәренә булганын хәзер аңлый инде ул. Ә ул вакытта... Язмышының бу кискен борылышын кабул итәргә теләмичә, озак сыкрарга туры килгән яшь әнигә. Зур сынаулар узган, сабыр, нык рухлы, сынмассыгылмас Дәлия Илгиз кызы бүген – Казан шәһәре Думасы депутаты, мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләрнең гармонияле үсешенә юнәлтелгән «Бар да балалар өчен» автономияле коммерцияле булмаган хәйрия оешмасының гамәлгә куючысы.

Тимурның туган көненә әйләнеп кайтабыз.

– Бала тапканнан соң үзем дә аңламаслык ниндидер бер саташу белән яшәдем. Шок хәлендә идем. Шул мизгелләрне тагын бер тапкыр кичердем, яңадан бала таптым сыман, психологик халәтем шундый иде. Берниндн дарулар да мине ул хәлдән айныта алмады. Минем белән бер палатада ятучы кыз, куркып, үзен икенче палатага күчерүләрен сорады. Әйе, мин хәтта үз-үземнән курка идем. Башыма нинди уйлар килгәнен үзем генә беләм... Яшисем килми иде... Өченче көнендә генә елый алдым. Бала үзе суларга сәләтсез дип, аны ясалма аппаратлардан өзәргә рөхсәт сорап, кул куйдырырга керделәр... Мин үз баламны үтерергә җыенмыйм, теләсәгез нишләтегез, дәвалагыз, дидем.

Коръән укыганнан соң, яшәүне сайлап, беренче сулышын алган улы белән Дәлия ханымны балалар хастаханәсенә күчерәләр. Аннары икенчесенә, өченчесенә, тагын әллә ничәнчесенә... Ә табиблар һаман берниндн диагноз куя алмый.

– ДЦП диагнозы тумыштан куела дип уйлый идем. Юк, бала башта башкалардан берни белән дә аерылмый икән. Үскән саен гына тайпылышлар сизелә башлый. Баш мие белән аяк-куллар арасында бәйләнеш булмау аркасында тиешенчә хәрәкәтләнә алмый. Шуңа күрә мускуллар атрофиясе, хәрәкәт параличы башлана. Шул вакытта гына нидер дөрес түгеллеген аңлыйсың. Табиблар, рентгеннан карап, баш миенә зыян килгәнлеген күрсә дә, нәтиҗәсе ни дәрәҗәдә булачагын фаразлый гына ала. Баш мие шундый әйбер икән ул – кайбер очракта яртысы диярлек үлгән булырга мөмкин, ә баланың үз-үзен тотышында бу берничек тә сизелми: ул уйный, йөгерә, үсә. Киресенчә, баш миенең кечкенә генә икенче бер өлешенә зыян килеп, баланың сәламәтлегенә тирән йогынты ясый ала.

Тәүлекнең һәр минутын Тимурына багышлый яшь әни. Беркем белән сөйләшәсе, аралашасы килми. Шуңадырмы, эштән кайткан иренә: «Ни хәлләрең бар?» – дип, каршына утырып сөйләшерлек көче дә калмый. Ире турында гына түгел, үзе турында да оныта. «Тарттырылган кыл кебек идем», – дип искә ала ул чакларны Дәлия Илгизовна. Нәрсә булса да, баласы өчен ул иң беренче ашыгыч ярдәм күрсәтүче дә бит әле. Эпилепсия өянәге башланганда ирен тынычландырсынмы, улын кайгыртсынмы? Шуңа күрә бу авыр йөккә тулысынча үзе җигелергә хәл итә Дәлия. Газиз әнисе гел янәшәсендә була. Иң якын кешесе дә, рухын ныгытучы да, ярдәмчесе дә, «Син булдырасың, кызым!» – дип, көч биреп торучысы да, иң авыр чакларында терәге дә – әнисе Люция ханым.

ГОСТка туры килмәгән балалар

Ә Тимурда ДЦПның катлаулы формасы... Үсә барган саен, мәшәкате дә арта. Иң гадиеннән генә башлыйк әле. Баланың селәгәе агып, киемнәренең изүе тиз юешләнә. Үзенчәлекле балаларга туры килгән күкрәк япмасын табуы гына да ата-аналар өчен зур проблема.

– Гади балалар өчен булганнары безгә туры килми, тиз юешләнеп бетә. Кем ничек кенә көрәшми моның белән. Чүпрәк, микрофибра, хәтта памперс элеп куючылар да бар. Варшавага баргач та эзләп карадым махсус япманы, анда да шулай ук тилмерә икән әниләр.

Мәсьәләне үзе хәл итәргә алына Дәлия ханым. Тукыма кибетендә шешәдән су тамызып карап, туры килгән тукымаларны сайлый. Юеш үткәрәме, юкмы... Сайлап

алган плащевка тукымасын күтәреп ательега бара. Башта япманы өчпочмак формасында тектерә. Танышларына, дусларына да өләшә, ошаталар. Ләкин Дәлиянең үзенә ошап бетми. Өчпочмак тар бит. Ә авыру бала башын туры тотмый, янга таба да, алга да ия – селәгәй җилкәләргә, күкрәккә ага. Япманы озынрак итеп тә, түгәрәгрәк итеп тә тектереп карый. Соңыннан гына иң отышлысы бишпочмак формасы дигән нәтиҗәгә килә. Бу бит әле бер күкрәк япмасы гына!

Аннары Дәлия бу эшкә чынлап торып тотынырга була. Мөмкинлекләре чикле балалар өчен махсус киемнәр тегү белән моңа кадәр бер кеше дә шөгыльләнмәгән. Ә алар шулкадәр кирәк! Нишләп әле бу эшне киңрәк масштабка чыгармаска? Тәвәккәлли: берсе артыннан берсе киемнәр, бодилар тектерүгә күчә. Моның өчен Тимурның коляскасын сатарга туры килә...

– Коляска сатып, тукымалар алып кына эш бармаганына тиз төшенергә туры килде. Үз сызымнарым белән төрле тегү фабрикаларына барып карадым – заказыма алынырга теләмиләр. Әлбәттә, аларга ГОСТ буенча гадәти балаларга күпләп тегү уңайлырак. Ә минем заказым – берничә данә генә. Конструкторлар бөтен сызымнарымны сызып ташлады. Теккәннәре дә кайсы туры килә, кайсы юк. Беренче киемнәрне социаль челтәрләр аша сатарга тырышып карадым. Ләкин моңа да осталык кирәк икән. Бәхетемә, мине киләчәктә иң зур ярдәмчем булачак Лариса Вознесенская белән таныштырдылар. Киң күңелле, мәрхәмәтле дустым шул вакытта бер ай бушка эшләргә риза булып, миңа ярдәм кулы сузды. Беренче клиентлар да табылды.

Соңрак Дәлия ханымга икенче бер уй килә. Тегелгән киемнәрне мөмкинлекләре чикле балаларга бушлай өләшә алырлар иде бит! Дуслары ярдәме белән тукымалар сатып ала ул. Инвалид балаларны үстерүче әниләрне балалары белән төшке ашка чакыралар, бәйрәм оештыралар, бушлай киемнәр өләшәләр. Шул көнне яңа хыял туа – Татарстандагы гаиләләрне генә булса да бушлай кием белән тәэмин итәргә иде!

Эшчәнлек киңәйгән саен, кәгазь эше дә арта: хатлар, гаризалар, документлар тутырырга кирәк. Болар янына исәп-хисап эшләре дә өстәлә. Ул вакытта тагын бер тугры дусты – Эльмира Яруллина ярдәмгә килә. Дәлия ханымның сеңлесе Дилә дә теләктәшлек күрсәтә, шулай дүртәүләшеп тотыналар. Һәркем үз бүлеге өчен җавап бирә. Кызганыч, эшләре алга бармый. Берсе юрист, икенчесе икътисадчы, геодезист, җырчы... Нинди тегүче чыксын алардан?

– Инновацияләр үзәген җитәкләгән дустыбыз Антон Деганов НКО (коммерцияле булмаган оешма) ачарга тәкъдим итте. Бу эшчәнлегегез белән грантлар ала аласыз бит, диде. Безнең өчен тагын бер ят әйбер булса да, өйрәнеп, тәҗрибә туплап грантлар белән эшләргә тотындык. Беләсезме, бер гаризабыз да игътибарсыз калмады! Шул вакытта дөрес юлдан баруыбызны аңладык. Грант акчаларына эшчәнлекне киңәйттек: әти-әниләргә психологик ярдәм күрсәтүне дә оештырдык. Бу юнәлешне инвалид бала тәрбияләүче әниләр аеруча ошатты. Чөнки аларның һәркайсы кайчандыр шок, стресс кичергән. Бу халәттән



Фото: Анна Арахамия

Безнең киемнәр – бу гаиләләр өчен коткару чарасы.



■ Дәлия Гайнанова үзенең уң кулы – Лариса Вознесенская белән.



■ Әнисе Люция ханым һәрвакыт ярдәмгә әзер.

вакытында дөрес итеп чыга белмәү аркасында аларга бүген дә бик авыр – моны үземнән беләм. Озакка сузылган депрессия яшәргә комачаулый, алар үзләренә йомыла, эмоцияләрен чыгарырга курка. Психолог ярдәмендә нәкъ шушы проблемалары өстендә эшләделәр. Яңа очрашуларны әле дә түземсезлек белән көтеп алалар.

Тимурга дигән күкрәк япмасыннан башланып, зур хәйрия эшенә күчкән җитештерү үзәге буйлап атлыйбыз. Дивар буйлап тезелеп киткән киштәләрдә инвалид балалар өчен махсус киемнәр. Аларның төрлелеге шаккаттыра. Барысы да уйлап эшләнелгән. Куллары тураймаган ДЦП диагнозлы ябык балалар өчен тулысынча сүтелә торган комбинезоннар; кул очлары, бармаклары эшләмәгән балалар өчен магнит белән генә үзе ябышып төймәләнә торган костюмнар; аутист балалар һәм деменция белән авыручы өлкәннәр өчен арттан төймәләнә торган киемнәр; куллары, аяклары кыскарак, тәннәре түгәрәгрәк Даун синдромы булган балалар киемнәре; Илизаров клиникасында операция ясаткан балалар өчен ыштаннар; тагын күкрәк япмалары, курткалар, жилетлар, аяк киемнәре... Мөмкинлекләре чикле балаларның һәр үзенчәлеген исәпкә алып иҗат ителгән (нәкъ шулай!) алар. Һәр проблеманың чишелеше – шушы киштәләрдәдер кебек. «Ә бу киемнәре булмаган балалар нишли соң?» – дип кызыксынам. «Нишләсеннәр, өйдә утыралар», – ди Дәлия Гайнанова.

– Бәләкәй чакта була әле ул, ә менә зур баланы киендереп урамга алып чыгар өчен җиде кат тир түгәргә кирәк. Хатын-кызның моңа көче дә җитми. Тураймаган кулларга ни рәвешле өс киеме киертергә соң?! Баласын өйдә утыртудан башка чарасы калмый әниләрнең... Бик күп кайтавазлар алабыз – димәк, кирәкле эш белән шөгыльләнәбез.

Киемнәрнең тамгасына игътибар итәм. «GT Dress» дип язган биркаларның да үз тарихы.

– Бу махсус киемнәрне чыгара башлагач, аларга исем уйларга керештек. Тегеләй дә, болай да куеп карыйбыз. Дустымның ире Ренат Яруллин «GT» исеме белән атарга тәкъдим итте. Соңыннан белдек – чит илдә чыккан машинаның камилләштерелгән моделен дә «GT» дип атыйлар икән. Ә минем өчен бу хәрефләр бөтенләй башка мәгънәгә ия – Гайнанов Тимур! Безнең киемнәр дә – камилләштерелгән версия бит! Исеме шулай хәл ителде.

«Сез булышасыз, диләр»...

Мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләрнең гармонияле үсешенә юнәлтелгән «Бар да балалар өчен» автономияле коммерцияле булмаган хәйрия оешмасы төрле хәйрия фондлары белән эшли. Кызларның хезмәте турында илкүләм ишетеп беләләр, чит илләргә дә юл ачыла. Җитештерүне Төркиядә дәвам итәргә дигән тәкъдим килә хәтта. Ләкин алар үзебезгә – Татарстанга да бик кирәк шул! Эшмәкәрләргә ярдәм итү фонды аша теләктәшлек күрсәтелә: дәүләт ярдәме белән товарны сертификациялиләр, сайт, социаль челтәрләр алып бару өчен акча бүлеп бирәләр. Ниһаять, моңа кадәр төрле фабрикалар белән эшләргә мәҗбүр булган оешманың үзенә тегү машиналары алалар!

– Шул вакытта Казан шәһәре мэры Илсур Рәис улы Метшин бик зур ярдәм күрсәтте. Менә шушы бинаны бирде ул безгә. «Монда фуралар белән киләчәкләр, мондый киемнәр регионнарда юк», – дип канатландырды. Үзебезне тагын да кирәклерәк итеп тойдык. Эшләр җайга китте. Бу бина хәтта үзенчә бер лабораториягә әйләнде. Төрле авырулар бар бит: ДЦП, Даун синдромы, аутизм... Балаларны монда алып килеп, аларга кидертеп карап, өлгеләр ясый башладык. Моңа кадәр кая гына барып ялынсак та, безнең киемнәрне тегүне иң ахырга калдыралар иде – гел чиратның теге башында тордык...

Изгелек җирдә ятмый. Иҗтимагый эшчәнлеге Дәлия Гайнанованы башка яссылыкка күтәрә – аны Казан шәһәре Думасы депутаты итеп сайлыйлар. Күңелен биреп башлаган эше өчен моның никадәр мөһим булуын Дәлия ханым үзе дә яхшы аңлый.

– Мин хәзер инвалид балаларны, аларны тәрбияләүче ата-аналарны борчыган бөтен мәсьәләләрне җитәкчелеккә турыдан-туры җиткерә алам. Кайвакыт игътибарлары җитеп бетмәүдә җитәкчелек тә гаепле түгел. Чөнки алар проблеманы без күргән кебек күрмиләр, теорияне генә беләләр. Көндәлек мәшәкатьләр алар күзлегенә эләкми. Иң беренче эш итеп төрле авыру балаларны тәрбияләүче әти-әниләрне Илсур Рәис улы белән очраштырдым. Анда яңгыраган сорауларны һәм аларның чишелешен Илсур Метшин тулысынча күтәреп алды, хуплады. Эшкә дә бик тиз тотынды шәһәр җитәкчелеге.

Район башлыклары белән берлектә мөмкинлекләре чикле балалар үстерүче әниләрнең уңай мохитне тикшерүләре дә – Дәлия Илгиз кызы башлаган бер эш. Даруханәләргә керер өчен ясалган баскычларны гына исәпкә алсаң да, аларның күбесенә коляска белән менә торган түгел. Даруханәгә инвалид бала тәрбияләүчеләр генә түгел, гомумән, балалы әти-әниләр, пенсионерлар ешрак йөри. Район җитәкчесенә бала утырган колясканы этеп шул баскычлардан менәргә тәкъдим итәләр. Уен эшмени – колясканы әйләндереп каплый язгач, мәсьәләгә бөтенләй башкача карый башлыйсың...

– Кемнедер гаепләр өчен эшләнми бу. Таләпләр дә үзгәреп тора бит, элек закон буенча шулай да яраган. Закон үзгәрә, ә корылмалар, биналар шул килеш кала. Шуңа күрә яңа биналарның таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерү белән дә шөгыльләнәм. Европа бу өлкәдә алга киткән. Без әле беренче адымнарыбызны гына ясасак та, инде шактыйга ирешергә өлгердек. Мөмкинлекләре чикле балалар белән эшләүдә көчле команда формалашты. Алар белән таулар күчерергә була.

Дәлия ханымның төп таянычлары – Казан шәһәре мәгариф идарәсе башлыгы Ирек Ризванов һәм Башкарма комитет җитәкчесенең социаль өлкә мәсьәләләре буенча урынбасары Гүзәл Сәгыйтова. Башкарылган бер генә эшен дә алардан аерып карау мөмкин түгел, ди Дәлия Илгизовна.

– Эшчәнлекнең күп өлеше белем бирү өлкәсенә кагыла. Аутист һәм начар ишетүче балаларны безнең белем бирү системасына яраклаштыру буенча эш алып барыла. Әти-әниләр теләгән дә исәпкә алырга кирәк: кайберәүләр андый балага аерым сыйныфта укырга кирәк дип саный, икенчеләре баланы башкалар белән бергә укыту яхшырак, ди. Шуңа күрә сайлау мөмкинлеге булырга тиеш. Дөньяви тәҗрибәне дә исәптә тотарга тырышабыз. Инвалидлар белән яшәүгә дөрес яраклашырга кирәк, аларга да безнең белән яшәве уңайлы булсын. Кызганыч, бер әти-әни дә гомерлек түгел. Үзенчәлекле балалар өчен куркынычсыз фатирлар булдырырга кирәк – алар үзләре яшәргә өйрәнергә тиеш. 18 яше тулган балалар моңа аеруча мохтаҗ. Мөмкинлеге чикле бала махсус һәм югары уку йортларына керә алмаган очракта, аларның көнкүрешен кызыклы итеп оештырырга, аларны үстерү чарасын табарга, шөгыльле итәргә кирәк. Шул уңайдан бик күп Мәдәният үзәкләре балалар өчен үз ишекләрен ачты, анда бушлай түгәрәкләр оештырылды. Спорт залларын ачу мәсьәләсен дә хәл итәргә алындым. Таяныр кешеләр булганда барысы да безнең көчтән килә торган әйберләр.

Инвалид бала тәрбияләүнең нәрсә икәнен аңлагангамы, проблемаларны чишү юлларын таба белгәнгәме, депутат булгангамы... Дәлия ханымга төрле социаль челтәрләр аша көн саен дистәләгән хатлар, сораулар килә. Лифт, мәктәп, коляска проблемалары белән турыдан-туры мөрәҗәгать итәләр. «Сез булышасыз диләр», «Сезгә язарга куштылар...» – дип сүз башлаган кешеләргә ничек ярдәм итмисең? Казанның 49 нчы мәктәбендә гражданнарны кабул иткән вакытта директор бик яхшы бер бинаның буш булуын әйтә. Файдалы эшкә кулланырга иде шуны, ди. Дәлия Гайнанова бу бинаны Илсур Метшинга күрсәтә. Мөмкинлекләре чикле һәм гади балалар өчен ачылган вакытны файдалы уздыру, ял итү үзәге – менә шул очрашуның нәтиҗәле үрнәге. Балалар чүлмәкчелек, робот техникасы, җитештерү, слесарьлык эше белән шөгыльләнә хәзер биредә.

– Шәһәр Думасы сессиясендә чыгыш ясаганда: «Беренче тапкыр улым Тимурга рәхмәт әйтергә телим», – дидем. Балам шундый булып туганга күрә бүген меңләгән гаиләләргә, балаларга ярдәм итә алам. Эшемне бик яратып, күңел биреп башкарам. Шуңа күрә арымыйм да, ахрысы.

«Дәлия – курку белми торган кыю кеше, шул дулкында гел алга бара», – ди коллегасы Лариса. Шул сыйфатлары аңа тагын бер куркуын җиңәргә ярдәм иткәндер, мөгаен. Инвалид бала тәрбияләүче күпчелек хатын-кызлар яңадан бала табудан куркып кала, бөтен гомерләрен авыру балага багышлый.

– Табибым бик яхшы иде. «Гайнанова, юләр булма. Гомереңне бер балага гына багышлама, тагын берне тап», – дип торды. Бу минем дә татлы хыялым иде шул... Тимур хисләрен күрсәтә белми, аңламый. Ә минем баламның җылы кочагын, муеныма сарылган бәләкәй кулларының җылысын тоясым килә, «Әнием» диеп яратыласым килә... 2013 елда икенче балам, хыялым – кызым Ариана туды. Йөклелек чорым куркуда, стресста узса да, Аллаһка шөкер, ул сау-сәламәт.

Башка хыяллары да дөньяны колачларлык. Бүген Дәлия Гайнанова башлаган бренд Россиядә генә түгел, Германиядә, Беларусьта, Кыргызстанда, Молдовада таныш. Калган илләрнең дә әлеге исемлеккә элгүе – вакыт эше. Димәк, алар турында ишетергә генә өлгермәгәннәр. «Бераз тәвәккәллек кенә җитеп бетми», – дип елмая ул үзе.

– Мин бик күп сәламәт балалы хатын-кызлардан яхшырак, бәхетлерәк яшим бит дип сөенәм. Бәхетле булу – синең кабул ителгән карарың ул. Нинди генә шартларда яшәсәң дә... Һәр авырлыкның, һәр мәшәкатьнең чиге бар, ул барыбер хәл ителәчәк. Һәм һәрвакыт синең файдага хәл ителәчәк. Мин шуңа ышанам.

Ярдәм күрсәтергә теләүчеләр өчен «Барысы да балалар өчен» автономияле коммерцияле булмаган оешманың (АНО «Все для детей») банк реквизитлары:
Банк Филиал «Нижегородский» АО «Альфа-Банк»
Р/счет 40703810429070000113
Кор/счет 30101810200000000824
ИНН 7728168971 / КПП 770801001 / БИК 7728168971





Гөлнур САФИУЛЛИНА

– Проект ни өчен «28 күзәнәк» дип аталамы? Барысы да бик гади... Әйтик, олы кешегә оекбаш бәйләү өчен 40–42 күз җыярга кирәк. Ә монда нибары 28 дә җитә. Беләсез инде, ул балалар шулкадәр кечкенә – кайберләре әтиләренең учларына да сыеп бетә. Бәйләгән әйберенә карап кайчак аптырап та торасың: «Кечерәк булмасмы, ярармы икән?» – дисең... Ә аннан фотосурәткә төшереп җибәрәләр – 1 килограммнан да азрак булып туган балага ул киемнәр зуррак та булып күренә әле...

28 КҮЗӘНӘК

«Җитлекмичә туган балалар белән эшләүче табиб-неонатолог турында фоторепортаж әзерләгән чагым иде. Кинәт сабыйларның берсендә оекбаш күреп алдым. Зәңгәр төстәге йон җепләреннән бәйләгән оекбаш! Күңелемдә, әлбәттә, шунда ук сорау туды: «Нигә кидердегез аны?» – дим. Баксаң, бәйләгән әйберләр җитлекмичә туган бу балаларга тизрәк тернәкләнергә ярдәм итә икән. Моны аңлаган табиблар ул оекбашларны үзләре үк бәйли дә икән! Ел саен безнең республикада 450 мең бала туа, һәм шуларның 4–12 проценты вакытыннан алда дөньяга килә: авырлыклары мең граммга да җитми. Менә никадәр оекбаш кирәк! Табибларның эше дәвалау, ә оекбаш бәйләргә генә без дә булдыра алабыз дип уйладым», – дип яза казакъ журналисты Карла Нур. 2012 елда Казакъстанда «28 күзәнәк» («28 петель») дигән проектны ул оештыра: үз тирәсенә волонтерлар туплый – алар җитлекмичә туган сабыйлар өчен киемнәр бәйли башлыйлар. Журналистның баш-

лангычын Казакъстанның 15 шәһәрендә күтәреп алалар! Аннан Латвиядә, Үзбәкстанда, Азәрбайҗанда, Кыргызстанда, Украинада...

Россия бу проектка 2017 елның җәендә кушыла. Мәскәү, Санкт-Петербург, Саратов, Омск, Красноярск, Краснодар, Севастополь... шәһәрләрендә клублар ачыла. Мондый ярдәм һәркайда бик кирәк һәм шундый көтелгән булып чыга! Ул клубларга кергән волонтерларның барысы да диярлек, әлбәттә, хатын-кызлар: төрле оешмаларда эшләүче хезмәткәрләр, студентлар, пенсионерлар, хуҗабикәләр... Республикабызның перинаталь үзәкләрен бәйләгән әйберләр белән бушлай тәэмин итеп торучы андый клуб безнең Казанда да бар. Алай гына да түгел, волонтерларның бу хәрәкәте инде Татарстан районнарына, аның авылларына да барып җитте. Әйтик, менә Сабага. Районның «Көмеш волонтерлар»ы әлеге клубка ярдәм итәргә бик теләп кушылдылар.

– Гөлнара Фәтхрахманова безнең Сабага өч ел элек килен булып төште. Барысы да ул кайткач башланды... Аңарда идеяләр ташып кына тора! Артыннан язып кына өлгер... Социаль проектлар оештыру эшендә Мәскәүдә туплаган тәҗрибәсе дә бар.

Казанга эш белән барган чагым иде. Гөлнара шалтырата: «Менә шул урынга кереп, җепләр алып чыга алмассыңмы?» – ди. Мин әле бу кадәр җепнең нигә кирәген дә тәгаен генә белмим... Кибеткә барып җиткәч кенә ул җепләр өчен түләргә спонсорын да таптык. Барысы да шундый тиз хәл ителде! Баксаң, Гөлнара инде үзе 20 меңлек җеп алып кайтып куйган икән. Инде бу эшкә волонтерларны җәлеп итәргә кирәк иде...

Саба районы мөхтәсибәтенең оештыру эшләре буенча җитәкчесе Гүзәл Шәрифуллина дөрес әйтә: һәр иҗтимагый эштә башлап йөрүче кирәк. Үз артыннан ияртүче, рухландыручы! Шул ук вакытта идеяне күтәреп алучылар – аны тормышка ашыручылар да бик кирәк. Гүзәл кебекләр. Гөлнара – читтән кайткан кеше, ул Сабада берәүне дә белми, ә Гүзәл шушында туып-үскән, аңа бар да якын, таныш.

Проектка иң беренче булып Сабадан Зөбәрҗәт апа Ярмөхәммәтова

Һәр бәйләгән кием янына баланың әнисенә теләкләр язып салырга да онытмыйлар.

кушыла – җитлекмичә туган балалар өчен сигез комплект бәйли!

– Бәйләргә гомер буе яраттым, – ди ул. – Ә монда бигрәк тә тырышып бәйләдем. Олы балабыз авыру булды. Хастаханәләрдә бик озак яттык – сигез операция генә кичердек. Бер елны тоташ тугыз ай хирургия бүлегеннән чыкмадык. Операциягә әзерләнәбез генә, бала авырып китә... Бу бәләкәчләрнең әниләре кебек үзәкләрем өзелеп, реанимация ишек төпләрендә дә байтак басып торырга туры килде миңа. Сөтемне савып алып менәм – алмыйлар. Димәк, баланың хәле тагын кыл өстендә. Идән юучы бер хатын: «Нәрсә дип тилмерәсең?! Монысын калдыр да, сәламәт балалар бар бит – берәрсен алып кайтып кит», – дигән иде. Шул көннәр кабат исемә төште. Ул сынаулардан соң тормышка гел рәхмәтле булып яшәдем...

Әлеге балалар өчен бәйләүнең үз үзенчәлекләре, үз тәртибе бар – районыбыз авылларына барып мастер-класслар да үткәреп йөрдем. Гади биш энә белән бу киемнәрне бәйләү шактый авыр – күзләр энәдән шуа да чыга. Башка берәр җае юкмы икән дип эзләнә торгач, тефлон энәләр таптым. Кызлар аннары ул энәләрне күпләп кайтартып, райондагы бөтен бәйләүчеләргә дә таратты...

Алга китеп булса да әйтим, Сабада бүген ашыгыбрак туган нәниләргә киемнәр бәйләүче ике йөзгә якын волонтер бар! 69 гына хуҗалыклы Утар авылында, мәсәлән, волонтерлар кырык икәү – димәк, анда яшәүче хатын-кызларның 70 проценты шушы хәрәкәткә кушылган. Ә Явлаштау авылында... Кызлар үз артларыннан бу кадәр кешене ничек ияртә алган соң? Икәү утырып: «Халыкны ничек кузгата алабыз икән?» – дип сөйләшкәндә, Гүзәл үзенең ватсапта районның абыстайлар группасында торуын искә төшерә. Ә анда – 64 абыстай. Шуларга яза... Иң беренче булып Явлаштаудан Тәслимә апа Сабирҗанова җавап бирә. «Өйрәтсәгез, бәйләп карарга телибез», – ди. Гөлнара белән Гүзәл, капчык-капчык җеп күтәреп, Сабадан 18 чакрымдагы шул авылга китәләр. Ике көннән Явлаштаудан яңадан шалтыраталар: «Җеп бетте, китерәсезме, тагын бәйлибез!» – диләр... Җепләр калдырырга Утар авылына төшәләр, мәчет тулы хатын-кыз каршы ала (Кечкенә генә авыл 90 га якын комплект бәйләп тапшыра!)

Явлаштау авылы волонтерлары белән дә мәчеттә очраштык. Сүзгә кыска алар:

– Изге теләкләр тели-тели бәйләдек, үсеп кайтсыннар, әти-әниләренә игелекле бала булсыннар дидек...

– Бер комплектка оекбаш, башлык, жилет һәм плед керә. Күбрәк оекбаш кирәк, кер юу машинасына салабыз да, гел бер пары югала дигәннәр... Иң авыры – оекбаш бәйләү. Бигрәкләр дә бәләкәй бит – шырпы тартмасы кадәр генә. Җиде күзәнәкнең берсен алам дисәң, икенчесе төшә дә китә. Тефлон энәләр алганчы аптырадык. Оекбашларны йөз парга җиткерәбез дигән идек, артып та китте әле. Бер сантиметр җепне дә әрәм итмәдек – кайсыбызда нинди җеп калган, кушып-кушып бәйләдек...

– Онытылып бәйләдек, кайсы көнне сәгатькә карыйсың – төнге унике тулган! Кул эше хатын-кызны шулай тынычландыра бит ул...

– Бер күзәнәк алган саен үзебезгә дә савап булсын дип теләдек...

– Тиз бәйләнә, шунда ук күзгә күренә. Күңел рәхәтләнеп китә, тагын бәйлисе килә...

– Мәчеттә дә җыелып бәйләдек, бер-беребездә кич утырып та...

– Өйдәгеләр нинди сүз әйтсен?! Малларны карыйбыз, ашарга пешереп куябыз... Бик кечкенә икән, дип, бәйләгән әйберләргә алар да аптырады. Курчакка киертеп күрсәттек...

– Миңа хәзер 42 яшь. Әнинең безгә бер тапкыр да оекбаш бәйләп кидерткәне булмады. Ике эштә эшләде – вакыты юк иде аның. Ә бу балаларга бәйләде! Шулкадәр яратып, чын күңелдән эшләде. Намазын укый да, тизрәк бәйләүгә тотына...

Фото: Анна Арахамия



Гөлнара ФӘТХРАХМАНОВА

– Күпме проект арасында иң оешканы – шушысы. Саваплы булгангадыр... Кешеләрне берләштерер, дуслаштырыр өчен бер изге эш кирәк. Бу проект ул максатка иреште дип уйлыйм. Минем бит үземнең дә моңарчы Сабада, иремнән, кайнанамнан һәм Гүзәлдән кала, танышларым юк иде. Ә хәзер кая барсам да, елмаеп каршы алалар... Иң беренче ярдәм итүче Саба мөхтәсибәте булды: имам-мөхтәсиб Айнур хәзрәт Әхмәтовка зур рәхмәт. Кешелекле кешеләрнең берсе ул... Айгөл Бариева, Җәмилә Сәлахова, Альбина Фазлыева, Алина Азаталкина кебек блогерларның да ярдәме сизелерлек булды.

Казанда бу хәрәкәтне Анна Бажанова җитәкли. Беренче тапкыр аңа мең ярым данә бәйләгән әйбер илттек. Төркиядән, Әтнә районыннан, Питрәч районының Шәле авылыннан да кушылдылар безгә... Машинага чыгып утыргач, елыйм да елыйм. Ирем тәмам аптырады... Апалар кечкенә дип санаган бу эш зур игелеккә китерәчәк дип уйлыйм. Барысы да нияттән тора бит. Ул балалар үсеп җиткәч, безгә кемнәр ярдәм итте икән дип эзләячәкләр әле. Әниләре бит аңа бу хакта сөйләячәк. Бәйләү генә түгел бит әле: 200 хатын-кыз комплектлар бәйләсә, 500 гә якын кеше спонсор акчасы күчерде. 10 сумнан башлап 70 меңгә кадәр!

Һәр игелек синең үзеңә әйләнеп кайта. Проектка кушылгач сезнең белән берәр могҗиза булмадымы, дип апалардан гел сорыйм. Күп еллар элек бер авыру балага акча җыйдым. Банкка барып, шул акчаны күчереп чыгуга, Мәскәүгә эшкә чакырып шалтыратканнар иде...

– Утар авылында бер хатынның иртә туган оныгына шундый комплект киерткән булганнар. Рәхмәт йөзеннән, ул проектта берничә комплект бәйләгән...

– Жилетка, пледка бизәкләр дә бик кушасы килә, тик рөхсәт ителми! Бер кием дә 150 граммнан артмаска тиеш – бу балаларга шуннан артык авырлык ярамый...

– Бер-ике оекбаш булса да бәйләп карыйк, дип кенә тотынган идек. Моның кадәр зурга китәр дип уйламадык. Шул балаларның тормышларын саклап калырга булышабыз дигән ният ярдәм итте... Синеке күпме булды, дип бер-беребезгә язабыз. Линейка куеп, үлчәп рәсемгә төшереп җибәрәбез. Арабызда иң олысы Равилә апа иде – аңа 78 яшь тула...

Арада бер Равилә апа Халикова гына җитлекмичә туган баланың әни кеше өчен нинди зур сынау икәнен белә. Төпчек улы – бишенче баласы җиде айлык кына булып туа аның. Башкалары 5900 грамм булып дөньяга килә, ә монысы – нибары 1200. «Имезергә бирмиләр, ут астына тыгып куйдылар. Ундүрт көннән соң мине кайтарып ук җибәрделәр. Юллар юк, телефон кәнсәләрдә генә. Йөрәк әллә нишли... Шалтыратам да: «Бала исәнме?» – дип сорыйм... «Яшәмәс», диделәр инде авылда. Өйгә алып кайткач, бөтен авыл карарга йөрде. Ике баласы бар хәзер Рәфыйкның», – дип сөйли ул.

Кемдер: «Ә нигә ул балаларның әниләре үзләре бәйләми соң?» – дияргә мөмкин. Бу сорауга Гөлнара Фәтхрахманова болай дип җавап бирә:

– Берәү дә балам җитлекмичә туар дип көтми бит. Аннан ул көннәрдә яшь әниләрнең башка борчулары да җитәрлек була. Кемдер әле үзе дә бәйли белми... Ә чыбыкларга чорналып кювезда яткан балага дарулар гына түгел, нәкъ менә 100 процентлы йон җебеннән бәйләгән киемнәр дә ярдәм итүе инде бәхәссез. Беренчедән, ул, әлбәттә, тәндәге җылыны саклый. Пледны итәккә куеп бәйләгәндә, апалар: «Тезләребез гел җылыда тора», – диләр. Проектны башлаганнан бирле үземнең дә аяктан оекбашны салган юк... Икенчедән, аз гына чәнчеп торып, балага массаж да ясый: мондый баланың йокысы бик тирән була, кайчак ул суларга да онытa – бәйләнгән киемнәр исә балага суларга онытырга ирек бирми... Һәр бәйләгән киемне кер сабыны белән юып тапшырабыз. Кара төстән кала, барлык төстәге җепләрдән бәйлибез. Әниләрнең болай да авыр чагы: реанимациядә яткан баласы янына бик азга гына керә ул. Сабые өстендә ачык, якты төсләрдән бәйләнгән комплектны күреп, аның кәефе бераз булса да күтәрелсен, дибез. «Мин бит бу киемнәрне бирмәдем», – дип, әниләр башта аптырап кала, аннан, аңлаткач, бик сөенәләр ди. Әлбәттә, алар волонтерларга бик рәхмәтле...

Без әле сезгә уенчыклар бәйләвебез турында әйтмәдек. Аның үз тарихы бар. Даниядә яшәүче бер әни, сигезаяк рәвешендә уенчык бәйли дә, аны баласы янына кювезга куюларын сорый. Табиблар баланың хәле яхшыруына игътибар итә. Сигезаякның капшавычларына тотынган бала аны кендек бавы дип белә, үзенә куркыныч янамый дип саный икән. Аны тормышка бәйләп торган аппарат чыбыкларын да тынычлыкта калдыра. Шулай итеп, бу уенчыкларның да файдасы бар. Сабада яшәгәч, без аларны сигезаяк түгел, ә чыршы рәвешендә бәйләдек.

Проектта балаларны да катнаштырасы килгән иде: Саба «Иҗат йорты»-на йөрүче укучылар да бәйләде. Иң яшь волонтерыбызга нибары 11 яшь, ә иң өлкәненә – 87...

...Ел саен Җир йөзендә 15 миллионга якын бала 40 атна булганчы туа, бу – һәр унынчы бала дигән сүз. Күбесенең авырлыгы 500 грамм – 1 килограмм тирәсе. Дөньяның төрле почмагында яшәүче кешеләр бу сабыйларның гомерен саклап калу өчен 50 мең данәдән дә артык кием бәйләгән инде. «28 күзәнәк» клубына һәркем керә ала, хәтта бәйли белмәүчеләр дә. Кергәч өйрәнәләр! Өйрәнергә вакытыгыз юк икән, әлеге хәрәкәткә башкача да ярдәм итеп була – 100 процентлы йон җепләре алырга булышырга мөмкин. Әйе, оештыручы кызлар хаклы: зур гамәлләр кечкенә генә игелекле эшләрдән башлана.



БЕР КАРАСАҢ...

Марат
КӘБИРОВ,
язучы

Белмим, бу мәсьәләдә нидер әйтергә хакым бармы икән... Төгәл генә аңлатып та, хәтта аңлап та булмый аны. Кешене өйрәтү генә җиңел. Тик сез үзегезгә кулай дип тапсагыз кабул итәрсез, кирәкми дип уйласагыз, куллануга алмассыз, башкаларны гына өйрәтерсез. Бүтәннәрне өйрәтүдән дә рәхәт нәрсә юк бит ул.

Йокларга җыенасың, мәсәлән. Иртәгә әллә күпме проблемаң көтеп тора, күзгә йокы керми, башта мең төрле уй бутала. Менә шундый чакта түшәгеңә сузылып ятасың да аз гына вакытка үзеңне үлгән дип күз алдына китерәсең. Мин шулай итәм. Кайчагында.

Ә бит, бер карасаң, бу шаяру – шулкадәр җитди нәрсә. Бу дөньяда әллә күпме кеше кичен йокларга дип ята да иртән тора алмый. Һәм ул кеше син дә булырга мөмкин: һәркем гомер эчендә бер тапкыр үлә ич инде. Берәү дә аннан качып кала алмый. Шулай тиеш. Иртән бөтен дөнья йокыдан уянган чакта, мәсәлән, мин уяна алмаска мөмкинмен. Бер карасаң, бәхетле үлем инде: чирләп, үзең җәфаланып, кеше интектереп кемдер кулына карап ятасы түгел. Ләкин уянасың икән, Аллага шөкер итәргә кирәк. Шатланырга кирәк, чөнки бу – адәм баласының иң зур шатлыгы. Димәк, сез исәнсез – яшәү дәвам итә.

Уянгач, аяк-кулларны хәрәкәтләндереп карыйсың. Алар эшли: йөриләр, бер кыенлыксыз хәрәкәт итәләр. Шуннан торып юынасың, тешләреңне чистартасың, гимнастика ясап аласың... Бөтен нәрсә исән-сау. Настоящный, Аллага шөкер!

Ә бер карасаң... Әйдә, бер генә мизгелгә шуны күзаллап карыйк: уяндың, ә сүз әйтә алмыйсың... Яки атлый алмыйсың... Яки кулларың хәрәкәтләнми... Качып та китә алмыйсың, сүз дә әйтә алмыйсың, хәтта кукиш та күрсәтә алмыйча кеше күзенә карап ятасың. Фаҗигаме? Фаҗига! Мондый хәлдән Ходай үзе сакласын. Шуңа күрә Ходай Тәгаләгә шөкер итәргә кирәк. Шатланырга!

Әле йокыдан торып та өлгермисең, сине ике шатлык көтеп тора дигән сүз. И-и, без ашыгабыз инде, вакыт әрәм итәсе килми. Капкалап алырга да чыгып китәргә кирәк. Тизрәк табынга утырабыз. Табында ризык мулдан. Мулдан булса, зур шатлык, чөнки адәм баласының ачлыктан интеккән чорлары да аз булмаган. Шуңа күрә табыныңда ашар ризык булу – бик зур нәрсә. Зур шатлык!

Ләкин шатлыкның иң зурысы табындагы ризык кына түгел әле, аның иң зурысы – синең ашый алуың. Әгәр ризык юк икән, син аны кайчан да булса бер юнәтергә мөмкинсең. Бу бары тик тырышлыктан, тынгысызлыктан тора. Хәзерге чорда шулай. Ләкинниндидер чиргә юлыгып, сиңа ашарга ярамый икән, беркем дә ярдәм итә алмый. Хәтта һәрчак табиблар да ярдәм итә алмый.

Шуннан, ягымлы елмаеп, хатының сине эшкә озатып кала. Уңышлар тели, бит очыңнан үбеп ала. «Кайтуыңа нәрсә пешерим?» – дигән була. Менә монысы да шатлык бит инде. Йортыңда яратып көтеп торучылар бар икән, эшеңне эш итәргә, начар юлларда йөрмәскә тырышасың. Гаилә – ул кешенең күңел бөтенлеген саклаучы зур көч.

Мин инде барысын да санап тормыйм. Әткәңәнкәң исән-сау булуы да зур куаныч. Алар гади генә карт белән карчык түгел – кешене үткәннәр белән тоташтырып торучы тылсым, гомер агачының тамырлары ич.

Менә шул рәвешле, адәм баласы иртән торып өеннән чыгып киткән арада гына да никадәр күп шатлыкка юлыга.

Шушы шатлыклардан түбәсе күккә тиядер дисезме? Шиш! Ул аларны күрми дә. Тапап уза, чөнки аның күзләре көндәлек мәшәкатьләр белән томаланган. Кайдан цемент юнәтергә, ничек фураж алырга, акча кайдан табарга, кайсы кибеттә карабодай ярмасы арзанрак икән... Төрле кешенең төрлечәрәк инде, әмма бернәрсә хак – таң белән үзен каршылаган зур шатлыкларны күрми ул.

Менә сез меңлекләрне аяк астына салып таптыйтаптый, эт койрыгында ялтырап киткән бер тиен артыннан чапкан кешене күз алдына китерә аласызмы? Бу очракта шулайрак килеп чыга. Кеше үзен уратып алган иң зур байлыкларны, иң газиз шатлыкларны таптый-таптый, вак-төяк артыннан йөгерә. Кемнең кем булуына карамастан.

И-и, кызык инде бу адәм баласы...
Бер карасаң...

Фото: Анна Арахамия

Казан артындагы кечкенә генә Кышкар – дөньяга ике академик биргән авыл. Аларның берсе – Казан дәүләт педагогика университеты профессоры, 16 елдан артыграк аның ректоры, 1990–1995 елларда Татарстан Югары Советы депутаты, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Казан дәүләт университетының атказанган профессоры, хезмәт ветераны Рүзәл Абдуллаҗан улы ЮСУПОВ. Рүзәл абыйның бай биографиясен, кызыклы хезмәт юлын бер мәкаләгә сыйдырып бетерү – Альп тауларын колачлауга тиңдер. Монда язганнар ул узган юлның бары мизгеле генә. Рүзәл Юсупов – татар милләте, татар теле фәне, татар мәгарифе өчен бик күпне эшләгән кеше. Аның гыйльми һәм публицистик хезмәтләре, язган мәкаләләре генә дә алты йөзләп. Болар бар да кешедә күпме ихтыяр көче, тырышлык була алуын күрсәтә.

Лилия
ГӘРӘЕВА



ТАМЫРЛАР Мин авылдашларым өчен Йосыф Абдуллаҗаны малае булдым. Әтием дә, әнием дә гап-гади колхозчылар иде. Әбибабайларым да – авыр тормышта яшәгән крестьяннар. Әтинең әтисе Йосыф бабайга гына бераз уку эләккәндер: авылда мөәзин булган ул. Бик гадел, юмарт кеше, диләр иде аны. Үзенә бирелгән сәдакаларын да авыр тормышлы авылдашларына өләшкән. Йосыф бабай вафат булгач, әби кабат кияүгә чыгып, читкә китеп барган. Әти һәм энесе Сафа икесе генә калганнар. Әниебез Лотфикамал Иске Мәңгәр авылыннан. Мин Бөек Ватан сугышы башланырга ике ел ярым кала – 1938 елның 14 сентябрендә туганмын. Туган җирем – Арча районындагы (ул чакта Әтнә) Кышкар авылы. Шагыйрь Габделҗәббар Кандалый, драматург Фатыйх Халиди, язучы Әхмәт Уразаев-Кормаши, мәгърифәтчеләр Мотыйгулла Төхфәтуллин, Таиб Яхин, Габдулла Тукайның әтисе Мөхәммәтгариф Тукаевлар укыган мәдрәсәсе белән атаклы авыл ул.



БАЛАЧАК Без биш малай үстек. Мин – өченчесе. Балачагымнан иң беренче истә калган күренеш шул: кыш көне уйнарга чыккач, өебез янынннан печән төяп узып барган чанадан бер учма печән йолкып алып калдым. Моны күреп торган бер апа, көлемсерәп, шелтәләде: «Син нишләп монда печән урлап йөрисең әле? Бар, өеңә кер, әтиең кайткан анда!» Йөгереп өйгә керсәм, форма кигән бер абый мине кочаклап күтәреп



«БЕР СӘГАТЕМНЕ ДӘ БУШКА УЗДЫРМЫЙМ»

алды. Әни исән чагында сорап кала алмаганмын: кайчан булган ул – Финляндия сугышыннан соңмы, әллә Суслонгердан кайткачмы?

Безнең балачак авыр елларга туры килде. Ягарга утын, ашарга ипи, кияргә кием юк. Кышын көннәр буена энем Әнәс белән ягылмаган өйдә сәкедә утырабыз. Әни бу вакытларда бездән 30 чакрымдагы Арчага чана тартып ашлык илтергә киткән була. Равил белән Наил абыйлар кырдагы эскертләрдән мичкә ягарга салам йолкып алып кайта, инеш буеннан тал чыбыгы җыя. Ә беркөнне әни елап кайтып керде. «Әй, балалар, әтисез калдыгыз бит, әтиегез үлгән», – дип сыгылып төште. «Иргегез батырларча һәлак булды», дигән кара мөһерле хат алган икән. Безнең бәхеттән, ул хәбәр чын булып чыкмады. Бер бәрелештә әти каты яраланып, немецлар басып алган җирдә ятып калган. Хәрәкәтләнмәгәч, үлгән дип уйлаганнар. Бераздан безнекеләр ул җирләрне кабат кулга төшерә. Әти, госпитальдә дәваланып, хат язарлык хәлгә килгәч, безгә хәбәр салган.

Үскәндә төп ризыгыбыз бәрәңге булды. Әле сугыштан соң да бик күп еллар уган бәрәңге кушып пешерелгән ипи ашадык. Ипи пешерү өчен, тимерче алачыгында калайны игәү сабы белән тишкәләп ясалган угычтан һәр атнаны ике чиләк бәрәңге уасы. Бармак битләре угычка эләгеп, канап, ертылып бетә иде.

Җитмәүчелек үзәкләргә үтте. Еллар узса да, бер вакыйга һич онытылмый. Әни, бер кадак сарык йоны тоттырып, бездән 15 чакрымдагы Әтнә базарына җибәрде. Миңа 10–11 яшьләр. Җәяүләп барып, базар таралганчы йөрсәм дә, әни әйткән хакка йонны алучы булмады. Кичкә таба көчкә арзанракка сатып, соң гына авылга кайтып җиттем. Мактыйсы урынга: «Ник мин әйткән бәягә сатмадың, йонны әрәм иткәнсең бит!» – дип, әни мине сүкте.

Авылдан 14 яшемдә китсәм дә, шуның дүрт-биш елын колхоз эшләрендә дә катнашып өлгердем. Ул елларда тирестән саман кирпеч сугалар иде. Без, малайлар, шул тирескә салам кушып, ат белән издерәбез. Аннары урак өстендә пираватта (привод сүзеннән) ат куууны да безгә йөкләлиләр иде. Зуррак үскәч, салам тарттыру, әвенгә көлтә ташу кебек эшләрне дә башкардым. Атлы эшкә йөрү ошый иде миңа, чөнки бөтен хатын-кыз эше безнең өстә (күбрәк миндә), һәм ул бик ялыктыра.

Әни уйнарга атнага бер генә чыгара иде. Сәбәбен яшереп тә тормады: уйнасагыз, киемегез туза, ризык күп китә. Без эштә пешеп үстек.



УКУ Башкалар шикелле, мәктәп ишеген сентябрьдә ачып кермәдем. Мин укый башлаганда уку елының яртысы узган иде инде. Укучы яшендә түгел идем әле. Укыйсым килә дип алҗыткач, әти мәктәп мөдиренә әйткән дә, ул «килсен» дигән. Беренче укытучым Кәүсәрия апа булды. Җиңел укыдым, беренче классны шул ук елны «биш»легә генә тәмамладым. Гомумән, җидееллык мәктәпне тәмамлаганда аттестатымда бер «дүрт»ле дә юк, гел «бишле»ләр генә иде. Укытучыларыбыз чын фидакарьләр булган икән дип уйлыйм хәзер. Аларның, бәлки, һөнәри осталыгы җитеп тә бетмәгәндер, ләкин алар намус белән укыттылар. Математика укытучыбыз Шамил абыйның педагогик белеме юк, ул мехчылар техникумын гына тәмамлаган. Шулай булса да, безне белемле итү өчен тырышты. Аңламасалар, алып кала, өстәмә укыта. Миңа математика җиңел бирелде. Алгарак китеп булса да әйтим, армиядән кайтып, филология факультетында укый башлагач, бер очрашканда бик әрнеп: «И, Рүзәл, син бит математик булырга тиеш идең!» – дип ачуланды укытучым.

Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, укуны Яңа Кенәрдә дәвам итәсе. Абыйларым бездән 15 чакрымдагы шул мәктәптә интернатта яшәп укыдылар. Шуңа күрә мин укыганда ук Казанда ул чакта абруйлы саналган авиация яки технология техникумына керү максатын куйдым. Кызыл таныклык белән анда имтихансыз гына кабул итәләр иде. Әмма таныклыгымда бер сүзне төзәтеп язганнар. «Биш»кә генә укыганны раслар өчен, Мактау грамотасы сорыйлар. Ә аны бирүче кыз җәйге ялга китеп барган. Грамотаны алганчы, документларны кабул итү вакыты узып киткән.

Мин әле анысын белми идем. Казанга кадәр илтүче кеше юк, берүзем юлга чыктым. Миңа 14 яшь тә тулмаган, үз гомеремдә беренче тапкыр Казанга баруым. Адресым: Колхоз базары урнашкан урам, түгәрәк баганалы капкалы йорт, Зөләйха апа. Озак эзләдем мин ул йортны, түгәрәк баганалы капкалар күп булып чыкты анда.

Казан кооперация техникумына документлар кабул итәләр икән, шунда керергә булдым. Кооперация сүзенең нәрсә аңлатканын да белмим. Анда уку тормышымдагы иң җитди сынау булды. Мин бит җиде ел саф татар авылында татарча укып килгән малай. Русчам такы-токы гына. Уку планы да, уку режимы да бик кырыс: өч ел эчендә урта мәктәп программасын да узып бетерәсе, белгечлек тә аласы, ике тапкыр практика да узасы... Рус теле укытучысы Тамара Лазаревна «өчле» куеп, бер семестр буена мине стипендиядән мәхрүм итте. Ә ул минем бердәнбер яшәү чыганагым иде, беркайдан бернинди ярдәм юк. Авылда да хәлләр бик авыр иде бит. Бу билге үз гомеремдә алган беренче һәм соңгы «өчле» булды.



АКЧА Миллион сумлык товарлар белән эш итә башлаганда әле 17 яшем дә тулмаган иде. Техникумны тәмамлагач, мине Курган өлкәсенә товаровед итеп юлладылар. Иске чемоданымда – әни биргән бер мендәр дә, тамак ялгарга дигән ризыклар. Өстемдә – таушалып килгән гади костюм. Җылы киемем дә, яшь башлар өчен кирәкле әйберләрем дә, аларны алырга акчам да юк. Усть-Уйка районының Ново-Кочердык дигән авылында эшли башладым. Райпотребсоюз складларына кайта торган товарны счет-фактура буенча кабул итәм, җитмәгән, бозылган әйберләргә акт төзим, тирә-яктагы кибетләрнең эшен тикшерәм, тагын бик күптөрле эшләр башкарам. Базадан товар алып кайту да минем өстә. Үзем төйим, саныйм, үзем, безнең районнан килгән машиналарны шәһәр буйлап эзләп табып, шоферларга ялына-ялына ризалатам... Бер барганда унышар машина товар төягән вакытларым була. Авыр-авыр капчыклар, әрҗәләр бит ул. Тәҗрибәсезлегем, яшьлегемнән файдаланып, берничә тапкыр төп башына утырта язганнары да

булды. Үз гомеремдә ике тапкыр судта катнаштым. Беренчесе Курган өлкәсендә эшләгәндә булды. Бозылган чүпрә өчен миннән түләтергә теләделәр. Базадан алганда товар бозылмаган иде. Дөньяда никадәр гадел һәм никадәр кара эчле кешеләр була алуын шунда эшләгәндә күрдем. Судта җиңдем. Соңыннан белдем: товар җаваплылыгы алыр өчен ул чакта яшем дә җитмәгән булган. Шунда мине яклап чыгыш ясаган райпотребсоюз председателе урынбасары Анатолий Катаевны гомерем буена рәхмәт хисләре белән искә алам. Гади хезмәткәрне яклап, гаделлек хакына үз җитәкчесенә каршы сөйләгән кешене башка күрмәдем.

Балалар үстергәндә дә акча гел җитмәде. Укытудан тыш, тәрҗемәләр дә иткәлим, рецензияләр дә язам... Ай ахырына барыбер кемнәндер бурычка алып торырга туры килә. Гаилә корганда йортыбыз төзелеп тә бетмәгән иде бит. Үз көчең белән, тиенләп җыйган хәләл акчаңа төзегән йорт та, башкасы да кадерле була.

Әле ректор итеп билгеләнгәч тә, телефоны да, башка уңайлыклары да булмаган шул йортыбызда яшәдек. Башта мине, торыр урының бар, дип, фатир чиратына бастырмадылар. Югыйсә андый хокукым булган. Шуны белгәч, чиратка бастым. Ул вакытта әле ректор түгел идем. 50 яшемдә үз гомеремдә беренче тапкыр фатир алдым. Дүрт кешегә – 48 квадрат метрлы торак! Бергә эшләгән «дус» профессорның шикаяте белән ул фатирны алу мәсьәләсе тарих-филология факультетының ачык партия җыелышында тикшерелде. Җыелыш мине тулысынча яклап чыкты, рәхмәт коллегаларыма.



УҢЫШ Татар телен, аның әдәбиятын ныклап өйрәнәсе килү теләге армиядә чакта туды. Кайту белән университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керергә әзерләнә башладым. 8–10 нчы сыйныфлар өчен татар теле программасын үзлегемнән өйрәнергә туры килде.

Безнең төркем бик көчле студентлардан тупланган иде. Соңыннан алар барысы да абруйлы шәхесләр булды: галимәләр Фирдәүс Гарипова, Флера Баязитова, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин, икътисад фәннәре докторы, язучы Фарсель Зыятдинов, фән докторы, шагыйрь Әнвәр Шәрипов, шагыйрь Шамил Маннапов, галимнәр Ленар Җамалетдинов, Шәрифҗан Асылгәрәев... Миңа беренче курстан ук тарих-филология факультетының комсомол оешмасы секретаре урынбасары вазыйфасын йөкләделәр. Икенче курстан соң секретарь итеп сайладылар. Өченче курста Ленин стипендиаты булдым. Университетта аны өч-дүрт кеше генә ала иде. Өченче курстан дүртәү – Ленар Җамалетдинов, Фарсель Зыятдинов, Равил Фәйзуллин һәм мин индивидуаль план белән укуга күчтек. Һәрберебез фәннең берәр тармагын сайлап, үзе өчен генә махсус уку планы төзеде. Соңгы ике курс программасын бер елда үттек. Диплом якларга әле вакыт бар, сынау срогы белән радиога тәрҗемәче булып кердем. Миңа кадәр монда озак еллар Абдулла абый Төхфәтуллин эшләгән. «Ас» тәрҗемәче, яңалыкларны машинкада басучыларга әйтеп торып кына тәрҗемә итә. Минем, оригиналны укып, телдән генә тәрҗемә итү тәҗрибәм юк иде әле. Ә радиода телетайп аша алынган хәбәрләрне шундук эфирга чыгарырга кирәк. Редактор булып язучы Барлас Камалов эшли, минем текстларны ул төзәтә. Күрәсең, аңа да эш күп калгандыр. Бер айдан мине ТАССР Министрлар Советының радио һәм телевидение комитетының радио бүлеге директоры Фәтхи Фазылҗанов чакырып алды. Ипле генә сөйләшә торган, олпат җитәкче: «Энем, син бик тырыш егет. Күреп торам, сиңа монда кыенрак, безгә тәҗрибәле кеше кирәк», – дигәч, шулкадәр күңелем төште. Абдулла абыйны пенсиягә озату утырышы алдыннан иде бу. Китеп өлгермәгән идем әле, мине дә чакырды. Ул: «Тыныч күңел белән китәм, урыныма ышанычлы кеше кала», – ди. Мине җибәрәселәрен әйткәч, Абдулла абый кабынып китте: «Кем әйтте? Ризалыгым юк!» Кайвакыт кешеләрнең язмышларын әнә шулай бер сүз, бер вакыйга бөтенләй башка якка борып җибәрә. Радиода эшләп калдым. Ярты елдан мине телевидениегә редактор итеп чакырдылар. Әле өйдә дә телевизорыбыз юк заман... Телевидениедә эшләү мине күп нәрсәгә өйрәтте. Шунда эшләгәндә диплом эшемне язып якладым. Диплом җитәкчем – Казан педагогика институты ректоры Мирфатыйх Зәкиев аспирантурага керергә тәкъдим иткәч, башта риза булмаган идем. Берничә ел эшләп, гаиләбезнең матди ягын бераз җайлау иде ниятем. Шулай да кандидатлык минимумнарын тапшырып куйдым.

Татарстан телевидениесендә эшләгән елларым тормышымдагы иң бәрәкәтле еллар булды. Тәҗрибәле журналист булып җитештем, СССР журналистлар берлегенә кабул ителдем. Мирфатыйх Зәкиевич икенче тапкыр аспирантурада укырга тәкъдим иткәч, бу юлы инде каршы килмәдем.



ФӘН 1964 елның көзеннән мин – Казан дәүләт педагогика институтының аспиранты. Җитәкчем – Мирфатыйх Зәкиев. Диссертация темасы – рус теленнән татарчага тәрҗемә итү теориясе. Бу темага әзерлегем, туплаган материалларым бар иде, аны вакытыннан элек язып, ярты ел алдан якладым. Мирфатыйх Зәкиев үзе җитәкләгән татар теле кафедрасына укытучы итеп эшкә алды.

Китаплар тәрҗемә иткәндә мисаллар янә күп кенә теркәлде. Докторлык диссертациясе язарга кирәк дигән фикергә килдем. Диссертация язу – катлаулы эш, алай да төгәлләп чыктым мин аны. Ләкин минем тема буенча яклау советлары булмау ачыкланды. Рус теле советына берничә төрки тел галимен кертеп, бу советны СССР хөкүмәте карамагындагы Югары аттестациясе комиссиясе карары белән генә якларга мөмкин иде. Бик катлаулы булды ул. Ниһаять СССР Фәннәр Академиясенең Рус теле институты советында мин «Общее и специфическое в лексико-фразеологической системе русского и татарского языков» дигән темага докторлык диссертациямне уңышлы якладым. Бу 1982 ел иде. Тиздән Мәскәүдәге аттестация комиссиясе «филология фәннәре докторы» дигән гыйльми дәрәҗә бирү турында карар чыгарды. Татар теле кафедрасы профессоры булып эшләвемне дәвам иттердем.

1983 елда ректор миңа тарих-филология факультетының деканы булырга тәкъдим итте. Коллективны, укыту-тәрбия эшләрен яхшы беләм, бу эшне башкару кыен булмады.

Җай гына эшләп йөргәндә институтыбызда зур яңалык – ректорыбызны Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, тарих институтына директор итеп күчерделәр. Аның урынына куяр кеше эзләү башланды. Бу эш белән партиянең өлкә комитеты шөгыльләнә иде. Мине дә чакыртып алдылар. Үзем күздә тоткан берничә кандидатны атадым. «Сине тәкъдим итсәк, ничек?» – дип сорадылар. Мондый җаваплы эшкә әзер түгеллегемне әйттем. Ике-өч көннән партия өлкә комитеты секретаре Рәис Беляев үзенә чакырып: «Син булдыра аласың, Рүзәл, сиңа ышанам!» – диде. 1986 елдан башлап, Казан дәүләт педагогика институтының, аннары университетының ректоры булып уналты ел ярым эшләдем.

Казан педагогика институты бай тарихлы. Ул 1876 елда, Санкт-Петербург һәм Мәскәү институтларыннан кала өченче булып ачыла. Шул вакыттан бирле педагоглар, мәгариф җитәкчеләре, галимнәр һәм мәдәният хезмәткәрләре әзерли торган шөһрәтле уку йортына әверелә. Мин үз алдыма вузны иң алдынгы югары педагогик уку йортлары сафына бастыру максатын куеп эшләдем. Минем өчен коллективта үзара аңлашу, татулык булдыру мөһим иде. Көнбатыш илләрендә күргәнемчә, үзем дә кешеләргә игътибарлы, тыңлый һәм аңлый белә торган җитәкче булырга тырыштым. Факультетлар, кафедралар саны икеләтә күбәйде, 6 факультет иде, 12 булды, 39 кафедрадан 60 ка җитте, яңа белгечлекләр кертелде. Чит ил вузлары белән элемтәләр урнаштырылды, докторлык диссертацияләре яклау советлары ачылды. Фәнни потенциал да ныгыды. 1986 елда фән докторлары 16 кеше булса, 2002 елда алар 60 булды. 1994 елда вуз яңа статус алды – педагогика университетына әверелде. Моңарчы укытылган инглиз, немец, француз телләренә өстәп, испан, гарәп, төрек, фарсы, һинд, кытай, япон телләре белгечләре әзерли башладык. Студентлар белән күзгә-күз карап очрашуларны, ачыктан-ачык сөйләшүләрне гадәткә керттем. Эш гаять күп, бер-ике атнага ялга китсәм дә, чемодан тутырып документлар алып барам да, вакытымны отчет докладлы язып үткәрә идем. Әнә шундый кырыс режимда эшләдем. Казан педагогика университеты беренче ун вуз арасында булды. Бу – зур күрсәткеч.

Аспирантура һәм докторантура, докторлык диссертацияләрне яклау советы җитәкчесе буларак, миңа чагыштырма лингвистика фәнен башлап җибәрү, фәнни-педагогик кадрлар әзерләү вазыйфасын да башкарырга туры килде. Минем җитәкчелегемдә 30 кеше кандидатлык диссертациясен яклады, 5 кеше фән докторы булды.



МӘХӘББӘТ Хатыным Диларага рәхмәтем зур. Кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрен язганда, китаплар, мәкаләләр язып бастырганда аның ярдәме әйтеп бетергесез булды. Бөтен диссертациянең, мәкалә, китапларның кулдан язган текстларын комиссион кибеттән сатып алган иске генә «Москва» машинкасында ул басып бирде. Әле дә бөтен язганнарымны компьютерда ул баса.

Дилара – күрше Олы Мәңгәр авылының уңган, чибәр кызы. Без танышканда Казан авиация институты студенткасы иде. Мин армиядә вакытта олы абыебыз Равил һәм эти-эниләр авылдагы өйне сатып, Казанның Северный бистәсендә яңа йорт җиткезгәннәр. Шуннан ерак түгел, без дә Наил абый белән туганнар ярдәмендә икебезгә йорт салдык. Уңайлыклары булмаган авыл өе. Тыйнак кына туй ясап, Дилара белән шунда яши башладык.
Өй эшләре, балалар тәрбияләү күбрәк аңа төште. Заводта да эшләп, читтән торып институтта да укыды, үзе эшләгән зур предприятиенең профсоюз оешмасы рәисе булды.
Яшь чакларны уйлыйм да, гомер заяга узмаган, максатыма ирешкәнмен, дим. Шулай да бер үкенечем бар: Диларага күбрәк булышасы булгандыр, бәлки.



БАЛАЛАР Ике бала үстердек – улыбыз Фәнис, кызыбыз Диләфрүз. Кызыбыз үзем эшләгән институтның чит телләр факультетын тәмамлап, халыкара бүлектә эшләде. Киявебез Айдар җитди эшләр башкара, тырыш, акыллы. Ислам белән Кәрим исемле оныкларыбыз бар. Алар да уңган, фикерле егетләр. Ә Фәнисебезне 30 яшендә югалттык, фаҗигале төстә вафат булды. Фәридә исемле кызы калды. Кайчакларда үзегем өзелеп улымны сагынам. Нинди булыр иде икән, ниләр эшләр иде икән, дим. Акыллы, булдыклы егет иде.



ҮЗЕМ ТУРЫНДА Мин – авыл баласы. Табигатем белән хуҗалык кешесе, төзүче. Ректор булып эшләгәндә үзем җаваплы вузның төзеклеге өчен гаиләмә эшләгәнгә караганда да артыграк көч түктем. Кечкенәдән авыр тормышта үскәнгә, пединститутның гади укытучысы булып эшләгәндә дә җиңел яшәмәгәнгә күрә, миндә кешеләргә ярдәм итү теләге көчле иде. Ул елларда авыррак хәлле укытучыларга һәм студентларга, хәтта үземә куркыныч янаганда да, хәлдән килгәнчә ярдәм итәргә тырыштым. Без договор буенча укыган студентларга да берничә ел стипендия түли алдык, мондый хәл башка вузларда булмады. Договор нигезендә укучыларга дифференциаль тәртиптә түләү системасы керттек, укырга кергәндә бары бер генә балл җитмәгәннәр, яхшы укыганнар аз гына сумма түләде.

Тырышып, чын күңелемне биреп эшләдем. Ләкин алай да кайбер югары җитәкчеләргә ярый алмадым. Казан педагогика университетында бер-бер артлы ревизияләр башланды. Миңа үз теләгем белән ректорлыктан китәргә тәкъдим иттеләр. Сайлау срогым буенча бер ел эшлисем калган иде – риза булмадым, хаклыгымны суд аша раслады. Дөньяда гаделлек тә барлыгына мин чираттагы тапкыр инандым. Срогым тулганчы эшләп, үз теләгем белән ректор вазыйфасыннан киттем.



МАВЫГУ Без үскәндә авылда гармун уйнамаган егет сирәк иде. Мин дә уйнаштыргалыйм, укыганда концертлар куеп та йөрдек. Бакчада эшләргә яратам. Әле дә үз бакчабызны көрәк белән үзем казып чыгам. Җәяү йөрим. Кабан күле буйларыннан көн дә бер урап кайтам. Күп мәкаләләр язам, китаплар бастырам... Яңарак кына «Милләтебез иминлеге сагында» дигән китабым дөнья күрде. Бер көнемне, бер сәгатемне дә әрәм үткәргәнем юк.





Килен һәм кайнана… Ике арадагы мөнәсәбәтләрнең матурлыгы, ныклыгы, якынлыгы күбрәк кемнең зирәклегенә, акылына, тырышлыгына бәйләнгән? Иреңнең әнисе үзеңнекеннән тары ярмасы кадәр генә ким булырга тиеш, диелгән динебездә. Ә менә сез моңа ничек ирештегез? Нинди сынаулар, нинди юллар аша уздыгыз? Сөйләгез әле! Башкаларга – бигрәк тә яшьләргә гыйбрәт, сабак, үрнәк итеп сөйләгез.



«Сөембикә» журналы белән берлектә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен үстерү мәсьәләләре комиссиясе «Килен һәм кайнана» дигән хатлар конкурсы игълан итә. Ул ел дәвамында барачак, һәм аларның иң эчтәлеклеләре журнал битләрендә урын алачак. Сездән хатлар көтеп калабыз!



БЕЗНЕҢ ӘНИ – ДӨНЬЯДА БЕР!



Фәнзилә ХӘЙРИЕВА

Кияүдәге апама кунакка килеп, алар яшәгән авылны шундук үз иттем. Кешеләрен яраттым. Апамның кайнанасы белән үзара җылы, якын мөнәсәбәтләрен таң калып күзәтә идем. Үскәч, минем дә шундый гаиләгә эләгәсем, кайнанамның кызы урынына күргән яраткан килене буласым килде.

Иске Байсар авылын мин кечкенә вакыттан ук белә идем инде. Чөнки Филүзә апам шундагы больницада шәфкать туташы булып эшли иде. Шунда ул кияүгә чыкты, Фәнил җизни белән ике кыз тәрбияләп үстерделәр. Мин инде мәктәптә укыган елларымда җәйге каникулларны көтеп ала идем. Чөнки апама булышырга дип утырмага барачакмын! Бу матур авыл, әллә нинди серле бер утрау кебек, күңелнең бер почмагына кереп урнашты! Зурлыгы, халкының күплеге, урамнарының яшеллеге, ишегалларының чәчәкләргә күмелеп утыруы, урам тутырып кешеләр йөрүе мине шаккаттыра иде. Ул Сөн буйлары, асылмалы күперләре, урманнары, аккошлар кайта торган күлләре, Чәүкә таулары, Казан–Уфа юллары… Анда больница, зур мәктәп, мәчет, кибетләр… Мәдәният йортында гел концерт-спектакльләр куялар. Апамның кайнанасы, Татарстанның атказанган терлекчесе Әминә апа Гарипованың спектакльләрдә уйнавы артистлардан һич ким түгел. Ул һәрчак баш рольләрдә. Районда гына чыгыш ясап калмыйлар, Казаннарга чаклы баралар! Үзем кечкенә генә Иске Җияш дигән авылдан, бездә башлангыч мәктәп кенә.

Күрше авылга, 3 чакрым ераклыктагы Иске Теләкәй урта мәктәбенә йөреп укыдык. Ә Байсар, рәшә артындагы әкияти бер дөнья булып, гел ымсындырып, үзенә тартып торды. Апама кызыгып: «Их, шундый авылда, шундый кайнана белән яшәсәң иде!» – дигән хыялый уйлар да башта уйнап алмый калмагандыр.

Мәктәпне тәмамлагач, Алабуга мәдәният-агарту училищесына, театр бүлегенә укырга кердем. Укып бетереп кайткач, районда эш урыннары тәкъдим иттеләр. Алар арасында Байсар мәдәният йорты да бар! Минем инде театр артисты буласым килә башлаган чаклар. Әлмәт, Минзәлә театрларын күздә тотам үземчә. «Ярар, Байсарга барып берәр ел тәҗрибә туплыйм да, театрга китәрмен», – дим. Шундый уйлар белән хыялымдагы авылга эшкә килдем. Җор телле, моңлы тавышлы бик тә кешелекле, ярдәмчел клуб мөдире Әнвәр абый Вәлиев шундый ачык итеп каршы алды! Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дә бит әле үзе! Дәртләнеп эшкә керештем. Ирек исемле егет яшьләр оешмасы җитәкчесе икән. Шук-шаян, тәвәккәл, авыл яшьләре белән төрле спорт ярышлары да оештыра, мәдәни чараларны үткәргәндә миңа да булыша. Бик ярдәмчел, ихлас үзе. Ут эчендә, Чечняда хезмәт итеп кайткан. Шәп егет, кыскасы. Уртак эшләр безне тагын да якынайтты. Мин апамнарда яшим, Ирек кичләрен озатып куя. Ошый бу егет миңа! Ирек белән йөри башлагач, кызлар: «И син аның әнисенең әйбәтлеген белсәң иде, Фәнзилә! Халидә апа шундый рәхәт кеше!» – дип, күңелне иләсләндерәләр. «Ул шундый киң күңелле, өеннән гел кеше өзелеп тормый!» – дип мактыйлар. «Кем генә керсә дә, чәй эчерми чыгармый инде», – дип тә җибәрәләр. Берсе шунда: «Ирекнең Эльмира апасы Минзәлә театры артисткасы бит. Кара, син аңа охшагансың бугай», – дип, салпы якка салам кыстыра. Әтисе гармунда уйный, әнисе ягыныкылар – җырчылар, энесе Эдуард белән сеңлесе Миләүшә бииләр, ди. Ә мин, кыенсынып, шул Халидә апаның күзенә чалынмаска тырышып, урамнарыннан кача-поса гына узып китәм. И Ходаем, тәрәзәдән карап кала күрмәсеннәр тагы, дим. Булачак кайнанам белән күрешкән юк иде әле. Көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинатында тегүче булып эшләгән, соңгы арада мәктәптә технология дәресләре алып бара, кызларны тегәргә, аш-су әзерләргә өйрәтә дип кенә беләм.

Клубта эшләгәч, сәхнәгә дә чыгасың, җырлыйсың да, биисең дә. Әлбәттә, Ирекнең әнисе дә клубка төшми калмый. Ул концерт-спектакльләрне калдырмый икән. Берзаман иптәш кызлар сөенче ала: «Халидә апа сине бик ошаткан икән! Фәнилнең балдызы бигрәк сөйкемле кыз, дип әйткән ди!» Ирекнең апа-сеңелләре телендә дә гел мин генә, ди, имеш. Мин инде үземне Хәйриевләрнең кадерле килене, эне-сеңелләренең яраткан җиңгәләре итеп күз алдына китерә башлыйм. Илфак абыйга – әти, Халидә апага әни дип дәшәсе көнем турында җитди уйланам.

2001 елның матур җәендә Ирек белән өйләнешергә сүз куештык. 23 августта безнең якта – Теләкәйдә язылыштык, ә 24-ендә инде мин Байсарга килен булып төштем.

Ирекнең әти-әнисе мине елмаеп, якын итеп каршыларга чыккан. Оялып кына: «Исәнме, әни! Исәнме, әти!» – дип, ике куллап күрештем. Ә алар бал-май каптырып: «Бал кебек татлы телле бул, кызым!» – дип, кочаклап ук алдылар. Әтигә килен бүләге итеп түбәтәй кидердем, әнинең иңсәсенә ак яулык салдым. Аннары Ирекнең Эльмира апасы мине су юлы күрсәтергә алып китте. Көянтә-чиләкләр асып, сөйләшә-сөйләшә Әхсән абыйлар коесына суга бардык. Шушы туй көнендә үк әнинең оештыру сәләте көчле булуга шаккаттым. Безнең кызыл туйны ул энәсеннән җебенә тикле уйлап оештырган иде. Ул ха-лы-ык! Бөтен авыл җыелган диярсең! Ишегалдына зур палаткалар корып куйганнар, шарлар, авыл рәссамы Энгельс абыйдан пар аккошлар рәсемен ясатып элгәннәр, матур сүзләр язылган плакатлар белән бизәгәннәр. Өстәлләрдә – урман, кыр чәчәкләре, мул табын. Йөз метр гына арадан Сөн, аръяктагы яшел болыннар, анда уйнап йөргән колыннар болай да түгелергә торган күңелне чайпалдыра. Күземә яшьләр бәреп чыга. Бәхет яшьләре! Бакча ягына кухня хәстәрләгәннәр. Унлап хатын-кыз йөгерә-йөгерә ашарга әзерләп йөри. Уйлап карасаң, никадәр хезмәт! Хәзер инде ул туйларны кафеларда бер генә көн үткәрәләр, артык мәшәкатьләнмиләр дә кебек.

Туйда тәнәфес вакытында әни мине үзе биергә чакырды! Көчле кул чабулар астында парлап биедек! Соңыннан аңладым: күңелдәге тартынып торуларны юып төшерер өчен әни махсус шулай эшләгән инде! Һәм без шуннан бик якынаеп киттек. Ул миңа сердәшче дә, киңәшче дә, дус кызым да кебек. Аның белән бөтенесен уртага салып хәл итеп була. Үз әниемә алай ук ачыла алмыйм мин. Ә кайнанам белән рәхәтләнеп сөйләшәбез. Җияшкә баргач та камыр ризыклары пешергәндә: «Безнең әни болайрак пешерә, менә шуларны куша», – дип тезә башлыйм да, «И син бианаңны якынрак күрәсең лә», – дип, үз әнием юри үпкәләгән булып кылана. Нишләмәк кирәк, туган йорттан 16 яшемдә чыгып киттем, кайнанам белән 21 ел яшим икән шул инде. Безнең якта ирењнең әти-әнисен биатай, бианай дип йөртәләр. Миңа ул сүз ничектер салкын, чит тоела. Берәрсе: «Бианаң өйдәме?» – дип килеп керсә, «Әниме?» – дип кайтарып сорыйм.

Яңа йорт җиткереп башка чыкканчы, алты җан ел ярым бергә яшәдек әле: әти белән әни, Ирек, мин, энесе, сеңлесе. Шул чакларда әти белән әни ник бер авыр сүз әйтсен дә, ник караңгы йөз күрсәтсен! Апасы белән җизнәсе – икесе дә артистлар, атна саен Минзәләдән кайтып йөриләр. Эльмира апа белән аеруча якын сердәшләр идек. Ул мине бертуган сеңлесе урынына күрде. Концерт-спектакльләр әзерләгәндә дә булышырга клубка килә иде... Иде, дим. Эльмира апа моннан биш ел элек юл һәлакәтендә вафат булды. Аңа кадәр Илдар җизни дә арабыздан киткән иде инде... Әнинең ул югалтуларны ничек кичергәнен, җанына урын табалмый өзгәләнүләрен үзебез генә беләбез... Алай да түзем, сабыр була белде әле ул! Ирек Чечняга эләгеп, өч айлап бер хәбәре дә килмәгәндә дә, йөрәге ут булып янса да, күз яшьләрен күрсәтмәгән: «Кайтыр, Аллаһ боерса, исән генә йөрсен балакаем!» – дип, өйдәгеләрдә дә ышаныч, өмет уята белгән ул. «Яклый мине, саклый мине әнкәмнең догалары», – дип кенә әйтәсе кала...

Бер елдан китәм дип килгән кыз әнә шулай бөтенләйгә кала.

Өйләнешеп ел ярым үтүгә кызыбыз Сөмбел туды. Эдуард укытучы кыз Луизага өйләнде. Шулай итеп, ике килен, кайнана-кайната бер түбә астында яшәп алдык. Төрле чаклар булгандыр, ләкин әти белән әни тарафыннан ялгыш та кырын караш тоймадык. Әни шәп дипломат ул безнең! Һәрвакыт алтын урталыкны таба белә! Мунча яксак: «Барыгыз, бар, сез кирәгез башта. Балаларны юындырыгыз. Без кайчан да керәләбез, ашыгыр җир юк», – ди. Кер юып элсәк: «И чиста да минем киленнәр! Ап-ак бит бөтен керләре!» – дип мактый башлый. Уйлый торгач, әнинең канәгатьсезлеген сиздерә, чак кына шелтәләгәндәй итә торган бер сүзен таптым бит тәки! «И бәбекәччәем!» – дип куя ул башын чайкап. Һәм шуның белән вәссәлам! Ул да көлә, без дә көләбез.

Күршегә генә йорт салып чыктык. Ике ихата уртасында капка бар, шуның аша гына йөрибез. Ул капканың ябылып торганы да юк. Миңа кияүгә чыкканда бер тана, өч сарык бүләк иткәннәр иде. Яңа өйгә малларны да үзебез белән алып чыктык. Иртән сыер саварга кирәк. Көтү киткәнче, дүртенче яртыда торып сыер савасың. Клубта эшләгәч, бик соң кайтырга туры килә. Төнге берләр җитә. Яшьләр күп, төрле чаралар үткәрергә кирәк. Сөмбел дә әле кечкенә. Кайбер көннәрдә торалмыйча йоклап калган чаклар да булды. Ул вакытта да әни мине уятмады, үзе кереп, сыерны савып куя иде. Мин торып чыкканда йә сыер сава, йә сауган сөтне тапшырырга дип, урамга ук чыгып киткән була. Кая гына җыенсак та – Актанышка төшәбезме, эшкә йөгерәбезме, Чаллыга барабызмы – тыныч күңел белән чыгып китәбез. Ишек бикләнгәнмеюкмы – уйлап торыш юк, чөнки әни һәрвакыт керә, тикшерә. Көненә өчәр-дүртәр тапкыр кереп тә хәлебезне белеп чыга ул. Үзебез дә шулай: ике өйне берләштереп, арткы капкадан керә-чыга йөрибез. Эштән кайтышка кайчак ашарга әзер булмый. Ә әни сизгән диярсең: «Әйдә, тиз генә юыныгыз да керегез. Хәзер токмач салам да аш кабартам», – дигән тавышы ишетелә. Йә: «Фәнзиләәү! Коймак пешергән идем, чәй эчеп чык», – дип чакыра.

Безнең гаиләне умартага тиңләр идем. Ә әни безнең – чып-чын ана корт: балаларны, якыннарны, туган-тумачаны, кода-кодагыйларны җыеп торучы изге җан ул. Бәрәңге утырту-алулар, печәнгә төшүләр, сугым суюлар, каз өмәләре – җыенысын, бөтен балалары җыелып, уен-көлке белән күмәкләшеп башкарабыз да эшне тиз генә тәмамлап, Сөн култыгындагы аяк очында – алмагач, шомыртлар ышыгындагы өстәл артында табын корабыз. Әти хромкада уйный, без җырлыйбыз. Балалар кечкенә чакта да шул хромкада уйнап, оныкларын биетеп-җырлатып үстерделәр инде. Әтине, яратып, «Мичурин бабай» дип тә йөртәбез әле. Ул бит бакчачы безнең. Нәрсә утырта башласак та, аның киңәшенә колак салабыз. Кайсы орлыкны кайчан чәчәргә икәнен, кайчан җирнең өлгерәсен төгәл әйтеп бирә ул. Иртүк бакчага чыгып китә, кояш баеганда гына керә. 6 нчы класста укучы улыбыз Сөләйман гел бабасы янында. «Малай кеше бабай янында эшкә өйрәнеп үсә инде», – дип, әбисе кечкенәдән үк сеңдерә килде.

Гаилә ансамблебез турында да әйтим инде. 2007 елда бөтен гаиләбез белән чыгыш ясап, районда җиңеп кайттык без! Ирек белән Эдуард биеде, Эльмира апа белән әти өздереп гармунда уйнады, әни, Илдар җизни, Эльмира апа спектакльдән өзек күрсәттеләр, ахырдан күмәкләп җырладык... Ул ансамблебезгә менә дигән алмаш үсеп килә бүген. Сөмбел, Сөләйман, Эльза, Зилә, Гүзәл, Наилә, Камил, Алсу, Айсылу, Ләйлә, Роберт – Хәйриевләрнең оник-оникчыклары үзе бер труппа булырлык.

Төрле кичәләр үткәргәндә, концертлар куйганда авыл үзешчәннәре белән эшлим. Һәр концерт-спектакль саен клубта утырып чәй эчүне матур гадәткә әйләндердек. Менә шул көнне әни һәрвакыт бәлеш пешереп куя безгә. Концертка төшмәсә төшми, бәлешне пешерми калмый! Миңа соңыннан видеосын күрсәтерсез әле, ди. Мәдәният йорты каршында эшләп килүче «Җәүһәр» ансамбле өчен әни, үзе белән бергә эшләгән тегүче Хәнилә, Дамира апалар белән бергә ике ел рәттән инде концерт костюмнары тегә. Күлмәкләр, алъяпкычлар, яулыклар... Менә шулай әни минем өчен, клуб өчен дә җан атып йөри. Минем өчен генә түгел, кызым өчен дә сердәш ул. Сөмбелебез Чаллыда медицина көллиятендә 3 нче курста укый. Кайтып кереп минем белән чәй эчеп ала да: «Әбкәйнең хәлләрен белеп чыгыйм әле», – дип, әниләргә кереп китә дә көне буена югала. Сәгатьләр буе серләшеп утыралар. Кызыма да әйтәм инде, синең кайнанаң да әбиең кебек булсын иде, дим.

Килен кайнана туфрагыннан ярала, диләр бит. Хактыр. Әни дә кайнанасы Мәрзия, килендәше Галя белән бер өйдә бик дус, тату яшәгән. Галя больницага эшкә килгән җирдән кияүгә чыгып калган бу якларда. Галя апа татарча сөйләшергә дә, безнең гореф-гадәтләргә дә өйрәнгән. Килендәше Халидәнең зирәк акылы, үрнәк яшәү рәвеше, кешеләрне яратуы, игелекле, ярдәмчел булуы рус кызын әнә шулай безнең мохиткә боргандыр дим мин.

Шундый тыл булганда, эшләребез әйбәт бара, җаныбыз тыныч, күңелебез көр. Ирек – «Ташкын» хуҗалыгының баш зоотехнигы. Берничә ел рәттән районда «Үз һөнәренең остасы» дип танылды. 2018 елда Казанда узган авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре бәйрәмендә республикабызның ул вакыттагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов, Ирекнең хезмәтләрен бәяләп, «Рәхмәт хаты» тапшырды. Сөенгәннәребез! Бездән дә бигрәк, әти белән әни шатланды! «Министр үзе тапшырган бит!» – дип куюлары иң олы рәхмәткә тиң иде. Мин дә «Үз һөнәренең остасы» дигән исемгә лаек булдым. Безнең мәдәният йорты төрле мәдәни чаралар үткәрү буенча Актаныш районында гел беренчеләрдән. 2021 елда республика күләмендә үткәрелгән «Иң яхшы мәдәният хезмәткәре» дигән конкурста җиңеп, грант оттым. Һәм боларның барысы да безнең генә түгел, әтинең, әнинең дә зур җиңүе ул!

Белмим, республикада, бәлки, андый кайнаналар бардыр, ләкин безнең районда, безнең авылда аның шикеллесе юктыр. Безнең әни бит ул – мировой, дөньяда бер!

«СЕЗНЕҢЧӘ ТУЙ КИРӘКМИ БЕЗГӘ!»

Җәй көне бердәнбер улыбызны өйләндерәбез. Бу көн турында күптән хыялланып йөрдек: никахын, туен, килен токмачын, су юлы күрсәтү кебек гореф-гадәтләрне бөтен йоласын туры китереп үткәрәсе, туганнарны, дусларны чакырып зур бәйрәм оештырасы килә. Ләкин... Яшьләргә алай кирәкми. Алар мәчеттә генә никах укытып, соңрак үзләренчә туй уздырырга тели. Без хыялланган йолаларны бөтенләй кирәксенмиләр. Калган эшкә кар ява дигәндәй, соңыннан дип калдырган туй бөтенләй дә булмаска мөмкин, ясап тормыйбыз диярләр. Кыскасы, аларга безнеңчә ошамый, безгә – аларча. Ничек күндерергә аларны? Һәрнәрсәнең үз вакыты бит. Үстергән балаларыбызның тормыш юлын матур башлыйсы килә...

Ильмира. Казан.

Җәвит ШАКИРОВ. Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты

Туй мәҗлесләре, никах табыннары уздыручы буларак, очрашып сөйләшкәндә кайбер әти-әниләргә дә, яшьләргә дә киңәш бирәм. Йолалар инде онытылып бара, әмма без аларны яңартырга, искә алырга тиеш. Халкыбызның күркәм гореф-гадәтләре: бал-майдан авыз иту, чигелгән матур сөлгеләргә икмәк куеп, яшьләрне әти-әниләре каршына бастыру, аларга хөрмәт күрсәтү, әти-әниләргә, әби-бабаларга бүләкләр бирү бик күңелле үтә бит!

Хәзер яшьләр никах укыталар да, туй уздырып тормыйлар – чыгымнар күп. Акчаны туйга сарыф итмичә, ялга барып кайтучылар да байтак. Без, әти-әниләр, йолаларны сакларга тырышсак та, яшьләр фикере белән дә килешергә кирәктер. Акчаны янга калдырып, файдалырак урынга тотарга ниятлиләрдер, бәлки. Мин яшьләргә каршы килмим, аларның фикерен тыңларга тырышам. Шулай ук әти-әниләрнең дә фикерен исәпкә алып, шулайрак итик дип киңәш бирәм, бер урталык табарга тырышам. Балаларыбыз безгә бик кадерле. Иң мөһиме – бәхетле булсыннар, тапкан малларының рәхәтен күрсеннәр.

Зөлфия ШАКИРОВА. Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты

Без – балачактан әкиятләр карап, китаплар укып, ак туй күлмәге киеп бердәнберенә кияүгә чыгу турында хыялланып үскән буын. Тәрбия икенче иде. Әти-әни Аллаһтан соң икенче урында булды. Мин беркайчан да, хәтта үзем инде дәү әни булгач та, алар сүзеннән чыкмадым. Әти-әни сүзе минем өчен закон иде. Үзебез дә улыбызның туен бөтен йолаларны үтәп башкардык. Безне әти-әниләр шулай тәрбияләгән, без шуның буенча яшибез, балаларыбызга, оныкларыбызга да шуны биреп калдырырга тырышабыз. Хәзер бит ирекле мәхәббәт... Чит илгә охшатырга тырышып, мөселман икәнлегебезне онытып яшәп карыйлар, аннан өйләнешәләр, ошамаса – аерылышалар. Туй түгел, хәтта никах та укытмыйлар. «Соңыннан»га калдыруны җиңел холыклылык дип кабул итәм, димәк, алар бу мәсьәләгә җитди карамый. Әти-әни әйткәнне санламау, дип әйтер идем. Алар бит озаграк яшәгән, тормыш күргән кешеләр. Туй ул бер генә була, һәм һәрвакыт әти-әнинең хәер-фатыйхасында узарга тиеш. Шул очракта гына никах бәхетле дә, озын гомерле дә була.

Белгеч фикере



Солтания ГАТАУЛЛИНА, психолог

Туй алды каршылыклары күп парларда туа. Әти-әниләр яшьләрнең бәйрәме икәнен онытып, үзләренчә бәйрәм итәсе килгән очраклар еш очрый. Туйны яшьләр өчен түгел, кунаклар өчен уздыралар. Кешегә күрсәтү өчен кебегрәк килеп чыга. Балалар аша үзләренең хыялларын тормышка ашыру дип әйтер идем мин моны. Кемнеңдер мәсьәләсе бик кискен тормый, яшьләр риза була, ә менә кемдер үз хыялы өчен туганнар белән каршылыкка килергә мәҗбүр. Нишләргә? Иң элек бер сорауга җавап бирегез – ул барысын да хәл итәчәк. Туйның финанс ягын кем үз өстенә ала? Монда өч төрле вариант бар:

1. Туйның бөтен чыгымнарын әти-әни түли. Бу иң авыр очрак. Ата-аналарның бик сирәге генә акчаны яшьләр кулына тоттырып, тулысынча үзләренә хәл итәргә мөмкинлек бирә. Кем түли, шул җырга заказ бирә бу очракта.
2. Чыгымнарны яшьләр һәм әти-әниләр бергәләп түли. Бу очракта, сөйләшеп уртак фикергә килү мөмкинлеге күбрәк.
3. Туй чыгымнарын яшьләр тулаем үз өстенә ала һәм бәйрәмнәрен үзләре теләгәнчә үткәрә.

Әйе, гореф-гадәтләрне саклау, аларны буыннан-буынга җиткерү – бик күркәм күренеш. Әмма яшьләрнең теләкләрен дә истә тотып эшләү кирәк: сайлау мөмкинлеге калдырыгыз, җаваплылыкны үз өсләренә алу ирекен бирегез. Туйны бер генә һәм гомерлеккә истә калырлык итеп уздырырга кирәк.



САБАН ТУЕ – УРТАК ТУЙ!



Лилия
ГӘРӘЕВА

Халкыбызның гореф-гадәтләре турында язып та, Сабан туен телгә алмасак, гаҗәп булыр иде. Иң борынгы һәм бүгенгә кадәр халкыбызның яраткан, көтеп алган бәйрәмнәреннән ул. Сабантуйның килеп чыгышы ерак гасырларга, Идел буенда яшәүче татарларның ислам динен кабул итүләренә кадәрге чорларга ук тоташа, һәм ул игенчелек культы белән бәйле. Әлеге йоланың беренчел максаты – Күк һәм Кояш алласы Тәңрегә гыйбадәт кылып, корбан чалу, мул уңыш алу өчен югары рухларның күңелен күрү булган. Сабан туе бәйрәме турында 921 елда Идел буе Болгарстанына сәяхәте вакытында Әхмәт ибн Фадлан да язып калдыра.
Сабантуй турындагы мәгълүматларыбыз күп очракта мәйдан, андагы уеннар, көрәш һәм ат чабышы белән төгәлләнә. Югыйсә төрле җирдә яшәүче татарларда Сабан туе дигән сүз бәйрәм белән бәйле төрле йолаларны да берләштерә.

Киби (кыйби)

Сабан туен уздыруның элек төгәл генә бер көне булмаган, ул һава торышына, табигать шартларына бәйле узган. Күп җирдә аны җир кибү белән, язгы чәчүгә керешкәнче уздырганнар. Казан арты татарлары исә чәчү төгәлләнгәч бәйрәм иткән. Бәйрәмнең көнен гадәттә авылның аксакаллары билгеләгән һәм базар көнне аны халыкка белдергәннәр.

Сабан туе алдыннан балалар өйдән өйгә кереп, бәйрәмнең кайчан буласын хәбәр итеп йөргән. Һәр өйгә кереп, шатлыклы хәбәрне ирештергәннәр. Аның үз такмагы да булган:

Киби-киби кипкән,
Сабан туе җиткән.
Сабан туе иртәгә,
Атың бәйлә киртәгә.

Киби гадәттә Сабан туена атнаун көн, унбиш көн кала уздырылган. Галимә Флера Баязитованың «Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары» китабында кибиның Сабан туе алдыннан, язгы ташу тынгач булуы турында әйтелә.

Аның «дәрә кычкыру» дигән варианты да билгеле. Яшьләр тау битендә учак яккannар, малай-шалай исә: «Әй-әй-әй, иртәгә – сөрән, берсекөнгә – телән!» – дип кычкырган. Дәрә кычкыру Сабан туе башлануга ишарә булган. «Дәрә кычкырганнар иде, Сабан туе башланды», – дигән өлкәннәр.

Кар эреп, җирләр кибү белән егетләрнең тагын бер шөгыле арткан – Сабан туенда катнашасы атларны ярыштырып, чабышка әзерләгәннәр. Ат аягы кыздыру дип аталган ул.

Сабан туен сабан, сөрән, сука белән генә бәйләп аңлату дөрес түгел. Сабан сүзе язгы чәчү, сөрү эшләрен һәм әлеге чорны да белдерә.

Сөрән сугу

Сабан туена кадәр һәр авылда, хәзер инде хәтта Казанның үзендә дә башкарыла торган бер күркәм йола яши. Күпчелек авылларда бирнә җыю, бүләк җыю дип атала ул. Кайдадыр сөрән, сөрән сугу, сөрән салу, диләр. Кыйби җыю, әрәпә, сөлге җыю дигән вариантлары да бар. Төрлечә аталса да, әлеге йола Сабан туе алдыннан яшьләрнең авылда йорттан йортка кереп халыктан бүләк җыеп йөрүеннән гыйбарәт. Флера Баязитованың югарыда телгән алынган китабында болай диелә: «Иртәгә Сабан туй дигәндә сөрән сугалар ыйы, көне буена йөриләр. Җәш киленнәрдән тастимал җийалар. Җүкә тайакны теләләр, шунда элдереп җийалар. Ике-өч кеше тотоп йөри, җаурыннарына (җилкәләренә) салып. Урам буйы гарбуннар белән җөриләр сөлге җиганда».

Бүләкне төрле якта төрлечә җыйганнар. Кайбер якларда моны яшь егетләр башкарган. Җилкәләренә сөрән агачын салып (бүләкләрне бәйли торган агач), урам буйлап җәяү йөргәннәр. Кайсыдыр авылларда бүләкләрне муенга асканнар яки билбауга гына бәйләгәннәр. Ул билбау «зәр» дип аталган. Кайдадыр бүләк җыю өчен егетләр атларга атланып чыккан – атлы сөрән дигәннәр. Һәр ике вариант та – уен-көлкеле, җырмузыкалы үзе бер бәйрәм рәвешендә узган. Арадан бер яки берничә егет гармунда уйнаган.

Сабан туена бүләк җыюда кайбер авылларда олы яшьтәге ирләр генә катнашкан. Монысы җыр-гармунсыз гына башкарылган һәм бәйрәм кебек булмаган.

1970–1980 нче елларда Казан арты районнарында Сабан туена бүләкләрне җигүле атларда, дугаларга кыңгыраулар тагып җыялар иде. Ат арбасына кечкенә бала-чага төялә, егет-кызлар гармун белән җырлап килеп, һәр йортка туктала. Әбиләр-апалар бүләк җыючыларны капка төбенә үк чыгып көтә. Кеше күбрәк җыелган җирдә яшьләр татар көенә биеп тә алалар, аларга апалар да кушылып китә. Биргән бүләкләр озын нәзек колгага бәйләнә. Авылны йөреп чыкканчы ул колганың авырлыгы шактый була, аны егетләр чираттан күтәрә.

Сабан туе сөлгесе

Сабантуйга бирелгән иң кыйммәтле бүләк булып һәрвакыт чигүле сөлге саналган. Узган Сабан туеннан соң шушы авыл егетенә кияүгә чыккан яшь киленнәрнең һәркайсы бәйрәмгә атап сөлге чиккән. Казан артындагы кайбер авылларда яшь киленнәр бәйрәм бүләге итеп ирләр күлмәге һәм ике чигүле кулъяулык яки намазлык та әзерләгән. Башкалар исә кем – баш яулыгы, кем – күлмәклек яки бер метр-метр ярымлы тукыма, кемдер исә чигүле кулъяулык бүләк иткән. Сөлге, тастымал бирүчеләр дә булган. Моннан тыш, һәр хуҗалык Сабан туена бүләк җыючыларга бер яки берничә йомырка да биргән. Төрки халыкларда йомырка яз килүен белдерүче символ, ә татарларда ул Сабан туен гәүдәләндергән. Ул көнне җыелган йомыркаларның бер өлешен кибеткә тапшырып, Сабан туенда катнашучыларга бирергә бүләкләр алынган, бер өлешен балаларга өләшкәннәр. Калганы мәйдандагы уеннар өчен тотылган. Уфа өязендә, мәсәлән, йомыркаларны кызылга манып, мәйдандагыларга да өләшкәннәр.

Сабан туйга бүләк бирү һәркемнең үз ихтыярында булса да, һәр йорт үзеннән өлеш чыгарган. Әле яшьләр берәр сәбәп белән үз капкаларына сугылмасалар, хәтта үпкәләгәннәр дә. Сабантуйга бирелгән бүләк – сәдака – өйне ут-күздән саклый, бәрәкәт китерә дип ышанганнар. Авылда яшәүчеләр генә түгел, кайткан кунаклар да Сабан туена бүләк әзерләргә тырышкан. Бу йола әле дә саклана. Сабан туе батырына яки беренче килгән чабышкы өчен дип, кемдер бүләкне адарынып та биргән.

Бөтен авылда да бүләк җыю йоласы булмаган. Мәсәлән, Минзәлә районының Минзәләбаш авылында бүләк аласы акчаларны авыл байлары биргән. Батырның иңенә саласы сөлгене исә яшь киленнәр бүләк иткән. Чигүле бу сөлгеләр белән батырларны гына түгел, ат чабышында, йөгерүдә беренче килгәннәрне дә бүләкләгәннәр.

Кайбер якларда бирнә җыю төгәлләнгәннән соң, яшьләр җырлыйҗырлый авылны тагын бер кат әйләнеп, бүләкләрне күрсәтеп чыкканнар. Сөлгеләрнең берсе кыр капкасын бизәгән. Иртәгә бездә бәйрәм дип, күрше-тирәдәгеләргә белдереп торган ул. Соңыннан җыйган бүләкләр авылның мәртәбәле картларына тапшырылган.

Мәйдан

Сабан туе уеннары уза торган урын һәр җирдә диярлек бер исем йөрткән – мәйдан. Бәйге дигән атамасы да билгеле. Бик сирәк авылларда гына моның өчен аерым бер урын булып, Сабан туе ел да шушы урында уздырылган. Күп авылларда әлеге мәйдан, игеннәрне таптамас өчен, пай җиренең кайда калдырылуына бәйле сайланган. Тигез, чиста, халыкка бару-кайту өчен уңайлы да булырга тиеш булган ул.

Һәр авылның үз билгеләнгән вакытында хөрмәтле аксакаллар авыл яшьләре җыйган бүләкләрне мәйданга алып килгән. Бу да үзенә күрә бер тантаналы мизгелләрдән. Иңбашларына бүләкләр элгән колгаларны салып, агайлар мәйданга узган. Һәр ярыш, һәр уен өчен бүләкләр алдан ук билгеләп, аерып куелган. Сөлгеләр колгага матурлыгына, байлыгына, зурлыгына карап эленгән. Колга очындагысы – иң матуры, затлысы, кыйммәтлесе. Беренче сөлге – җиңүчегә!

Иң матур киемнәрен киеп, авылның яше-карты, кунаклар – кем җәяүләп, кем җигүле атларга утырып, кем – ялгызы, кем гаиләләре белән Сабан туе мәйданына агылган. Әле анда, әле монда гармун тавышы, дугалардагы кыңгыраулар, дирбиялардәге шөлдерләр чыңлаганы ишетелгән.

PRESSA

Бәйрәмгә кадәр йорт-җир юылган, каралты-коймалар яңартылган, самавырлар ком белән ышкып агартылган.



Татар халкының тагын бер күркәм йоласы – бәйрәмгә һәркем яңа кием юнәтергә тырышкан.

Уеннар

Мәйдандагы уеннар гасырлар буена килгән тәртип буенча уздырылган. Бәйрәмне ат чабышы башлап җибәргән. Бу ярышта катнашу бик дәрәҗәле саналган, шуңа да аты булганнарның берсе дә читтә калырга теләмәгән. Җайдак итеп 8–12 яшьлек малайларны утырткannар. Ат чабышында катнашучылар җыелышып беткәч, аларны авылдан 5–8 чакрым читкә алып китеп, ярышка старт бирелгән. Куркынычсызлыкны күздә тотып, чабыш атлары киләсе җир мәйданнан читтәрәк билгеләнгән. Шулай да җиңүчеләр халык күз алдында бүләкләнгән. Атлы җайдакларның мәйдан әйләнүләре үзе бер матур манзара булган.

Безнең халыкта әле тагын бер гадәт бар – иң актыктан килгән атка бүләк бирү. Тормышларында берәр авырлыкка тарыганнар, актык килгән атка бүләк бирер идем, дип, нәзер дә әйтә торган булганнар. Ат чабышы, аңа әзерлек, җиңүчене бүләкләү күренешләре Галимҗан Ибраһимовның «Алмачуар» әсәрендә бик тәфсилле итеп тасвирлана.

Кайбер авылларда Сабан туеның беренче өлеше ат чабышы белән тәмамланган, халык өенә кайтып, тамак ялгап килгән. Калган уеннар төштән соң уздырылган. Күпчелек җирдә исә атлар чабышка киткәннән соң, мәйданда уеннар дәвам иткән. Уенда катнашучылар яшенә карап бүленгән – малайлар, ир-егетләр, картлар. Соңгылары йөгерешкә дип махсус әзерләнгән – чабарга комачаулый торган кием-салымнарын салып, чалбар балакларын оекбаш балтырына җыйган яки бау белән бәйләгән.

Ат чабышы, йөгерү, көрәш – Сабан туеның төп уеннарыннан.

Көрәш

Билбаулы татар көрәше – Сабан туеның иң кызган мәле. Көрәшче үз сөлгесе белән көндәшенең биленнән алып, аны аркасына күтәреп салырга тырышкан. Тамашачылар көрәш мәйданын әйләндереп түгәрәкләнеп утырган. Көрәшне һәрвакытта да малайлар башлап җибәргән. Бу традиция бүген дә дәвам итә. Көрәш батырны ачыклаганчыга кадәр бара. Берничә кешене рәттән еккан егет батыр дип санала. Җиңүчеләр берничә булса, алар соңыннан үзара да көрәшә. Батырлар көрәше – бәйрәмнең иң дулкынландыргыч мизгелләреннән.

Җиңүче егеткә бүләкнең иң затлысы – чигүле сөлге һәм тәкә. Баш батырга тәкә бүләк итү гасырлар буена сакланып, хәзергә кадәр килеп җиткән традиция. Көрәш мизгелләрен тасвирлаган рәсемнәр безнең эрага кадәрге III–I гасырларга караган археологик табылдыкларда да очравы мәгълүм. Ул шулай ук кайбер төрки әдәби чыганакларда очрый.

Ә кайбер авылларда, мәсәлән, Мамадыш өязенең Татар Икшермәсе һәм Иске Икшермә авылларында Сабан туе үзгәрәк форматта узган. Бирелгә буялган йомыркаларны башта – балалар, алардан соң яшьләр җыйган. Иң ахырдан өйдән өйгә кереп йомырка җыярга картлар чыккан. Җыелган йомыркаларны бер чиләккә сала барганнар. Кайчагында меңәр йомырка җыелган. Соңыннан авылның бар халкы басуга чыгып, йомыркаларны җиргә чәчкән һәм мөселманча күмәк дога кылган. Басуга хәер чыгару дип атаганнар аны. Иген бөртекләре йомырка шикелле эре булсын дип теләк теләгәннәр.

Кичке уен

Яшьләрнең кичке уены – Сабан туеның аерылгысыз өлеше булган. Кичке уен бәйрәм узган җирдә яки яшьләрнең уеннары үтә торган традицион урында – чишмә буенда яки болынлыкта, әрәмәлектә кояш баегач оештырылган. Таңга кадәр монда җыр-гармун тавышлары тынмаган. Төрле уен коралларында уйнарга маһир егетләр хәтта үзенә күрә ансамбльләр дә оештырган. Иң популяр уен кораллары булып гармун, скрипка, көпшә курай саналган. Ә уйналган уеннардан түгәрәк уен, таклы уйнау, көтүле уйнау, тәкәле уйнау дигәнне атарга мөмкин. Кичке уенда егетләр белән кызларның бергә булуы да гаепкә алынмаган. Яшьләрнең күңел ачканын карарга хәтта өлкәннәр дә җыелган.

Кызларның кулга-кул тотынышып биюләре дә сакраль мәгънәгә ия. Түгәрәк уеннарына кызлар күп булып җыелып чыксалар һәм кырда иген дулкынланган кебек хәрәкәтләр ясасалар, уңыш та шул кадәр яхшы булыр дип ышанганнар. Кичке уеннар печән өстенә кадәр дәвам иткән.

Сабан туе, җыен, кичке уеннар – авыл халкы тормышының иң ямьле мизгелләре булган. Хәер, ник булган? Сабан туе – бүген дә халкыбызның иң яраткан бәйрәме.

Фотолар: Арча районы Кышкар авылы клубы архивыннан.



« Видео: Арча районы Кышкар авылы клубы һәм Актаныш районы Иске Байсар мәдәният йорты архивыннан.



ДИН ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕН БЕРЛӘШТЕРГӘН ҖЫЕН











– Инде күп еллар Бөтенроссия татар дин әһелләре җыены Россия төбәкләре дин эшлеклеләрен берләштерә. Россия Президенты да мөселманнарның җәмгыятьтә милләтара тынычлыкны һәм татулыкны ныгытуга, мәдәни күптөрлелекне саклап калуга, илебезнең өстенлекле мәнфәгатьләрен яклауга зур өлеш кертүләрен билгеләп үтте...

Россия Федерациясе хөкүмәте рәисе урынбасары Марат Хөснуллин Казанда быел уникенче тапкыр узган җыенга әнә шундый бәя бирде. XII Бөтенроссия татар дин әһелләре җыены Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм иткән көннәргә туры килде: Марат Хөснуллин исә әлеге бәйрәмне әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты рәисе дә иде.

Җыенга 5 чит илдән, Россиянең 76 төбәгеннән һәм Татарстанның район-авылларыннан 1100 дин әһеле һәм кунаклар чакырулы иде. Пленар утырышка кадәр, җыенда катнашучылар Казанда сафка бастырылачак Җәмигъ мәчете төзелешенә истәлек ташы кую тантанасының шаһиты булдылар – шул урында беренче җомга намазы укылды. Сүз уңаеннан, Татарстанда күп кенә мәчетләр халык ярдәме белән төзелә. Яңа Җәмигъ мәчете төзелешенә дә теләгән һәркем үз өлешен кертә алачак: моның белән «Игелек–Доброта» хәйрия фонды шөгыльләнәчәк. Истәлек ташы кую тантанасы вакытында бу хакта Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та әйтеп узды.

XII Бөтенроссия татар дин әһелләре җыенының пленар утырышы М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында үтте. Анда Россия Федерациясе хөкүмәте рәисе урынбасары Марат Хөснуллин, Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Татарстан Президенты Аппараты җитәкчесе Әсгать Сәфәров, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев, Россиянең Югары мөфтие, Россия Үзәк Диния нәзарәте рәисе Тәлгать хәзрәт Таҗетдин, Россия Мөфтиләр шурасы һәм Россия мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти шәех Равил Гайнетдин, Россия мөселманнары Дини җыены рәисе мөфти Әлбир хәзрәт Крганов, Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте башлыгы, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм башка танылган дәүләт эшлеклеләре, дин әһелләре катнашты.

Чыгыш ясаучылар ислам diненең үсеш тарихына тукталды, рухи яңарышның төп билгеләрен атады. «Бүгенге көндә республикада ике меңгә якын мәчет эшләп килә. Рамазан һәм Корбан гаетләре дәүләт дәрәҗәсендә бәйрәм итеп билгеләп уздырыла. Теләгән кешеләр хаҗга бара ала, укыйм дигән кешегә мәдрәсәдән башлап академиягә кадәр юл ачык. Яңартылган борынгы Болгар каласы республиканың рухи яңарышын күрсәткән иң мөһим билге булып тора. Изге Болгар җирендә Ак мәчет белән Ислам академиясе төзелде. Болгар шәһәрен Бөтендөнья мирасын саклаучы ЮНЕСКО оешмасы үз канаты астына алды», – диде пленар утырышны алып баручы Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев.

Җыенга килгән делегатлар хәләл индустриянең «Russia Halal Expo» халыкара күргәзмә экспозициясе белән таныштылар. Икенче көнне исә «Изге Болгар җыены»нда катнаштылар: әби-бабаларыбыз яшәгән, ислам динен кабул иткән тарихи урында меңләгән кеше җыелып алар рухына дога кылды.

Фото: Рамил Гали

PRESSA



Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА

Гөлшат Зәйнашеваның бер истәлеге сакланып калган: «Язучыларның Тукай исемендәге клубында булган бер әдәби кичәдә яшь кенә шагыйрә Эльмира Шәрифуллина «Елмайыйк без, кызлар!» дигән шигырь укыган иде. Артык сурәтләүләрсез генә, самими бер хис белән, балаларчарак язылган бу гади генә шигырь тыңлаучыларның күңеленә хуш килгән иде. Шигырьне өлкән шагыйребез Хәсән абый Туфан, яратып, сәхнәгә менгән иде. Эльмираның кулын кысып, болай дигән иде ул:
– Елмаеп кер, сеңлем, шигърияткә, елмаеп... Төкле аягың белән!..
...Үзе дә тормышның ачысын-төчесен татыган, шатлыкны да, кайгыны да кичергән Эльмира Шәрифуллинага ана хисләре, бала тәрбияләү мәсьәләләре бик якын. Эльмира аналарның бөеклеген, изгелеген үзенчә ача. Гади итеп, шул ук вакытта кайнар хис белән, үтемле шигъри чаралар белән тасвирлый».

ГАЗИЗЛӘРДӘН ГАЗИЗ КЕМНӘР ГАЗИЗ?

Елмайган иреннән үпсеннәр

Күтәреп күңелем пәрдәсен,
Җил түгел, син кердең, сөюем.
Бу – минем, мәңгегә булсын дип,
Чын итеп, зур итеп сөюем.

Сөешеп яшәгән парларның
Көннәре кайгысыз үтсеннәр,
Күзләре яктылык сипсеннәр,
Елмайган иреннән үпсеннәр.

Елмайган иреннән үпсеннәр,
Юлларга түшәлсен гөлбизәк.
Тизрәк кайт, кайт минем сөюем,
Калдым мин озатып, кул изәп.

Елмайган иреннән үпсеннәр,
Ихластан әйтелсен ярату.
Иң олы гөнаһ ул кемнеңдер,
Ялганлап, йөрәген канату.
Елмайган иреннән үпсеннәр,
Илһамы күзләргә күчсеннәр.
Мәхәббәт күтәрә, үстерә,
Парлылар сөелеп үссеннәр.
Сөешеп яшәгән парларның
Көннәре кайгысыз үтсеннәр.
Күзләре яктылык сипсеннәр,
Елмайган иреннән үпсеннәр!

Нарасыйның алтын чагы

Бала тудыру йорты бу,
Тәрәзәсе – кояш ягы.
Таң сызыла,
Таңның әле бәби чагы.

Галиябану бала тапты,
Тудырганы малай тагы.
Таң ярала,
Таңның әле сабый чагы.

Куенына яткырдылар –
Чын бриллиант, алма багы!
Таңнар ата,
Таңның инде әни чагы.

Хәлил булып үссен, Аллам, –
Бу бриллиант, алма багы.
Таң җәелә –
Нарасыйның пар канатлы
Алтын чагы!

Бала туды

Галибанә яктырып
Ал таң аткан чагында,
Сандугачлар җиһанга
Моң тараткан чагында,
Зилзиләләр куптарып
Үзе яткан карында, –
Җанлыдан җан яралды.
Чәчәкләр баш калкытып,
Нурга төренгән мәлдә,
Бар табигать уянып,
Җырга күмелгән мәлдә,
Бәгырьне парә-парә
Җан ачысы телде дә, –
Җанлыдан җан яралды.

Җанлыдан җан яралды,
Җиргә-күккә, тирә-юньгә
Яңа аваз таралды.
Яңа аваз таралды,
Сират күпере кичкән Ана
Бер рәхәт сулыш алды...
Бар матурдан матуррак,
Кыйммәтледән кыйммәтлерәк,
Үз җаныннан газизрәк
Бала тудырды Ана.
Бүген таңда дөньяга
Кеше тудырды Ана!

Җыр кайта

Күркәм йола,
Бәби кайткан йортка
Бер-бер артлы керә күрше-аршы.
Һәркем ризык белән, аш-су белән,
Китерәләр шулай бәби ашы.
Рәхмәт сезгә, мең рәхмәт сезгә,
Кардәшләрем, түрдән узыгыз.
– Ата-анасы –

Алтын канат белән
Үссен, – диеп, – күрше кызыгыз, –
Телисез ич әнә.
Изге теләк һәркем күңелендә.
Төкле аягың белән, әй, нәни кош!
Аваз салдың бүген өемдә...

Күркәм йола...
Бәби кайткан йортта –
Ягымлы сүз, иркә, наз, кадер.
Бәби кайткан йортта кыш өстендә
Чәчәк ата кызыл канәфер.
Бәби кайткан йортка шатлык кайта,
Сөю, сөелү кайта, нур кайта.
Бәби кайткан йортка
мең мәшәкать белән
Күкрәкләргә тулып җыр кайта,
Җыр кайта!

Бәби мунчасы

Йолалары милләтемнең
Күчә килә кечегә.
Ак әбиләр игътибары
Яңа туган кешегә.

Бәби мунчасы ягалар
Баладан котылгачтын,
Кырык кыл өзелгән газап
Күпмедер онтылгачтын.

Буыннарны сылап, сөеп,
Сыйпап оеш каннарны;
Мунча кертәләр әбиләр
Җан тудырган җаннарны.

Мунча кертәләр әбиләр,
Укыйлар теләк-дога.
Шуңадыр шул авыллардан
Рәхимле җаннар чыга.

Изге җыру

«Йөрәк парәм» диеп җыр башладым,
Бишегенә аның кагылгач.
Гөлләр тама икән телләреңнән,
Сабыеңа шулай табынгач ла,
Сабыеңа шулай табынгач.
Газизләрдән газиз кемнәр газиз? –
Үз баласы газиз анага.
Күкрәгенә сабый сарылганның
Йөрәккәе сыймый далага шул,
Йөрәккәе сыймый далага.
Ак биләүгә төргән нарасый җан –
Сабыйлыгы белән сылу ул!
Дөньяларны иңләп таралган җыр –
Бишек җыры – изге җыру ул, һай,
Бишек җыры – изге җыру ул!

Галиҗәнап әнкәй

Алиһә дә, ханбикә дә түгел,
Син гап-гади татар килене.
Гомер иткән йорт-җиреңә әллә
Күңелеңнән нурлар иңдеме?

...Бала булып яшәгәнсең башта,
Тапкан, баккан газиз әнкәңә.
Сабый булып барып сарылгансың
Ирек яулап кайткан әткәңә.

Зифа булып үсеп җиткәнсең дә,
Килен булып килеп иңгәнсең.
Ярсу җанлы, дәртле, мәхәббәтле
Иргә хатын була белгәнсең.

Таңнан торып казан аскансың син,
Иген чәчеп, урак ургансың.
Әмма җирнең һәрчак уртасында
Син булгансың һәм нык торгансың.

...Итәк тулы уллар, кызлар әнә –
Ничә җанга ана син хәзер.
Син алиһә – безнең дөньябызда,
Тезләнергә әзер, бир әмер.

Син – патшасы безнең яшәешнең,
Күпме йөрәк сиңа тоташа.
Синең сөю көчле иткән илне,
Алып чыккан янган ут аша.

Син – гап-гади татар килене бер,
Син – гап-гади татар хатыны.
Син – иң бөек яшәү чыганагы,
Галиҗәнап әнкәй, алтыным!..

Кендек әбекәем

Якты дөньяга кабул итеп
алган кендек әбием
Симәк авылының халык табибы
Хәмдевафа Вәҗиевага

Кышлар җитсә, ап-ак мамык карлар
Кабереңә синең түшәлә.
Олыгайган саен борчый хәтер,
Тынгы бирми төнге төш мәллә?

Күз алдымда кендек әбекәем –
Үткәннәрне барлап уй ага.
Ярты авыл халкын синең куллар
Кабул итеп алган дөньяга.

Ап-ак төскә киендерде сине
Кадер киче,
Туйлар,
Гаетләр,
Ак намазлык өсләренә чүккән
Ак җаныңны кемнәр гаепләр?

...Бәби тоткан кендек әбекәем
Ераклашкан саен янәшә.
Кендекләрне кистең,
Җиргә тектең –
Истәлеккә күчеп, мең яшә!

Вакыт җиткән

Вакыт җиткән,
Яучылары белән
Юлга чыккан инде юртаклар.
Кызларымны туйлап биргән чакта
Шатлыгымны кемнәр уртаклар?

Егет куенына кергән мәлдә
Алтын алма кебек кыз балам,
Мин тартынып кемгә сыенырмын,
Кемгә серем сыяр, йә Аллам?

«Ир шәүләсе – гарше күләгәсе»,
Саклап торыр яман күзләрдән.
Сөелеп кенә яшәсәгез иде,
Өстен булып бәгъзе сүзләрдән.

Без күрмәгән бәхет сезгә булсын,
Балда, майда йөзсен кулыгыз.
Бер-берегезгә дөнья бәһаседәй
Олы бәя биреп торыгыз!

Заман баласы

Куе булып үскән кара чәчем
Сибелеп-сибелеп очты җилләргә.
«Яулык бәйлә, балам. Башың сызлар –
Чәчкәеңне җилгә җибәрмә!» –

Диде әнкәй.
Яулык бәйләмәдем,
Чәчләремне кошлар апкитте.
Шуңадырмы,
Башым гел әйләнде,
Бер үпте дә дөнья, ун типте.

Типте дөнья.
Кагын-сугын йөртте –
Уй корабым комга утырды.
Әйбәт итеп сөйләрлекне бераү –
Гайбәт итеп дөнья тутырды.

Күңелемнең бетте тынычлыгы,
Башым сызлый,
Юктыр чамасы.
Без шул –
Чәчне генә түгел,
Ана сүзен
Җилгә очырган заман баласы...



БӘБИ ИСЕ



Миләүшә
КАҺАРМАНОВА

(Хикәя)

Чак түзде Асия. Өйдәгеләр белән хушлашып чыгып, машинага утыргач та ярсуын басалмады. Янәшәсенә көлә-елмая кереп утырып, күңелле көй куеп җибәргән иренә яндырып карап куйды:

– Тавышын яп! Болай да баш авыртты.

– Бармак башыдай баланың шаяруына да башың авыртса инде. Әнә, Гөлназ көне буе шуларның өчесе белән, бер җире дә авыртмый, – диде ире.

– Кеше хатынының кай җире авырта-авыртмавын син каян беләсең?

Ире, гадәтенчә, эндәшмәде, хатынының тузынуын җавапсыз калдырды. Моңа хатыны да канәгать. Чөнки ире вакланмый, хатын-кыз түбәнлегенә төшми. Йә ишетмәмешкә салыша, йә үз уена чума. Юл уңаенда ире кибеткә сугылмакчы булып туктады. Ял көнне дуслары белән балыкка барырга сөйләшкәннәр иде бит, азык-төлек аласы бар. Асиянең исә балык кайгысы китте, күңелендәге ярасы ачылды. Мәңге төзәлмәс ярасы...

Баласыз алар. Яшәүләренә дә ундүрт елдан артты инде. Укыган, хәлле кешеләр буларак, кыйммәтле клиникаларда да тикшерү үттеләр, дәваларның кирәген дә, кирәкмәгәнен дә кабул иттеләр. Хатыны имчеләрне дә калдырмады. Әйтүләренчә, икесе дә сау-сәламәт, өметне генә өзәргә ярамый. Тик ул өметне яшәтү өчен көчен генә кайдан алырга? Асия үзе күнәр иде дә, ирен ничек итеп һаман да буш өмет белән алдамак кирәк? Әнә бит бая танышларында бәләкәй бала күрүдән уенчык тапкан көчек хәленә төште. Әле генә тәпи киткән сабыйны ятып та, тезләнеп тә уйнатты. Хәтта чәй артына да утырмады бит, суынып беткән чынаягын кабаланып кына чөмереп китте. Шул сабыйдан ары бернәрсә дә күрмәс хәлгә җитте. Асиянең бар әйберсе дә бар үзе. Машинасы да бар, хан сараедай йорты да, кала үзәгендә фатиры да, яхшы эш хакы алып кайта торган ире дә... тик менә баласы гына юк. Һәм шул бәләкәй генә «юк» бүген күп «бар»ның бәһасен төшерә.

...Кайткач, Асия учын иягенә терәп, бертын ирен күзәтеп утырды да, төптән сыкрап чыккан газаплы да, бер үк вакытта җәлләгән дә тавыш белән:

– Тәлгать... сиңа баласыз кыенмы? – дип сорады. Ире, моңа кадәр дистәләрчә, йөзләрчә тапкыр булган кебек, килер дә чәченнән, аркасыннан сөеп тынычландырыр дип көтте. Көтте.

– Кыен.

Әкрен генә әйтте моны ире. Тик өзеп, ышанычлы итеп. Каршы эндәшә, сүз куерта алмаслык итеп. Ә бит белә иде ул бер килеп шундый җавап булырын. Әлеге дә баягы үлә алмый тарткалашкан өметнең соңгы кылларын зыңкылдатып өзә алгандай ниндидер бер сүз барлыгын... Һәм ул әйтелде...

Кыен... Димәк, аңа бу йортта, бу дөньяда баласыз кыен. Димәк, Асиянең сөюе генә аның күңел бушлыгын тутыра алмый... Димәк, шатланганда-куанганда да, иркә-назда, яхшы тәрбиядә булганда да аңа барыбер кыен... Хатын үзе төйнәп ташлаган төенне чишәргә маташып, чәбәләнгән саен аны ныграк чуалтты, бутады. Шулай күзләрен түшәм бизәкләрендә йөртеп ята торгач, башына кинәт бер уй килде: тукта, апасына барып кайтсын әле, бәлки, берәр киңәш бирер, һичьюгы күңелен бушатыр.

...Айсылу апасыннан өч яшькә генә кече булса да, Асия аны олы итеп кабул итте нишләптер. Бәләкәй чакта апасы аны баштанаяк үзе карады дисәң дә, артык булмас иде. Әнисе ике ел саен бәби алып кайтып, шулар мәшәкатеннән бушый алмады. Инде үсмерлек чорына кереп барганда

Асия әнисенең бу эшен ваемсыз рәвештә хәерчелек үрчетү дип бәяли иде һәм еш кына мәктәптән кайтып кереп, кичә генә җыештырганнарын баштүбән әйләндергән эне-сеңелләрен әрләгәндә, әнисенә дә өлеш чыгарды:

– Бернәрсәгә файдасыз нәрсәләр! Өй туздырудан башкага ярамыйлар! Нәрсә дип алып кайттың шушыларны! Берәүдә дә бу чаклы бала юк!

Әнисе, юашлыгыннанмы, әллә чынлап та гамьсезме, кызының ярсып чәрелдәвенә игътибар да итми: һаман да сабыйлары белән кайнаша.

Бәләкәй чагында ничек йөргәндер, әмма мәктәпнең әле башлангыч сыйныфларында ук киеменең башкаларныкына караганда кайтыш икәнлеген аңлады. Зурая төшкәч, бу хәл тагын да кимсетте кызны. «Күп балалы гаилә, җиткерә алмыйлар, авыр яшиләр», – дип жәлләп караулары исә авырткан сөяленә басып торган кебек булды. Ул кече туганнарына катылыгы белән аерылды. Дәфтәр-китапларын туздырсалар, күп сорап тормый чыбык белән сыдырды, эшкә кушканда тискәреләнсәләр дә суктырды. Чисталык яраткан, тәртип тотуга омтылган бала иде ул. Туганнарын кыйнап эшләтте, әрләптукмап җикте. Аннан хәтта әнисе дә шүрләде бугай. Балалардан бизеп, тәмам гарык булып үсте кыз. Шулар артыннан чистартып, юып-җыеп, бишек селкетеп үтте үсмерлек чоры. Башкалар кебек иркәләнеп, ваемсыз гына яши алу мөмкинлегеннән мәхрүм иткәннәре өчен күралмас хәлгә җиткән чаклары да булды аларны. «Минем балам булмаячак, ялгыз яшәячәкмен», – дип әйтә иде. Сабый күрсә, сөйми түзә алмаган дусларына аптырады: ничек шуларны яратмак кирәк?

Югары сыйныфларда башкаланың интернат-мәктәбендә укыды. Монда да аның кебек күп балалы гаилә балалары, ятимнәр тупланган иде. Аннан югары уку йортына укырга кергәндә дә әнә шул «күп балалы» гаилә әгъзасы булуы ярдәм итте – конкурссыз-нисез кабул ителде.

Тәлгать белән башкалада танышты. Җырлап-көлеп, яшьләрнең уртасында йөргән егет ник кырыс карашлы бу чибәркәйне сайлагандыр. Әнә шул салкын матур йөздә елмаю ишарәсе күрү, җыерылып торган нәзек кашларны бераз булса да яздырып җибәрү, энҗе тешләрне көн нурында ялтырату өчен тырышлыгын аз салмады ул. Асиягә дә бу ачык күңелле егет бик ошый иде. Тик ул: «Егет белән дуслашсаң, аңа кияүгә чыгарга кирәк, чыксаң – балалар», дигән уйдан кача алмый һәм шунлыктан үзеннән бер генә җылы караш, ым-ишарә көтеп зарыккан егетне нишләтергә дә белми. Ә егет беркөн килеп эшне кабыргасы белән куйды:

– Асия, мин сине аңлый алмыйм, кирәкме мин сиңа, әллә юкмы? – дип әйтеп салды Тәлгать, җитәкләшеп парк аллеясыннан атлаганда.

– Нишләп... алай дисең? – кыз сорауга сорау белән җавап бирде.

– Кумыйсың да, якын да җибәрмисең... Миннән уже егетләр көлә.

Кыз эндәшмәде. Ул мондый хәбәргә әзер түгел иде.

– Йә, ник тындың? Кирәкме мин сиңа, юкмы? «Юк», дисәң, китәм...

«Нәрсә әйтергә соң?.. Юк! Ул Тәлгатьне югалтырга теләми! Яратамы? Белми... Ничек соң ул ярату?.. Тәлгать аңа кирәк, аңа сыенасы, аркаланасы, иркәләнәсе килә. Ул бит беренче тапкыр үзен кадерле итеп тойды...»

– Әй...йе, – тавышы ишетелер-ишетелмәс иде Асиянең.

– Нәрсә «әйе»?

– Кирәк син... миңа.

Дуслашканнан алып тәүге иң җылы һәм иң иркә сүзләрне ишетте егет. Гүя «кирәк син» дип кенә түгел, ә «Яратам! Синсез яши алмыйм!» – диде кыз. Шатлыгыннан сөйгәнен кочагына тартып алды:

– Алай булгач, өйләнешәбез! Киләсе атнада!

– Ничек өйләнешәбез?! – Асия дерт итеп калды. – Кем әйтә!

– Мин әйтәм. Нәрсәгә сузарга? Бергә яшибез, бергә...

– Минем бала карыйсым килми! Минем... Мин...

– Ярый, үзем карармын. Ялкау кәләшем минем, – дип көлде Тәлгать.

* * *

...Кибеттә лимон, конфетлар үлчәткән арада ишек төбендә тарткалашкан яшь ана белән 3-4 яшьләрдәге балага игътибар итте. Бала кибеттән чыкмый карыша, нәрсәдер алып бирүне таләп итә бугай. Асия үзе дә сизмәстән боларга төбәп эндәште:

– Нәрсә алып бирмиләр, ә-ә?!

Кызый нәзек тавыш белән чәрелдәп тә җибәрде:

– Бана-ан!

– Банан булгач, банан. Бирегез әле безгә банан!

Яшь хатын «юк» дип каршы торып маташкан иде дә, бәләкәче бананны күкрәгенә үк кысканны күргәч, уңайсызланудан ни эшләргә белмәде:

– И апа, уңайсыз бит. Монавы мыжый. Рәхмәт, апа, кая акчасын...

– Куй! Юк белән маташма, – Асия кул гына селтәп тышка чыкты. Ул арада сабый нәзек бармаклары белән банан сындырып маташа иде инде.

...Айсылу апасында һәрвакыттагыча күңелле, шаушулы, сыйлы. Тыштан ук борынны яңа пешкән ит исе кытыклый. Әнисе кебек тәбәнәк йомры апасы ашка токмач кисә, кызы коймак коя. Асия, өстәл артына кунаклап, боларның мәшәкатьләрен күзәтә. Аңа эш бирмәделәр, утырып кына торырга куштылар.

– Хәзер аш та өлгерә, – Айсылу сәгатькә карап ала. – Балакайларымның эчләре өзеләдер... Утырдык дип шалтыратсалар да, озаклыйлар әле, юл начар вакыт бит.

– Йөрми торсалар да ярар иде борчып. Атна саен, акча туздырып... катырак әйтеп җибәрмисең инде, – апасын шелтәләп алырга да өлгерә Асия.

– Ничек итеп кайтмагыз дип торасың ачыгышып кына йөргән балаларга! – Айсылуның студент улларына сүз тидерәсе килми.

– Азрак ачыкканнан үлмиләр инде, жәлләмә.

Айсылуның сүз көрәштерәсе килми, хас әниләре мәрхүм инде, шунда ук икенче хәбәргә күчә дә китә:

– Теге синнән алып кайткан гөл, ни, хәтәр үсте дә китте, бар, күр әле.



Гөл үстерә алмый шул Асия. Утырткан бере сула, сатып алган йә бүләк ителгәннәре утыра-утыра да үлә. Монысын да чыгарып ташларга дип куйган җирдән апасы күреп алып китте. Шул гөл күкрәп утыра менә. Хикмәт инде. Карашы гөлдән тышка күчте: бая кибеттә күргән яшь хатын баласын уйната.

– Яңа гына шушы бала кибеттә банан таптырды, әнисе алмый.

– Ничек банан сатып алсын ул, чак көн күрә, – дип куйды Айсылу.

– Нишләп? Эчкечегә охшамаган бит, – Асия тагын тәрәзәгә төбәлде.

– Үзе эчмәсә ни, әнисе эчә, әнисенең икенче ире эчә, баласы бәләкәй, эше юк, – Айсылу, шулай тезә-тезә, аш бүлмәсенә кабаланды.

Ул арада шаулашып студент уллары кайтып керде. Апасының шуларны кочып-кочып сөйгәнен, өстәл артында кыстап-кыстап ашатканын сәерсенеп, хәтта бераз үртәлеп күзәтте Асия. Иркенләп сөйләшергә җай тимәсә дә, сеңлесенең кәефен сизгән Айсылу, озата чыкканда: «Кияүне әбижәйт итмә», – дип, уенлы-чынлы әйтеп калды. «Сиздә микән?.. Сизеләдер шул...»

...Беркөн эштә компьютерындагы таблицаларга сибелгән саннарны чүпләп күзе-башы тонып утырганда, секретарь Әкълимә килеп керде дә, башка кызларга ишеттермәскә тырышып, колагына пышылдады:

– Бер нәрсә алып килгән идем, миңа кереп чык әле.

«Нәрсә» дигәне газета икән. Хатын газета битен әйләндергәләде:

– Нәрсә бар монда?

Әкълимә озын тырнаклы бармагын бер рекламага төртте:

– Менә моны яхшылап укы. «Аналар һәм балалар» елына багышланган яңа программа буенча бәби ясау быелгы елда бушлай була дигән.

Асия бер кызарды, бер агарды. Шулай да ярсымаска тырышып, теш арасыннан кысып чыгарды:

– При чем тут... Кирәк булса, акчага да ясата алам.

– Анысы шулай инде, но выход бит бу, – Әкълимә белдекле кыяфәттә сөйли башлады. – Суррогатный ана табып ясатырга була. Ул бит барыбер сезнең генә була, ирең белән синеке инде то есть.

– Уф, куй әле, Әкълимә, булмастай белән баш катырып йөрмә.

– Буш түгел ул, Асиюш, уйла әле син. Хәзерге заманда бала табып бирүче хатыннар аз түгел, ди ул, акчага бөтен нәрсә дә сатылган вакыт бит...

Әкълимә ишектән чыкканчы ияреп килеп сөйләп калды. Асиянең саруы кайнап китсә дә, башында баягы сүз тукран кебек чүкеп барды: «Суррогат! Суррогат! Суррогат!»

...Тәлгать, ялларын балыкта үткәреп, күңеле күтәрелеп кайткач, телевизор карап ятты-ятты да, кинәт: «Әйдә, приюттан бер малай алыйк», – димәсенме.

Битенә маска сылап утырган хатыны аңа көзге аша төбәлде. Ире аның аптыраган сораулы карашын шулай ук көзге аша тотты.

– Нигә аптырыйсың? Шушылай тик утырып үткәрәбезмени гомерне?

Хатын исе китмәгәнгә салышты:

– Тик утырмыйбыз бит, көне-төне эштәбез. Ул баланы кем карый?

Ирнең тавышы капыл ыркуланды:

– Син! Кирәк булса – мин! Бер бала карый алмаслыкмы без?!

Асия тынып калды. Чөнки белә – бу мәсьәләдә ул көчсез. Юк, приюттан бала алырга теләми ул. Чит баланы гомердә дә ярата алмаячак! Кинәт Әкълимә әйткәнне исенә төшереп, шул «салам»га ябышты:

– Бик теләсәң, әйдә суррогат әни эзлик... Бала үзебезнең каннан була.

Тәлгать яткан җиреннән торып ук басты:

– Анысы ничек була тагын?

– Ну-у, бездән алынган орлыклар ясалма аталандырыла да суррогатның корсагына салына – вот и все.

Хәзер инде ире бертын дәшми утырды. Башына сыйдыра алмады, күрәсең, мондый яңалыкны. Ахырда чак телгә килде:

– Алай законлымы соң?

– Медицина рөхсәт итә бит. Әнә, телевизордан сөйләп торалар.

– Һе... – Тәлгать бер утырды, бер торып бүлмә буйлап йөренде. Аннан кабаттан хатынының каршына килеп басты. – Андый хатынны кайдан аласың, Асия? Кем кешегә бала табып бирә? Чит илдә генәдер андый әкият?


– Нишләп булмасын? Эшсез, акчасыз хатыннар белән дөнья тулы.

Тәлгать әйләнеп китеп, тагын бер урап килде дә, хатынының алдына чүгәләп торып күзләренә төбәлеп ялварды:

– Алай булгач, тап син шундыйны, Асия, тап, яме. Мин хакыннан тормам. Бармак башыдай бала өчен шушы өйне дә бирергә риза.

Хатын, хәлнең чынлап та аяныч һәм котылгысыз икәнлеген аңлап, керфекләрен кагып ризалыгын белдерде. Ире аның аякларын кочаклап, йомры тубыкларына йөзе белән капланды. Кырыкка җитеп барган ирнең тау кебек иңбашы, аркалары калтыранды. «Елыймы әллә? Алай дисәң – яшьләре юк». Ирләрнең күз яшьсез генә елый алуын белми иде Асия.

...Хатынның башын хәзер бер сорау бораулый: кайдан суррогат ана табарга да кемне ялларга?! Ике атна үзалдына нәтиҗәсез көяләнгәннән соң, башка чара тапмыйча, әлеге дә баягы апасы белән киңәшләшергә булды. Барып җиткән иде дә, Айсылу телефоннан эш белән чыгуын, бер ярты сәгатьтән генә кайтасын әйтте. Асия машинасы эчендә тирә-якны күзәтергә кереште. Талгын көйләр дулкынында оеп утыра торгач, кинәт каршы барактан теге танышлары килеп чыкканны шәйләп алды. Яшь хатын 3-4 яшьләрдәге баласын нишләптер күтәреп алган. Менә ул, эскәмиягә утырып, баласын алдына җайлап салды. Бала йоклый, күрәсең. Асия бу күренешне бераз күзәтеп утырды. Теге хатын да


Рәсем: Наталья Васильева

уйга батып утыра бирде. Шул вакыт Асиянең күңелендә шайтаннар уйнады. Нәрсәгәдер өмет итеп, нәрсәгәдер омтылып, машинасыннан төште дә хатын ягына юнәлде.

– Саумысыз? – баш кагып кына сәламләде яшь хатын, күтәрелеп тә карамады ичмасам.

– Сеңелкәш, син мине танымыйсың, ахры, – Асия, кыяфәтенә уңайсызланган төс чыгарып, хатын янәшәсенә чүгәләде. Шул чакта гына тегесе, исенә килгәндәй, карашын аңа күчерде.

– Сез?.. Гафу итегез... Кинәт танымадым.

– Гаеп юк. Прогулкамы?

– Про...гул-ка...

Яшь хатын тынычсызланып шыңшыган бәләкәчен алдында тирбәтте.

– Тшш-тшш, бәбчегем... Тшш-тшшш...

Тик бала күзләрен ачып ук шыңшырга кереште:

– Әни-и-и... Эчем авырта-а...

Хатынның яшьләре атылып чыкты, ул өзгәләнеп баласына иелде:

– Чулпан, бәләкәчем, елама, яме... Йокла, кызым, йокла.

Йоклап буламы инде! Баягыдан да ныграк кыбырсымакчы. Утыра торгач, баласына әнисе дә кушылды. Икәүләшеп балавыз сыкмакчылар. Бу күренешне сәерсенеп күзәтеп утырган Асия, капылт торып, балага үрелде:

– Кая әле, сеңелкәш, болай елашып утырып булмас, бир баланы, киттек.

Өметсезлекнең чигендә булган яшь ана берсүзсез аңа иярде.

...Айсылу ишек ачып сораулы карашын төбәгәч тә:

– Айсылу апа, Чулпан авырый шикелле, – дип сулкылдады әни кеше.

Хәлне бер күз сирпүдә үк аңлап алган Айсылу, баланы диванга салып, чишендереп ташлады, буыннарын уксус эретмәсе белән уды, җылы чәйгә кушып дару эчерде. Аннары чиста җәймәгә урап, әнисе алдына салды:

– Ипләп кенә тирбәт әле, хәзер тирләп йоклап алса, бераз җиңеләер.

Күп тә үтми кызкай мышнап ук йоклап китте. Баланы юрган астына салгач, хатыннар аш бүлмәсенә чыкты.

– Әйдә, җитеш, Ләйсән, балаң йоклаганда ашап ал, кыенсынма.

Ләйсән бер Айсылуга, бер Асиягә карашын күчерде:

– Сез туганнармы әллә, Айсылу апа?

– Әйе. Охшаганбызмыни? – Айсылу, көлеп, сеңлесенә карады.

– Нык ук булмаса да, танырга була, – Ләйсән рәхмәтле күзләрен Асиягә төбәде. – Сез, апа, теге вакытта да ярдәм иткән идегез, бүген дә...

...Ашап алгач, Ләйсән китәргә җыенса да, Айсылу җибәрмәде, баласы янына кереп ятарга кушты. Йончыган хатын артык карышмады, мендәргә башын



терәүгә күзләре дә йомылды. Айсылу белән Асия озак кына сөйләшеп ятты. Кызның аянычлы язмышы хакында сөйләде апасы. Шунда Асиянең башында бер уй яралды. Тора-бара үзе дә шул уй эчендә йөри, яши башлады. Шул уйны дөньяга ашыру планын корды...

Киләсе юлы хатын Ләйсәннең кызы белән чыкканын сагалап торып, машинасына утыртып алып китте дә, кала уртасындагы кафега алып барды. Тәмле ризык белән сыйлады, юк-бар сөйләп мавыктырды. Кайтканда уенчык кибетенә алып керергә дә онытмады. Ләйсән яңа танышына һушы китеп, сокланып карады. Аңа бу ападагы бар нәрсә ошый иде: үзен ышанычлы, иркен тотуы да, заманча киенүе дә, машина йөртүе дә, бераз һавалырак булуы да. Модалы прическасы, матур сумкасы, ялтырап торган кыска чәшке туны, колагындагы әллә нинди ташлардан эшләнгән алкалары, муенындагы алтын чылбыры – бар да хатынны буй җитмәс югары итеп күрсәтте. Кибетләрдә әйбернең хакына күз дә салмавы, күңеле ятуына карап сайлавы да, сатучыларны йөгереп йөрергә мәҗбүр итәрлек сөйләшә белүе дә, кафеда салат яшелчәләреннән хуш ис чыкмаганы өчен генә дә алмаштырып бирүләрен таләп итүе һәм аны берсүзсез үтәүләре дә язмыш типкесендә йөреп хәлдән тайган Ләйсәнне тәмам әсир итте. Асиянең һәр кыланышын, хәрәкәтен йотып, сөйләгәннәренә кыюсыз гына елмаеп баш кагып утырды.

Аерылышканда, хатыннар якын ахирәтләр кебек хушлашты. Ләйсәннең күптән булмаганча күңеле рухланып, үз-үзенә ышанычы артып китте, кәефен хәтта әнисенең чәче-башы тузып исереп ятуы да боза алмады. Почмактагы бәләкәй караватка инде ойый башлаган баласын салды да «бәү-бәү» дип көйләргә кереште. Үзе һаман Асия апасы хакында уйлады, чибәр ханым берничек тә аның күз алдыннан китмәде. Кичен яткач та әле аның: «Баладан башка бөтен нәрсәм дә бар, бер бәләкәч сабый бирми бит Ходай», – дип, атлаган саен кызын тупылдатып сөюен хәтерләп, «Аптырарсың бу дөньяга, сөт өстендә каймак кебек яшәр җиргә бала бирми», – дип уйланып ятты.

...Ләйсән шушы җимерек баракта үсте. Коридор очында яшәгән Аня әби белән үзен исәпкә алмаганда, мондагыларның барысы да кулларына акча килеп керү белән көннең йә төннең теләсә кайсы вакытында – яңгырда да, буранда да яндагы сыра лавкасына йөгерә торган кешеләр. Аларны баракларында коридор идәннәренең череп ятуы да, подъезд ишегенең каерылып төшүе дә, түбәнең яңгыр үткәрүе дә, суның, газның күптән ябылуы да, электр утының да шушы көннәрдә өзелергә тиешлеге дә һич кенә дә борчымый, күрәсең. Берсе дә иртәгә кая китәрен уйлап көяләнми. Аня әби генә: «Мин картлар йортына да бара алам, син нишләрсең», – дип борчыла.

Ләйсәннең әнисе Сәрия балалар йортында үскән, тегү фабрикасына эшкә урнашкач, аңа шушы барактан бүлмә биргәннәр. Бу йортта, чынлап та, кемне алып карасаң да, балалар йортыннан чыкканнар бит. Күршедәге Сергей белән Наташа да шулай ук детдомда тәрбияләнгән. Каршыдагы агач аяклы ир дә, теге Әкълимә дә, әнисе әйтүенчә, алар кебек үк туган-тумачасыз, йортсыз-җирсез адәмнәр. Җыелышып тамак чылаткан саен үзләре: «Кала түрәләре, фатир бирәсе урында, безне шушында китереп тыкты. Бурлар, алдакчылар, безнең өлешне йотты», – дип әрлиләр, әмма мәсьәләне хәл итәрдәе юк.

Ләйсәннең атасы юк, булмаган да. Бәләкәйрәк чакта әнисе янында күпмедер яшәп киткән бер абыйга «әти» дип эндәшә дә иде шикелле. Анысы чыгып киткәч, онытылды. Аннары үзләрендә яшәп чыккан «абыйларның» әти түгел икәнлекләрен аңлый иде инде кызый. Елдан-ел ныграк эчкән әнисен ана хокукыннан мәхрүм итү белән куркытып, үзен вакытлыча приютка алып та киттеләр. Әнисе күпмедер вакыт эчүен ташлап, эшкә кереп, кызын кире юллап алды да, түземлеге озакка җитмәде – яңадан эчте. Бикле калып ач утырган, атналар буе әнисен көтеп ала алмаган, исереклəрдән куркып Аня әбидә йоклаган чакларын исәпләп тә бетереп булмыйдыр. Мәктәпне яхшы гына тәмамлады. Медучилищега керде. Тик укуын тәмамлый гына алмады. ПТУ студенты Раян атна эчендә кызның башын әйләндерде. Ләйсән укуын тәмамлау белән, районга алып кайтып китәчәген, анда эш тә, яшәрләренә зур йортлары да барлыгын кабат-кабат тәмләп сөйли торгач, кыз бу хәлләргә шулкадәр ышанды, хәтта инде үзе дә күп нәрсә турында «авылга баргач» дип хыяллана башлады. Шунлыктан, авырга калуын белдергәч, киявенең суга төшкән кебек юкка чыгуына берничек тә ышана алмады. Егетенең тулай торагы алдында әллә ничә кичен көтеп үткәрде. Ахырда берсе: «Эзләмә, тапмыйсың син аны, күптән укымый да, монда яшәми дә ул, урлашып куылган иде», – дип китте. Шаккатып калды Ләйсән. «Ничек инде укымый? Ул бит «киләсе елга укып бетергәч», дип сөйләде... Аларның бит... мәхәббәт... Ничек инде?..» Авыры беленә башлагач, оялып, укуын ташлады һәм әнисенең ямьсез сүзләр белән каргаганын тыңлап, йомарланып тик ятты. Төне буе тоткан тулгаклардан хәле бетеп, кан күлдәвеге эчендә үлем белән тартышкан кызны Аня әби очраклы гына күреп, ашыгыч ярдәм чакыртты.

...Бүген кызын күтәреп кая китәргә дә белми Ләйсән. Аня әби – хастаханәдә. Әнисе тагын теге Сашкасын керткән. Моннан өч-дүрт ай элек кенә үзен кап-кара итеп тукмап чыгып качкан иде, тагын кайткан. Чулпанын таганда атындыра-атындыра, күңеленнән танышларын барлады. Кемгә куна барырга икән? Ахирәте Гөлкәйгә барыр иде, аларга кунак килгән бугай. Теге йорттагы Сания дигән апада да еш кына йоклап чыккалый иде, тик бу арада күренми ул... Тагын Айсылу апага керергәме... Озак йөрде Ләйсән урамда. Караңгы куергач, бар кыюлыгын җыеп, каршыдагы йортка юнәлде. «Кызын гына туендырса... үзе ашка утырмас, шунда идәнендә булса да йоклатып кына чыгарса, таң белән торып китәрләр». Шулай дип уйласа да, Айсылу апасының кыстап ашатасын да, йомшакка

салып йоклатасын да белә шул. Шуңа да кыенсына. Тик башка барыр урын да, урамда калыр әмәл дә юк...

Барып керсә, Айсылу белән Асия чәйләп утыралар. Асияне күрүгә, җир тишегенә керердәй булды. Хәтта йомыш сораган кеше булып чыгып китәргә иткән иде дә, авызын ачып өлгермәде, Айсылу апасы кызын күтәреп тә алды:

– Кунак өстенә кунак килә миңа бүген, әйдүк.

Үзе Ләйсәннең соңгы көннәрдә юньле йокы да, ашау да эләкмәгәннән төсе качып агарып киткән борчулы йөзенә сак кына карап алды.

– Сездә кунак бар икән, белсәм, бимазалап йөрмәс идем... – Ләйсән кимсенүдән елыйсы килеп торса да, үзен көчләп елмаерга тырышты.

– Дөрес эшләгәнсең, сиңа иртәнчәк барырмын дигән идем әле, – Асия көлеп җибәрде. – Менә бит, бирәм дигән колына – чыгарып куйган юлына. Иртән Чулпан белән сине кунакка алып китәм әле үзебезгә, – димәсенме!

Ләйсән аптырап китсә дә, тәртип йөзеннән сүзсез кала алмады һәм:

– Ку-уй, рәхмәт... Безнең кунакка йөрергә хәл юк, – дигән булды.

– Аның өчен нинди хәл кирәк? Берәр атна торып, безнең каланы да күреп кайтырсыз, үзем китереп куярмын, – дип, Асия хәл итеп тә куйды.

Икенче көнне иртәнге чәйне эчкәч тә, авыз ачарга да ирек бирмәстән, машинасына төяп алып чыгып та китте, ике сәгатьтән йортына алып кайтып та төшерде Асия. Утыра хәзер менә Ләйсән хан сарае кебек ике катлы йортның бер бүлмәсендә. «Шушы бүлмә сезнеке була, менә халатлар, кирәк-яракны барысын да шушында табарсыз, юыныгыз, ял итегез, хәзер аш әзер була», – дип, хуҗабикә үзләрен генә калдырды. Бераз йорт җиһазларын карап утырды, ванна бүлмәсенә кергәч, Ләйсән бөтенләй таң калды. Юыну урыны төшеп йөзмәле, идән-түшәм-стеналары ялтырап тора. Кызы белән арыганчы коендылар, тәннәрен су суырганчы уйнадылар. Күптән таска гына утыртып юындыруга күнеккән бәләкәче шулкадәр арыды, әнисенең киендергәнен дә көтмичә, сөлгегә уралган килеш йоклап та китте. Үзе аш бүлмәсендәге озын өстәл артында, алдына куелган купшы тәлинкәләрдәге төрле ризыкларга карап, үз хәленә үзе ышана алмый утыра менә хәзер. «Әйдә, синең килүең хөрмәтенә, почти ике меңлек вино ул», – дип, Асия бокалларга шәраб коя. «Ой, эчмим мин, Асия апа...» – диюенә дә, тәмләп карарга кушып, кыстый.

Азыгы да, шәрабы да шундый килеште: кинәт бер зары да калмагандай тоелды. Шушы бөтенлектән күңеле тулды. Еламаска тырышып, алдындагы тәлинкә бизәкләренә төбәлеп утыра иде, тәлинкә читенә тып итеп яше тамды... икенчесе тыпылдады. Көлә-көлә нәрсәдер сөйләп утырган Асия, тукталып, бер – тәлинкә читеннән юл салып агып төшкән яшь бөртегенә, бер кызга карады. Карашны күтәрә алмады кунак, түгелеп, сыкрап елап җибәрде.

– Ләйсән... Ләйсәнкәй, нәрсә булды, акыллым?.. – Хатын үрелеп яшь хатынның битен каплаган кулларын тотты. – Йә, йә, бетте... бетте.

Күз яшьләре соңгы уңайсызлану киртәсен агызып алып китте бугай:

– Сез мине жәллисездер инде, Асия апа, оят миңа болай хәерче шикелле йөрүе... – дип, Ләйсән дә ачылды. – Тик нишләргә дә белмим. Эшкә керергә баланы урнаштырып булмый, әнкәй карарлык түгел шул...

Аны тыңлап бетергәч, Асия сак кына сүз башлады:

– Аңлыйм, акыллым, аңлыйм. Эшкә чыксаң да, һөнәрсез көе күпме генә аласың инде! Ни ашарга, ни киенергә җитмәс. Балаң белән яшәр җир дә кирәк. Хәзер жилье кыйбат, ялгыз кешегә хыялланырга да түгел...

– Бер генә дә өмет юк... Үземә кул селтәдем инде, кызымны жәллим.

– Ләйсән... минем сиңа бер тәкъдим бар, – Асия һәр сүзне җентекле сайлап, урынлы куеп кына дәвам итте. – Әгәр дә син аны кабул итсәң, акча мәсьәләсе дә, торак мәсьәләң дә хәл ителәчәк. Үзеңә аерым фатир алып, кызыңны балалар бакчасына урнаштырып, бер зарсыз укып та чыга алачаксың. Аннан үз гаиләң дә булыр әле, кем белә, син бит әле яшь, сылу...

Ләйсән яшь тулы аптыраулы күзләрен хатынга төбәп катып калды. «Нәрсә сөйли ул?.. Нинди фатир?.. Нинди уку?..»

– Мин чынлап сөйлим, Ләйсән, аптырама алай. Тыңла, минем тәкъдимем шундый. Белүеңчә, безнең балабыз юк. Ә ул безгә бик кирәк. Мин үзем таба алмыйм. Безгә бәби табып бирә алырдай хатын кирәк... – Асия бераз гына икеләнде дә дәвам итте. – Менә син әгәр дә шул эшкә риза булсаң, без сиңа фатир сатып алырлык акча бирәбез.

Ләйсән һаман да авызын ача алмыйча шаккатып утыра бирде.

– Авырлы вакытында бездә яшәрсең, балаң янында, тамагың тук, тыныч булыр. Нәрсә телисең, барысын да алдыңа салам. Диңгезгә алып барып ял иттерермен, теләгәнеңне киярсең, алырсың... Ә?..

– Ә... Б-баланы... кайдан алыйм соң мин?.. – диде чак телен әйләндереп.

– Минем һәм иремнең орлыкларын ясалма кушып, синең аналыгыңа урнаштыралар. Син ул баланы күтәреп, үстереп кенә бирәсең, аңлашыламы?

– Аң-ңлашыла ла ул... Аптырыйм... Гомердә андыйны ишеткәнем юк.

– Ләйсән, син кире кагарга ашыкма әле, яме. Әйдә, бер-беребезгә ярдәм итик. Бүген-иртәгә ул баракны җимереп ыргытачаклар, кая барасың? Балаңның киләчәген уйла. Безгә бала тапканыңны беркем дә белмәячәк. Шушында яшәрсең, беркем борчымас, табып бирсәң, теләгән җиреңә китәрсең. Алдарлар дип һич курыкма, авырга калуың белән синең исәпкә акча салып куярбыз. Мине дә аңла... Баласыз инде иремне тотарлык хәл юк, гаиләм таркала...

(Дәвамы киләсе санда.)



«Гомер көземә язлар китерден...»



Фото: Александр Ефремов

Фарсель белән кавышып яши башлагач, безнең турыда язган шигыреннән юллар бу. Ундүрт ел бергә яшәп калдык. 16 августта вафатына бер ел була, ә күңел һаман Фарсельнең юклыгына ышанмый.

Венера ИБРАҺИМОВА

Очрашулар

Фарсель белән беренче тапкыр миңа 15 яшь чакта, Пучыда күрешкәнбез икән. 1957 елда гаиләбез авылдан Калинин районы үзәге Пучыга күченеп килде. Безгә тиешле йорт әле бушамаган, шуның өчен безне бер атнага ике балалы бер апага урнаштырып тордылар. Шул көнне кич йокларга ул йортка хуҗабикәнең авылдашы – Качкыннан бер егет килде. Без, балаларга, урынны идәнгә җәйделәр. Иң кырыйга кунак егетен салдылар. Иртән кунак егете чыгып китте, без ике сүз дә алышмадык. Соңыннан гына аның Фарсель икәнен белдем.

Икенче тапкыр очрашуыбыз тагын кызык кына килеп чыкты. 1961 ел. Мин ВЛКСМның Актаныш райкомында бүлек мөдире булып эшлим. Июнь аеның бер көнендә бәрәңге кәтмәнләгәннән соң, көянтә-чиләк алып суга киттем. Кайтканда артымнан бер егет иярде. «Апасы, юл буе артыңнан кайттым, әйләнеп тә кара-

мадың. Су эчерт инде, тамагым кипте бит», – диде ул. Туктадым да, чиләктән эчәргә куштым. «Юк, чиләктән эчеп булмый инде», – дип, әрсезләнеп, өйгә үк ияреп керде. Бер чынаяк су эчте дә: «Исемең ничек соң, чибәркәй?» – диде. Исемемне әйтмәдем, оялдым. Фатир хуҗам аны белә булып чыкты. Халык авыз иҗаты белән танышып йөрүче Казан студентларының берсе икән.

Өченче очрашу да хәтердә. 1963 елның гыйнварында Актаныш районын Минзәләгә куштылар. Мин комсомолның Минзәлә райкомына инструктор булып күчтем. Аннары бүлек мөдире итеп куйдылар. Шул елның сентябрь аенда Мәскәү янындагы «Аниково» ял йортына юллама бирделәр. Минзәләдән Казанга самолетта очтым. Әнкәем белән саубуллашып торган арада, кулдан чемоданымны бер егет алды да самолетка кереп китте. Артыннан керсәм, чемоданымны «урлаган» ирегет миңа кул болгый: «Венера, сиңа урын алдым, минем янга кил». «Мине каян беләсез?» – дим. «Хәтерлисеңме, миңа Актаныште бик тәмле су эчерткән идең, минем исемем Фарсель, авыл хуҗалыгы институтында укыйм», – ди. Теге чакта су эчәргә сорап артымнан килүе дә очраклы булмаган – ул мине таныган икән. Идәндә бергә ятып йоклаган чакны кызык итеп искә алды.

Казанга килдек, миңа ул башкаланы күрсәтте, шигырьләрен укыды. Ә кичен поездга утыртып: «Баргач хат яз, кайтканда телеграмма бир, каршы алырмын», – дип озатып калды.

«Аниково»да 24 көн ял иттем, бик күңелле булды. Фарсельгә хат язмадым. Ул чакта хәзерге кебек телефоннар юк. Телеграмма да бирмәдем. Ләкин ул барыбер вокзалга мине каршы алырга килде. «Совет» рестораныңда утырдык, аннары Горький паркына барып килдек. Ул мине бүлмәдә калдырып, дусты белән икенче бүлмәдә йоклады. Иртәгесен Фарсель самолетка билет алып, Минзәләгә озатып калды. «Хат яз, Казанга килсәң хәбәр ит», – диде. Хатлар язып карадым, ләкин хәбәр булмады, шулай да бер открыткасы килде. Шулай итеп, безнең мөнәсәбәтләр башланмаган килеш өзелде.

Олыгайган көндә яңа тормыш башлау безгә ничектер оят кебек тоелды.

1966 елда мин кияүгә чыктым һәм Пермьгә киттем. Аннан Түбән Камага кайтып шәһәр партия комитетында (горкомда) бүлек мөдире булып эшли башладым. Гомер узды. 1985 елда янә очраклы рәвештә Фарсельне очраттым. Ул да, мин дә беренче секретарьга керергә чират торабыз. Карасам, таныш кеше. «Фарсель син түгелме соң бу?» – дип, беренче булып мин сүз каттым. Хәл-әхвәлләр сораштык. Ул авыл хуҗалыгы җитәкчеләре җыелышына килгән икән. Кичен күчтәнәчләр күтәреп миңа кунакка килде. Дусларча озак сөйләшеп утырдык, гаилә хәлләрен, үткәннәрне искә алдык.

Сирәк кенә булса да Фарсель бәйрәмнәрдә котлап шалтыраткалады. Чын дусларча сөйләшүдән ары узмадык. Бер елны каты авырып Казан хастаханәсендә яттым. Фарсель минем янга ике-өч тапкыр килде. Фирая алдында намусыбыз чиста, йөзебез ак безнең. Фарсель Фирая белән яшәү дәверендә аңа хыянәт итмәде! Мин үзем Фираяны якыннан белмәдем, күргәнем дә булмады. Алар хәзер бергә инде, урыннары оҗмахта булсын!

Кавышу

2007 елда якын танышым, язучы Һәдия апа Хәбибуллинаның «Могҗиза тудыручылар» дигән китабы дөнья күрде. Фарсельгә шул китапны бирергә дип, Һәдия апа белән Казан дәүләт икътисад институтына кердек. Апрель ае, Фираяның үлгәненә бер ел үткән иде. Ул безне мәрхүм хатынының ел ашына чакырды. Без баш тарттык. Шулай да бик чакыргач, Һәдия апа белән Фарсельләргә бер бардык. Ишекне улы Айваз ачты. «Әти хәзер кайта, кибеткә генә китте, көтегез инде», – дип китмәвебезне үтенде. Чынлап та, Фарсель озак тормады, кайтып җитте. Матур итеп өстәл әзерләде, безне сыйлады. Китапларын, журналда чыккан язмаларын, фотоларын күрсәтте. Авыру улы белән яшәүче Фарсельне шул вакыт бик кызгандык. Саубуллашканда: «Иртәгә кайдан китәсең?» – дип сорады. «Автовокзалдан», – дидем. Ә миңа Казанның «Совет мәйданы»ннан китәргә туры килде. Ул, күчтәнәчләр алып, автовокзалга килгән. Түбән Камага китүче берничә автобусны озатып җибәргән. Кичен үпкәләп шалтыратты.

Менә шуннан телефон аша сөйләшүләр ешайды. Сөйләшкән саен Фарсель Казанга килергә, үзе белән яшәргә чакырды. Якыннарым белән киңәшкәннән соң, шактый озак уйлаганнан соң Түбән Каманы ташлап Казанга күчендем. Никах укытып яши башладык. Ул да, мин дә туганнарыбызга, дусларыбызга да белгертмичә бер ел яшәдек. Олыгайган көндә яңа тормыш башлау безгә ничектер оят кебек тоелды. Күп еллар язучы дусларына да белгертмәде.

Айваз белән уртак телне тиз таптык, гәрчә җиңел булды дип әйтә алмыйм. Кибеткә барсам, аңа дип махсус тәмле әйбер ала идем. Кунаклар килсә, өстәлдә нинди сый бар, иң беренче аның бүлмәсенә керттем. Ул үз бүлмәсендә ашады, күпме чакырсак та, аулакта ашарга яратты. Авыруы көчәйгәндә, чыгып китеп, югалып йөргән чаклары да булды. Андый вакытта төннәр буе Айвазны эзләдек. Күп тапкырлар Фарсель белән моргларга кадәр бардык. Әйе, авыр вакытлар күп булды. Ләкин аларны җиңеп, хәлләренә кереп ярдәм итә алганмын икән, үкенмим!

Казанда ундүрт ел Фарсель белән иңгә-иң куеп гомер кичердек. Мин аңа килгәч тә, өлкән яшьтә булуына да карамастан, өйдә диванда аунап кына ятмады, актив тормыш алып барды ул. Фарсель – үз тырышлыгы белән югары казанышларга ирешкән, тирән белемле, исеме данга күмелгән зур галим, күп дәрәҗәләр яулаган билгеле шәхес. Икътисад фәннәре докторы, профессор, академик, язучы, тәрҗемәче, танылган бакчачы һәм дәүләт тарафыннан би-

Могҗиза: мин килгәнче дә түгел, мин киткәч тә түгел, мин килгәч китте бит ул!



релгән дәрәҗәле исемнәр иясе дә: «Татарстанның атказанган фән эшлеклесе» һәм «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре». Аның бөтен гомере халыкка хезмәт итүгә корылган иде. Ир-ат буларак, алтын сыйфатлары бар иде аның: аракы белән мавыкмады, эчми-тартмый, исереп кайтып өйдә җәнҗал куптармый. Эштән кайтып хәл-әхвәл сорашып, ашап-эчкәч, кабат язу өстәле артына утырып, тизрәк фикерләрен кәгазь битенә төшерергә ашыкты.

Мин ул язганнарның барысын компьютерда җыйдым. Шулай ярдәмләшеп эшләдек. Үзе дә: «Венера, әле дә син бар янымда, рәхмәт сиңа, акыллым, мине аңлаганың өчен. Син илһам биреп торганда тыныч күңел белән эшкә китәм, фәнни хезмәтләремне дә дәвам итәм, иҗат итә алам», – дип, аркамнан сөя иде.

Хушлашу...

Инсульт булып, Фарсель Республика клиник хастаханәсендә 55 көн реанимациядә ятты. Җәйнең матур вакытында – 2021 елның 16 августында дөнья белән саубуллашты, 84 яшен тутырып бакыйлыкка күчте. Табиблар ничек кенә тырышсалар да, авыру үзенекен итте – алып калып булмады. Быел 1 июньдә аңа 85 яшь тулган булыр иде. Үзе исән булса, бу гомер бәйрәмен туганнары, дуслары, югары дәрәҗәләргә ирешкән курсташлары да (бер мәктәптә укыган сабакташы, якташы Минтимер Шәриповичны да күздә тотам) зурлап искә алырлар иде. Туксанга кадәр яшим әле дисә дә, насыйп булмады.

Аның янына реанимация бүлегенә көнаралаш барып йөрдем, ун гына минут дисәләр дә, әрсезләнеп өчәр сәгать утыра идем. 13 августта җомга көнне телефоныма язылган «Ясин» сүрәсен тыңлатып, башын тотып өч сәгать утырдым. Мыеклары үскән иде, тигезләп кистем, миннән күзен алмый карап ятты: «Үзең матур кисә идең, мин бик матур кисә алмадым», – дигәч, кулны кысты, аннары тәннәрен крем белән ышкып-массажлагач, битләреннән сөйдем. «Фарселькәем, китәм инде, дүшәмбе килермен, исән генә бул берүк», – дидем. Ул кат-кат кулымны кысты.

Дүшәмбе килдем. «Абыйның хәле авырайды, бераз керми торыгыз әле, апа», – диделәр. Ничек итсәм иттем, йөгереп кердем янына: «Хәлең авыраеп киттеме әллә, Фарсель?» – дип, битләрен, тәннәрен сыйпадым. «Китәсең түгелме соң, Фарсель, китмә, зинһар, китмә», – елый-елый, пышылдап догамны укыдым. Ишетә... Аңында... Соңгы сулышын алганда янында үзем булдым!.. Могҗиза: мин килгәнче дә түгел, мин киткәч тә түгел, мин килгәч китте бит ул! Дүшәмбе киләм дигәч, мине көткән бит, җанашым!.. Әйе, һәрвакыт сүзендә тора торган төгәл кеше иде шул ул.

Башларым әйләнеп, көч-хәл белән тотына-тотына, чыгып җиргә утырып, улы Айдарга шалтыраттым, бертуган сеңлесе һәм энесенә хәбәр иттем. Аннан, ярсып елый-елый, җан ачысы белән тешләремне кысып, бар көчемне җыеп Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдуллага шалтыраттым. «Көннәр эссе, озак тотып булмый, зинһар, озату чараларын үткәрергә булышыгыз, мөмкин булса, иртәгә Мәрҗани мәчетеннән озатсак иде», – дип үтендем. Сабыр гына тыңлады да: «Апа, тынычланыгыз, барысына да тырышырбыз», – диде. Яңадан шалтыраттым: «Фарсель гомере буе радио-телевидениедә эшләде, озатуда алар да булсалар иде». Аллаһның рәхмәте яусын Ркаил Зәйдуллага, озату чарасын җиренә җиткереп оештырды. Матур итеп Мәрҗани мәчетеннән озаттык. Язучылар, галимнәр, журналистлар, Фарсельнең хезмәттәшләре, дуслары, туганнар, күршеләр хушлашырга килгән иде.

Фарсельнең җәсәден 17 август көнне дүрт туганы, беренче хатыны Фирая, улы Айваз җирләнгән Биектау зиратына урнаштырдык. Бик тә авыр көн булды ул. Рухы янымда йөри кебек, күземнән чишмә булып яшь ага, күңел пәрдәсен моң-сагыш каплады. Ул хастаханәдә ятканда терелүен өмет итеп Аллаһыма ялвардым. Җылы кулларын тотып утырганда янында булганны тоя, күрә иде, сөйләшә генә алмады...

Тәкъдиргә каршы барып булмый шул... Аллаһның рәхмәтендә булсын Фарсель! Урыны оҗмахта, рухы шат, җаны җәннәттә булсын, тыныч йокласын кадерлебез!!!

Фарсельнең миңа язган шигыре:

Озатырга килми калма...

Вакыт дигән тар булса да дөньялыкта,
Соңгы юлга озатырга килми калма.
Килми калсаң, керермен дә төшләреңә,
Уянырсың мине уйлап иртә таңда.

Үлеләрдән шикләнәм дип, берүк яме,
Соңгы юлга озатырга килми калма.
Рухым минем исәннәргә зыян салмас,
Тик тереләр куркыныч ул, шуны аңла.

Таш атканга, дөньялыкта
аш аттым мин.
Үч тотмадым беркемгә дә, шуны аңла.
Юк-бар нәрсә саклап күңелеңдә миңа,
Соңгы юлга озатырга килми калма.
Йөзләремә бер моңаеп карыйм дисәң,

Соңгы юлга озатырга килми калма.
Барыбыз да кунак кына бу дөньяда,
Чират җитсә, күңелеңә авыр алма,
Ә шулай да озатырга килми калма...

Килдем... Килми каламмы соң инде, җанашым?!

ӘНИЛЕ РӘХӘТ ИЛДӘ

Мин үземне 3 яшьлек чагымнан беләм. Өстемдә әнкәй тегеп кидерткән ал күлмәк. Түр башындагы сәкедә яран гөлләре уртасында утырам. Сәкегә әнкәй үз куллары белән суккан буй-буй сызыклы палас җәелгән.

Әнкәй – шигъри күңелле, фантазиягә бай кеше. Ул матурлыкны күрә дә, күрсәтә дә белгән. Сабый чагымда мин гел аңа ияреп йөри идем. Икебез генә яшәгәнлектән, өйдә миңа күз-колак булырдай башка кеше юк. Мине – бердәнбер баласын шулай күз карасыдай саклап йөрткән ул.

Әнкәй мине үзе белән болынга алып барырга ярата иде. Болынга килгән саен төрле-төрле чәчәкләр белән таныштыра. Аларның нинди дәвага яраклы булуын әйтә. Болын шау чәчәктә. Араларыннан иң яраткааным – акчәчәк (ромашка). Әнкәйнеке – кыңгырау чәчәк. Алар чәчәк атканда болын шәмәхә-зәңгәр рәшә белән өртелә.

Әнкәй болындагы сыңар чәчәкне дә өзми, миңа да өзәргә рөхсәт итми. Шуңа күрә бер тапкыр да чәчәкләрдән такыя үреп кигәнем булмады минем. Әле дә чәчәкләргә читтән генә сокланып карыйм.

Без бара торган болын чәчәкле генә түгел, җиләкле дә иде. Мин җиләкне дөрес итеп җыярга әнкәйдән өйрәндем. Җиләклекне аркылыга-буйга йөреп таптамаска, җиләкнең иң эресен генә өзеп йөрмәскә тиешлегемне беренче баруда ук аңладым. Уйдык-уйдык бер урыннан гына җыеп та савытны бик тиз тутырып була икән. Бары тик җиләкнең һәр тармагын берәмләп карап кына җыярга кирәк. Без җир җиләге өлгергән вакытта күңел булганчы ашап кала идек. Киптереп тә куйдык. Җиләк кайнатмасы әзерләгәнебезне хәтерләмим.

Әнкәй моңлы итеп җырлый иде. Нәселебездә аның кебек җырлаучы башка беркем дә булмады. Күңелләрне айкап ала торган моң бар иде тавышында. «Су буйлап» җырын җырламыйча калган көне булмагандыр.

...Идел бит ул, тирән бит ул,
Тирән бит ул, киң бит ул.
Караңгы төн, болытлы көн –
Без аерылган көн бит ул.

Хәзер уйлап утырам: әлеге җырны әтием белән аерылышу сагышыннан җырлагандыр инде ул...

Мин кечкенәдән үк һәр эшгамәлемдә әнкәйгә охшарга тырыша идем. Ул җырлагач, үземне дә җырларга тиешле дип санадым. Шуңа күрә мәктәптә һәм авыл сәхнәсендә «Үз илемдә», «Ак пароход»ларны җырлап йөрдем. Ләкин кая инде ул миңа әнкәй кебек җырлаулар!



Аның аерым бер калын дәфтәре бар иде. Ул анда үзе иҗат иткән әйберләрне теркәп барган. Бәетләр, мөнәҗәтләр, шигырьләр... Үзе чыгарган мөнәҗәтләрнең барысын да моңлы гына бер көйгә салып җырлый иде әнкәй. Көннәрдән бер көнне, аңардан күрмәкче, мин дә шигырь язып карарга булдым. Ләкин нәрсә турында язарга? Өстәлдәге әдәбият дәреслегенә күзем төште. Бер битен ачтым. Карыйм – «Комсомолец Рәхи бәете». Шуннан карап язарга керештем. Беренче ике юлын шул бәеттән күчереп алам да, калган ике юлны, рифмалаштырып, үзем уйлап чыгарам. Эшемне тәмамлау белән, бәхет кошы тоткандай, әнкәй янына йөгердем. Мин язганны укый башлауга ук, көлемсерәп, туктап калды. Аннары, иңнәремнән кочып: «Күрше кызы Галия белән бергәләп язган кебек килеп чыккан инде бу...» – диде. Һәр әсәрнең авторы булуын, кеше язганны үзгәртергә ярамаганын шул көнне аңладым.

...Әнкәй кыска гомерле булды. Бакыйлыкка күчкәндә нибары кырык бер яшь иде аңа. 12 яшемдә әнисез калгач, бик күп еллардан соң мин болай дип язачакмын:

Вакытсыз киттең, балачак,
Ашыктың соң, әйт, нигә?
Үсеп тә җитмәгән идем,
Үлем тиде әнигә...
Балачагым, гамьсез чагым,
Нигә синә тартылам?
Әле дә ияреп йөрим күк
Әниемнең артыннан.
Кайтыр юл табып булмасмы?
Бик тә кайтасым килә.
Нәрсә биреп кайтып була
Әниле рәхәт илгә?

Әнкәй китте... Ләкин ул мине һәрьяклап мөстәкыйль тормышка әзерләргә өлгерде, киләчәк иҗатымда юл күрсәтүчем булды.

Рухия АХУНҖАНОВА



– Уң кулымның учында утлы шар тотып торам дип күз алдына китерегез. Бу сезнең энергиягез... Инде уч табаныннан ул шарны әкрен генә тәгәрәтә башлагыз. Башта беләзеккә кадәр, аннан терсәккә, иңбашына... Шулай «тәгәрәтеп» киләсең дә, аны тәнеңә, гәүдәңә «кертәсең». Аның эчтә ничек хәрәкәтләнгәнен һәр миллиметрына кадәр сизеп торасың... Бөтен күзәнәкләрең белән! Бераздан ул утлы шарны «тәгәрәтеп» сул кулыңның учына чыгарасың һәм кабат тәнеңә кертәсең. Гәүдәң буйлап аска, аякларга, аяк табаннарына кадәр дә төшерә аласың. Дулкынсыман хәрәкәтләр шулай туа... Бу юлларны укыганда сезнең дә эчтә җылы бер дулкын уянып, бөтен тәнегез буйлап әкрен генә таралдымы? Куллар үзеннән-үзе күтәрелде, учлар ачылдымы? Уч төбендәге күзгә күренмәгән теге кайнар шарны хәрәкәткә китерү өчен сыгыласы-бөгеләсе килә башладымы? Көзге каршына басып, уйлар артыннан ияргән ул хәрәкәтләрне кабатлый да башлагансыз икән, димәк, сез инде джаззо (jazzo) биисез! «Биим? Сез нәрсә турында сөйлисез?! Бөтенләй бии белмим ләбаса мин!» – дияргә генә ашыкмагыз. Хәзер барысын да аңлатам: сезнең инде чынлап та биегәнегезне дә, джаззоның нәрсә икәнен дә. Дөресрәге, аны сезгә әңгәмәдәшем Лилия ханым ГАЛЕЕВА аңлатыр.



ЙӨРӘК ТИБЕШЕ КӨЕНӘ БИЮ

Гөлнур САФИУЛЛИНА

Лилия ханым – Чаллыда туып-үскән. Россия халыкара туризм академиясенең Чаллы филиалын тәмамлаган. Әмма аңа үз һөнәре буенча эшләргә туры килмәгән. Тормышында мавыгулар байтак булган. Һәр мавыгуын һөнәр дәрәҗәсенә җиткерерлек сәләт бар Лилиядә. Берара ул чынлап торып флористика белән шөгыльләнгән: кәләшләр өчен чәчәк бәйләмнәре әзерләгән. 2000 нче еллар башы була бу: шәһәрдә әле адым саен чәчәк кибетләре ачылмаган. Аны эзләп, халык каланың икенче ягыннан ук килгән... Ә аннан, чәчәк-үләннәрне киптереп, бизәнү әйберләре ясауга күчкән. Бирелеп эшләгән! Үзенең кул һәм күңел җылысы кушылган ул колак алкаларын, йөзек һәм муенсаларны дус-танышларында әле дә очрата. Яратып кияләр!

«Күңелемдә туган теләкләр мине гел алга алып бара. Шулай яшәү кызыграк!» – ди ул. Инде менә тормышына бию килеп кергән. Джаззо!

– Бик авыр чагым иде. Әтине югалткан вакыт... Күңел әрни дә әрни... Соңгы ярты елда без аның белән бик якынайган идек. Авырый башлагач, әтине хастаханәләргә йөртергә, күбрәк янында булырга туры килде. Гел сөйләштек тә сөйләштек... Үзенең балачагы, үсмер еллары, яшьлеге турында сөйләде. Моңарчы мин аның хакында ишетмәгән, белмәгәннәрне. Инде бу югалту ачысын ничек тә кичерергә кирәк иде... Мине ул чакта джаззо коткарды. Интернет киңлекләрендә очраклы гына килеп чыккан идем мин аңа...

Лилия үзе әйткәндәй, тормышта бернәрсә дә очраклы гына түгел шул.

Интернетта Мимода Джаззо дигән кешегә тап була һәм аның куйган видеоларын карый башлый. Берсен, икенчесен... Видеодагы биюләр моңарчы күргән биюләрнең берсенә дә охшамаган. Бераз сәеррәк тә булып тоела, әмма... ошый! Өйдә үзе генә калган чагы була Лилиянең: музыка кабыза да видеодагыча бии башлый... «Ул минутларда үземнең эчке халәтемне биедем, һәм миңа күпкә җиңелрәк булып китте», – дип искә төшерә.

Нинди бию соң бу, дип, интернеттан шушы хактагы язмаларны эзли башлый. Ә язмаларның һәркайсы видеолар белән аралашкан: карый һәм караган саен бу биюгә гашыйк була бара!

Биюдә джаззо дигән әлеге юнәлешне Мимода Джаззо үзе уйлап чыгарган икән. Бу аның тәхәллүсе – псевдонимы, ә чын исеме – Джекоб Михельсон. Аңа хәзер 65 яшь, СССРда туган, Грузиядә, Латвиядә, Израильдә яшәгән, хәзер Лос-Анджелеста тора. Ул – режиссер, хореограф, дизайнер. Гомер буе балет белән шөгыльләнгән. «Ә джаззоны уйлап тапканнан соң миңа инде башкаларның кирәге калмады», – ди ул. Джаззо – джаз сүзенә бик охшаган, әйеме. Алар арасында, чынлап та, уртаклык бар икән. Джаз – музыканың, ә джаззо биюнең барлык юнәлешләрен үзендә туплаган. «Джаззо – техникасыз бию», – ди автор үзе.

– Джаззо – бии белүчеләр өчен түгел, ә биергә яратучылар өчен, – дип сөйли Лилия. – «Биергә өйрәнергә дә кирәкми, сез инде болай да бии беләсез!» – дип кабатларга ярата Мимода Джаззо. Биергә теләүчеләр, биергә яратучылар миллионнар бит алар! Безнең өчен шундый табигый күренеш бу. Чынлыкта, ана карынында ятканда ук бии башлыйбыз. Аннан соң да биибез әле. Балаларга игътибар итсәгез, аларның аяклары бит гел биергә тыпырдап тора. Үсә төшкәч кенә әллә никадәр стереотиплар, комплекслар уратып ала да, биюдән туктыйбыз. Ә джаззо безне кабат селкетеп, уятып җибәрә. Скрипкачы скрипка кылларына кагылып, аннан гаҗәеп музыка тудырган кебек, джаззо да кешенең күңеленә кагыла, аның бөтен эчке кичерешләрен, эмоцияләрен, рухи халәтен дулкынсыман хәрәкәтләр аша тышка чыгара – кеше ачыла...

Техникасыз бию дисәк тә, джаззоның нигезендә әнә шул дулкынсыман хәрәкәтләр ята. Ул хәрәкәтләрне өйрәнгәч исә кеше инде үз биюен уйлап чыгара башлый.

Лилия джаззо белән шөгыльләнүнең өстенлекләрен саный. Бүгенге җәмгыятьтә сәламәт яшәү рәвеше алып бару өчен шактый зур матди чыгымнар сорала: спортзалга, фитнес-клубка йөрү өчен абонемент, махсус киемсалым сатып алырга кирәк. Ә монда... монда бер тиен акча чыгармыйсың! Урыныңнан торып, йокы күлмәген, пижаманы да салмыйча, музыканы гына кабызасың да, көзге каршына басасың һәм бии башлыйсың.

Джаззо белән шөгыльләнә башлыйм дип, моңарчы җайга салынган тормыш рәвешеңә үзгәрешләр кертмисең. Биергә телим дип, ниндидер түгәрәкләргә язылмыйсың, чөнки махсус күнегүләр, хәрәкәтләр өйрәнергә, кемдер артыннан кабатларга, аларны истә калдырырга кирәкми. Бу бию беркайчан ике тапкыр кабатлана алмый: син бары үзеңне, үзеңнең шушы минутлардагы эчке халәтеңне тыңлыйсың һәм үз йөрәгеңнең тибешен биисең. «Музыка юк икән, йөрәк тибешегез көенә биегез!» – Мимода Джаззоның укучыларына яратып кабатлый торган сүзләренең тагын берсе бу.

Янә бер өстенлеге: син джаззоны берүзең генә дә бии аласың – партнерың булу мәҗбүри түгел. Әмма бергә барыбер күңеллерәк! Лилия кебек биюнең бу юнәлеше белән мавыккан хатын-кызлар иртәләрен онлайн рәвештә «очрашып», атнага өч тапкыр берәр сәгать бергә биюне гадәт иткәннәр. Төрлесенең дөньяның төрле почмагында яшәве дә комачауламый: берсе Норвегиядән кушыла, икенчесе – Германиядән, өченчесе – Чехиядән...

– Арада кем генә юк: эшмәкәр ханымнар, директорлар, хуҗабикәләр, пенсионерлар... Яшьләребез дә төрле. Бала көтүче яшь кенә бер ханым бар, мәсәлән. Римнан ул. Соңгы айлары, әмма барыбер бии! 70 яшьлек бер ханым онкология кичергәннән соң безгә килеп кушылды. Шундый канәгать! «Үземне бөтенләй башкача хис итәм, дөнья яңа яклары белән ачылды», – ди. Шикәр чире белән авыручы бер ханым бар. Бер ел эчендә шактыйга ябыкты, башка кешегә әйләнде ул хәзер. Ниндидер чирдән соң реабилитация узу өчен чыннан да файдасы бар джаззоның. Аны биючеләр дөньяда бик күп хәзер! Сүз уңаеннан, Мимода үзе биибез дип түгел, «джаззо белән шөгыльләнәбез» дип әйтергә ярата. Джаззо белән шөгыльләнү кешенең физик сәламәтлегендә генә түгел, эмоциональ халәтендә дә чагыла. Күз алдына гына китерегез: тәндә дулкын «кузгала» һәм ул үз юлында очраган барлык «блок»ларны – төрле стресслар тудырган «таш»ларны юып алып китә. Дулкынсыман хәрәкәтләр ясаганда моңа һәрвакыт безнең муеныбыз да катнаша: шуңа күрә анда бернинди

Фото: Анна Арахамия

«кысылулар» калмый – кан әйләнеше яхшыра. Нәтиҗәдә, баш авыртулардан, мигреньнән котылабыз. Хатын-кызның иң беренче муен өлеше картая, ә джаззо белән шөгыльләнү шушы процессны тоткарлый – битебез, муеныбыз озаграк вакыт матур булып кала. Воронежда яшәүче Татьяна Анпилова оештырган иртәнге проектта шөгыльләнүче хатын-кызларны күзәтүдән чыгып та әйтәм моны. Безгә кушылганда күбесенең карашы сүнгән, алар арыган, йончыган була, тоташ комплекслардан гына торалар. Бер айдан соң ук үзгәрәләр: ачылалар, күзләре очкынланып яна, дәрт уяна...

Алар инде урамда биюдән дә тартынмыйлар икән. Каядыр паркта яки кеше күп булган башка җирдә дулкынсыман хәрәкәтләр ясаучыларны күрәсез икән, шаккатмагыз – алар джаззо бии. Читтән караганда, бәлки, сәеррәк күренәдер, әмма моның ни икәнен белмәүчеләр өчен генә шулай тоела бу. Әйе, бу бию күбрәк хатын-кызларга туры килә.

Ә Лилиянең үзенең кайларда биегәне бар?

– Бик күп урыннарда! Үзеңдә дулкынсыман бу хәрәкәтләрне бер кузгатасың икән, аны инде туктата алмыйсың. Музыканы бөтенләй башкача ишетә башлыйсың – ул яңгырауга синең тәнеңдә дулкын булып хәрәкәтләр кузгала.

Узган ел Дагстанда ял иттек. Андагы таулардагы матурлык! Булган кеше белә инде... Ә джаззо белән шөгыльләнә башлагач, бер генә матур җирдән дә болай гына уза алмыйсың – шунда ук туктап биисе килә. Диңгез ярында да, таулар итәгендә дә... Биеклектән шулкадәр курыксам да, хәтта упкын читендә дә биедем! Бер атна экскурсияләрдә йөргәннән соң санаторийда яшәдек. Соңгы көнне саубуллашу кичәсендә, тәвәккәлләп, халык алдында джаззо биергә чыктым. Үзем теләп! Берничә ел элек: «Шулкадәр халык алдында чыгыш ясаячаксың», – дисәләр, гомердә ышанмас идем...

Әниләрнең туган ягына – Сабага кайтканда кырда туктап, эскертләр янында биегәнем булды. Машиналар булмаган буш юлда... Музейда! Безнең кызлар да шулай бөтен җирдә бииләр, хәтта урамда кышкы киемнән бию җаен да табалар иде. Ә узган ел, август ахырында барыбыз бергә сөйләштек тә, бер көнне кояш баткан вакытта урамга чыгып биедек: һәркем үзенең илендә, шәһәрендә, төбәгендә. Шундый матур видеолар килеп чыкты: артта – шәфәкъ, кояшның соңгы нурлары, ә алда – без биибез...

Зур бер хыялы бар Лилиянең. Алар Чаллының ГЭС бистәсендә яшиләр, өйләреннән ерак түгел – парк. Нарат агачлары үскән бу паркта ял итеп йөрүчеләр һәрвакыт күп була. Карусель янындагы сәхнә исә гел буш тора диярлек – Лилиянең шунда менеп биисе килә. Янәшәдән ашыкмыйча гына узып баручылар тукталып: «Бу нинди бию?» – дип сорарлар, ул аңлатыр... Быел җәй бу теләген, ниһаять, чынга ашырырга тиеш – сынган аягы гына төзәлеп бетсен дә... Джаззода тыпырдау юк: гәүдә авырлыгын бер аяктан икенчесенә күчереп, һәрвакыт бер аякта гына бииләр. Махсус костюмнар да кирәкми, киемгә төп таләп: ул иркен булырга, хәрәкәтләрне чикләмәскә тиеш. Биюче яланаяк булса әйбәтрәк – бу очракта аяк табанындагы бөтен нокталар хәрәкәткә килә.



« Лилиянең джаззо биегәнен видеодан карау өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.

Джаззо – танышу, яңа дуслар табу чарасы да. Бии башлаганнан бирле Лилиянең дә дуслары күпкә арткан. Туган көнендә, әнә, котлауларга, теләкләргә күмгәннәр үзен. Ул котлаулар бөтен дөньядан яуган! Иртәнге проектта катнашучылар өчен уртак чат булдырганнар: танышалар, аралашалар. Ялгызлыктан интегүчеләр хәзер байтак: пандемия чорында күпләр үз эченә бикләнде. Ә джаззо – кешене депрессиядән тартып чыгаручы бер инструмент та.

– Булдыра алмам дип борчылырга кирәкми. Килеп чыга, чыкмый дигән нәрсә юк джаззода. Безнең девиз – «Һәрвакыт килеп чыга!» Видеодан иң беренче биюләремне карыйм да, инде үземнең күпмегә остарганымны күрәм. Музыканы да хәзер яхшырак тоям. Хәрәкәтләрем дә башка...

Билгеле бер яшькә җиткәч, хатын-кыз «авырая». Тирә-юнендәгеләр моны сизмәсәләр дә, ул аны үзе эчтән тоя. 45–50 яшьләр арасында башлана ул. Мин инде өлкәнәям дип уйлыйсың. 20 яшемдәге җиңеллекне кайлардан алырга икән дисең... Аны кайдан алырга икәнен мин дә белми идем. Спорт белән әллә ни шөгыльләнергә яратмыйм. Ә джаззо миңа шул җиңеллекне бирде.

Утлы шар турында инде әйттем бит – файербол (fireball) техникасы дип атала ул. Техникасыз бию дисәк тә, джаззодагы бердәнбер техника дип шушыны атап була. Учыңдагы утлы ул шарны дулкынсыман хәрәкәтләр ясап тәнеңә кертәсең һәм күкрәк почмагында туктатасың. Шул ук дулкынсыман хәрәкәтләр ярдәмендә һәр әгъзаңа массаж ясый аласың: йөрәгеңә, ашказаныңа, бөерләргә, хатын-кыз органнарына... Әле бала тапмаган хатын-кызлар өчен бик файдалы ул. Менопауза яшенә җитүчеләргә дә бик кирәк. Организмда гормональ тайпылышлар, үзгәрешләр башлангач, күпме хатын-кыз аның белән ничек көрәшергә белми. Нишләргә белмәгәннән даруга тотына. Әгәр көн саен биисең икән, үзеңнең гормональ фоныңны бертигез халәттә тота аласың. Хатын-кыз сәламәтлеге өчен шундый зур табыш бу! Тагын бер нәрсә бар: джаззо белән шөгыльләнә башлагач, биюнең инде теләсә кайсы юнәлешен өйрәнә аласың – гәүдә сыгылмалыга әйләнә, җиңеләя, хәрәкәтләр нәфисләнә... Хатын-кызның гәүдә торышына кадәр үзгәрә: ул турырак басып йөри, матурлана, зифа-сылуга әйләнә. Аңа сексуальлек өстәлә. Моны тирә-юньдәгеләр дә күрми, сизми калмый...

Джаззо белән шөгыльләнә башлагач, теләсә кайсы бию мәйданчыгына аяк басуга ук йолдызга әйләнәчәксез – бертөрле генә биегән, дөресрәге селкенгән халык арасында аерылып торачаксыз. Башкаларныкына охшамаган хәрәкәтләрегезгә игътибар итмәү мөмкин түгел! Лилия бу сокланулы карашларны инде бер генә сизмәгән. Әмма иң мөһиме – ире дә, кызы да аның бу шөгылен хөрмәт итә. Кирәк чакта булышалар да: әниләре биегәнне видеога алар төшерми кем төшерсен?!

Инде меңләгән хатын-кызны (аларны гына да түгел!) рухландырган Мимода Джаззо: «Биегән кеше, корал тотып, үзенең күршесенә керми – бөтен дөнья биегәнен күрергә хыялланам», – ди. Чынга ашмаслык хыял түгел бит?! Сүз уңаеннан, шәкертләре җибәргән видеоларны бик сирәк куя ул. Әмма алар арасында Лилиянеке бар! Һәр мавыгуын һөнәр дәрәҗәсенә күтәрә белә дип, юкка гына әйтмәдем.

«ФИНАНС ӨЕ»НЕҢ НИГЕЗЕ



Ләйсән ХАЛИКОВА,
финанс белгече

Белгеч фикере

Чит илләр белән чагыштырганда, Россиядә иминиятләштерүгә мөнәсәбәт начаррак, ышаныч юк. Ә бит иминиятләштерү «финанс өе»нең нигезендә үк ята.

Бай кешеләр күптәннән «финанс өе»н төзеп, шунда «яшәсәләр», урта хәллеләр аны гомер буе төзи, ә кемдер әле нигезен генә салып маташа. «Финанс өе»нең нигезе әҗәтләрдән арыну һәм керем-чыгымнарыбызны барлаудан төзелә. Бурычлар күп җыелган, керем-чыгымнарыбызны барларга иренәбез икән, «өй»нең фундаменты нык булмый. Нигезнең икенче каты – тормышны һәм сәламәтлекне иминиятләштерү. Шушыларны тәртип белән «өйгәннән» соң, «йортыбыз»ның өске өлешенә күчә алабыз: «финанс мендәрен» булдыру, хыялларны һәм максатларны тормышка ашыру, пассив керем. Шушыларның бөтенесен булдыргач, түбә өлешенә – инвестициягә керешергә мөмкин. Финанс грамоталылыгы җитеп бетмәү сәбәпле, күп кешеләр, әҗәтләре була торып, «финанс мендәре»н дә булдырмыйча, шундук инвестицияләргә кереп китәләр. Нигездән түгел, түбәдән төзелә башлаган «өй», әлбәттә, озакка чыдамый.

Ни өчен иминиятләштерү «финанс өе»нең нигезенә үк салына соң? Хәвеф-хәтәр тулы дөньяда яшибез. Чирләр, бәла-казалар, куркыныч хәлләр уратып алды. Безгә шушы шартларда яшәргә, хәвеф-хәтәр белән идарә итәргә өйрәнергә кирәк. Уйлап карасаң, һәрберебезнең көндәлек тормышында страховка бар. Мәсәлән, запас тәгәрмәчләр, аптечка йөртәбез. Йортыбызга тимер ишекләр, катлаулы йозаклар куйдырабыз, монысына берәү дә мәҗбүр итми бит. Иминлек ягын уйлап шулай эшлибез.

Күз алдыгызга китерегез: кеше яши, гаилә кора, балалар үстерә, эшли. Күпмедер вакыттан ул балаларны укытырга, кеше итәргә кирәк. Ләкин уйламаганда-көтмәгәндә гаилә башлыгы – төп туендыручы казага юлыга яисә үлеп китә. Бу очракта гаиләсе финанс ягыннан бик кыен хәлдә кала. «Финанс мендәре» коткара, дип әйтергә мөмкин, ләкин ул булса да өч, күп дигәндә алты айга гына каралган була бит, аннан соң нишләргә? Ана кеше эшкә чыга алмый ди. Әҗәткә алып торып булыр иде, аны да кайтарырга кирәк. Машина яки фатирны сатар идең, кыска вакыт эчендә син теләгән суммага алучы табыламы, юкмы әле... Менә бу очракта иминиятләштерү – миңа берәр нәрсә була калса, гаиләм ач утырмаячак, дип, якыннарыңны кайгыртып кую ул.



Иминиятләштерүнең төрләрен аерырга кирәк:

- тормышны хәвеф-хәтәрдән иминиятләштерү – гаилә башлыгы үлеп китә калса, аның гаиләсенә килешүдә күрсәтелгән сумма түләнә;
- гадәттән тыш хәлләрдән иминиятләштерү – вакытлыча яисә өлешчә хезмәткә яраклылыкны югалтканда ярдәмгә килә;
- күчемсез милекне иминиятләштерү;
- гражданлык җаваплылыгы иминиятләштерүе, ягъни ОСАГО;
- туплам иминиятләштерү – монысы тормышны һәм сәламәтлекне иминиятләштерү, шул ук вакытта акча да җыю. Ул банк кертеменә охшаган. Билгеле бер вакытка, әйтик, ун елга килешү төзелә. Тормышыңны бер миллион сумга иминиятләштерәсең, ди. Даими рәвештә килешүдә күрсәтелгән күпмедер сумманы түләп барасың, ул акчалар хисабында саклана. Әгәр иминият очрагы булса, тиешле акчаны гаиләңә түлиләр. Ун ел эчендә иминият очрагы булмаса да, җыелган сумманы процентлары белән кире кайтарып аласың. Хәтта кеше беренче елны килешү буенча түләп, икенче ел башланганда дөньядан китсә дә, аның гаиләсе барыбер бер миллионны ала, чөнки шул суммага иминиятләштерелгән.

«Минем тормышым иминиятләштерелгән, ипотекам бар, банк страховка бирде», – дип әйтүчеләр очрый. Ялгышмаска кирәк: кредит яки ипотека алганда синең исемгә рәсмиләштерелгән иминият полисы сине түгел, банкны саклый. Сиңа нәрсә дә була калса, синең урыңга ипотекаңны түләп бетерәләр дигәнне аңлата ул. Әмма гаиләңне кем ашатачак соң? Банкны монысы кызыксындырмый.

Туендыручының тормышын гаиләнең биш еллык чыгымнары күләмендә иминиятләштерергә тәкъдим ителә. Статистика күрсәткәнчә, гаилә башлыгы үлеп китсә, аның хатынына һәм балаларына аякка басарга дүрт-биш ел кирәк була.

Фәнзилә МОСТАФИНА әзерләде.



ГҮЗӘЛЕМ ИЗМИР



Фәнзилә МОСТАФИНА

Борынгы Греция заманында ук төзелгән Смирнага – бүген Төркиянең өченче зур шәһәре саналган Измирга – барганчы ук гашыйк булган идем инде.
Госманлы империясенең соңгы көннәре һәм төрекләрнең бәйсезлек өчен сугыш алып барган еллары тасвирланган «Ватаным – син» төрек сериалында төп вакыйгалар нәкъ менә Смирна-Измир шәһәрендә бара. Дөрес, сериал бүгенге Истанбулда төшерелгән, ләкин фильмны караганда анысы онытыла – үзеңне шул заманнар Измирында йөргәндәй хис итәсең. Анда шундый кадр бар: бер тапкыр да диңгез күрмәгән яшь солдат фронтта командирыннан сорый: «Измир гүзәл шәһәрме?» «Гүзәл, – дип җавап бирә командиры. – Күп аңлатып тормыйм, барып җиткәч үзең дә күрерсең!» Бу сүзләрне үземә атап әйтелгәндәй кабул иттем. Һәм күңелемнең бер почмагына язып куйдым: Измирны барып күрәсем килә! Быел февральдә хыялым тормышка ашты: дустым Миләүшә белән аркага аса торган сумкаларыбызга Казан күчтәнәчләре салдык та, Төркиянең үзебез өчен яңа өлешен – Эгей диңгезе төбәкләрен ачарга, Измирның һавасын сулап, күңелгә сеңдереп кайтырга чыгып киттек.

Картаның кирәге дә калмады – дулкын тавышы эзләгән җиребезгә китереп җиткерде.

Төрекләрдә cemre düşmesi [джәмрә дүшмәси] дигән төшенчә бар. Көннәрнең җылынып, язга авышуын билгели торган күрсәткеч ул. Cemre сүзенең тамырлары гарәп теленнән килә, безнеңчәгә «ут, янып торучы яки пыскып ятучы күмер» дип тәрҗемә ителә. Февральнең егермеләрендә cemre һавага төшә, ягъни һавалар җылына башлый. Берәр атнадан – суга, ә тагын бер атнадан (якынча 5-6 мартларда) туфракка төшә, менә шуннан соң яз килде дип әйтергә дә ярый. Без ике куянның койрыгын берьюлы тотарга булдык. Җылының һавага төшкәнен көттек тә Измирга юл тоттык. Кары булмаса да, термометр 10–15 градус җылылык күрсәтсә дә, агачлар чәчәк атып утырса да төрекләр өчен әле кыш санала – һава да, диңгезнең сулышы да салкынча. Әмма без үзебездәге карлы (быел бигрәк тә күп яуды бит!) кыштан, минуслы температурадан, калын киемнәрдән шулхәтле арыганбыз, Измирның cemre төшкән һавасы май кебек тоелды. Берничә сәгать эчендә кыштан язга килеп эләккәндәй булдык. Шул ук вакытта төрек кышын да күрдек санала.
Сүз уңаеннан, без килеп берничә көн үткәч, cemre ташка төште, диделәр. Анысын суытып җибәргәч әйтәләр икән. Чынлап та, бер-ике көн таулардан суык җил исте, төрекләр анысына да матур исем тапканнар – «пойраз». Аны ир балаларга исем итеп тә кушалар.

Кар дигәннән, быел Төркиянең җылы төбәкләрендә дә кар явып шаккаттырды. Ә менә Измир шәһәрендә бер дә яумаган. Кызык иткәннәр: таулырак җирдә урнашкан икенче шәһәрдән бер машина арбасы кар төяп алып килеп, Измирның уртасына – Кунак мәйданына бушатканнар. Бала-чага шул кар белән уйнап рәхәтләнгән, олылар да могҗиза күргәндәй тотып-тотып караган. Моны безгә баргач сөйләделәр. Шулай сөенәселәрен белгән булсак, аркага аса торган сумкабызга үзебездәге ап-ак карны тутырып алып килгән булыр идек, билләһи!

Измирга кояш баегач барып җиттек. Арып-талып юлдан килгән кешеләр кунакханәгә урнашуга нәрсә эшлиләр? Кешеләрне белмибез, ләкин без тизрәк диңгез белән исәнләшергә ашыктык. Телефонда картаны ачып, «яр буе» дип җыйдык та уклар күрсәткән якка киттек.

Мәрхәбә, Измир! Хуш килдек, диңгез!.. Ә менә хәзер тыныч күңел белән тамакны туйдырсаң, ял итсәң дә була.

Икенче көнне иртән дә беренче эш итеп диңгезгә юл тотабыз, әлбәттә. Юл тотабыз дип... әнә ул – кул сузымында гына. Безне күптән көткәндәй бөтен зәңгәрлеге белән җәйрәп ята, офыкларга хәтле барып җитә дә ак болытлар белән тоташа. Капкалар өчен җирле ризыклар – Измир бомбасы (эченә мулдан эретелгән куе шоколад салынган кечерәк кабартма), геврек (Төркиянең башка җирендә симит буларак билгеле камыр ризыгын монда шулай атыйлар, ул кетердәбрәк тора) һәм каһвә алабыз да, кордон буена (монда яр буен шулай диләр) төшеп, ярның буеннан-буена сузылган эскәмияләргә аякны салындырып утырып, шәһәрнең уянуын күзәтә башлыйбыз. Заказ биреп куйган кебек: һава аяз, җылы – кыш димәссең дә! Диңгез белән күк йөзен бер итеп акчарлаклар биеп йөри, яр буеннан берән-сәрән спорт белән шөгыльләнүчеләр йөгереп үтә, диңгездән «мәлтәм» – безнеңчә әйткәндә бриз исә, кешеләр пароходта шәһәрнең каршы ягына эшкә бара. Рәхәт! «Менә, ичмасам, бәхетле кешеләр: көн саен диңгез буйлап эшкә йөриләр. Ә шул пароходта эшләүчеләр ничек бәхетледер!
Көн саен диңгезне, акчарлакларны күрәләр, дулкыннарга карап бөтен борчулары эреп тараладыр», – дип куя дустым Миләүшә. Тели белсәң – теләк, тели белмәсәң, нәрсә диләр әле? Эшләп карадык без ул пароходта. Икенче як ярга чыкканда манзарага хозурланып барып, идәнгә әйрән түккәч, швабра сорап торырга туры килде. Яр буенда аякларны салындырып утыру күңеллерәк икән, дидек.

Кайчандыр бик борынгы заманнарда – әле шәһәр Смирна исемен йөрткәндә, грек шагыйре Гомер да шушы җирләрдә йөргән (аның туган җире төгәл билгеле түгел, Смирна булуы ихтимал, дип яза тарихчылар), бәлки, үзенең данлыклы «Илиада» һәм «Одиссея» әсәрләрен безнең кебек диңгезгә карап утырып иҗат иткәндер. Соңрак греклар урынына борынгы римлылар килгән, аннары – Византия, аннары – Госманлы империясе чоры. 1919 елда шәһәр кабат греклар юрисдикциясенә күчкән, ә 1922 елда Ататөрек гаскәре тарафыннан алынган. Смирна-Измир җирендә бихисап канлы бәрелешләр, янгыннар, җир тетрәүләр булган. Шәһәрнең исеме, хуҗалары, йөзе алышынган. Эгей диңгезе генә шул килеш калган. Дөрес, шушы вакыт эчендә аның суы шактый чигенгән, ләкин бөтен бу чорларның, вакыйгаларның шаһиты булган диңгез бүген дә җәйрәп ята. Аңа карап



■ Кунак мәйданы.

«Монда кайда казысаң да – тарих», – ди Измир халкы.



Пагос тавы башыннан күренеш.



Чишмә шәһәрчегенең яр буендагы рестораннарның берсе.

утырганда үзең дә шушы чорлар аша узгандай буласың.

Гел янәшә булган, көн дә күреп торган нәрсәнең кадере кими. Измир халкы, әнә, арба белән китереп бушаткан карга да сөенгән. Ә без диңгез дип аһ итәбез.

– Сез үзегез ияләшкәнсездер инде, – дим такси йөртүчегә, төз пальмалар тезелеп утырган яр буеннан узып китеп, Кадифекале замогына менгәндә. – Көн саен диңгезне күрәсез, шуның яныннан үтеп эшкә йөрисез. Ә безнең өчен ул – тансык.

– Иялəшүен иялəшəсең. Лəкин каядыр сусыз җиргә китеп торсам, диңгезне сагына башлыйм. Бик яраткан дустыңны озак күрми торгач нәрсә хис итәсең, менә бу да шулай, – ди таксист.

Кадифекале борынгы Пагос тавы башында урнашкан. Легендалар буенча, Александр Македонский монда ауда йөргәндә арыгач, агач төбенә ятып черем итеп алырга уйлаган. Шунда төш күргән: алиһәләр Смирнаны яңа җиргә күчереп салырга кушкан. Төш юраучы да, имеш, җимерелеп беткән Смирнаны төньяккөнчыгыштан Пагос тавы итәгенә табарак күчерсәң, халкы бәхетлерәк булачак, дигән. Шулай итеп, яшь Македонский шәһәрне яңартырга тотынган. Заманында бик көчле ныгытма булган Кадифекале соңрак ташландык хәлдә калган. Әле 2007 елда гына торгыза башлаганнар аны. 2020 елда Кадифекале ЮНЕСКОның башлангыч исемлегенә кертелгән. Өстәмә финанслар бүленсә, Македонский чорындагы кебек үк булмаса да, элекке шанлы вакытларындагы ныгытма хәленә китерелер иде.

Дөрес булса, Ататөрек тә, шәһәрне алгач, иң күренеп тора торган җир дип, шушы тау башына төрек байрагы кадаткан, ди. Без менгәндә дә зур байрак җилфердәп утыра иде. Аның хәзерге көндә эленгәнен аңласак та, теге заманнардан ук калган дип уйлау, Македонский эзләреннән йөрибез дип күз алдына китерү кызыграк бит! Ә таудан бөтен шәһәр ачыла. Диңгез кочагында яткан һәм тауларның иңенә сыенган гүзәлем Измир.

Чынлап та, шәһәрдә ачык һава астында музейлар шактый. Сакланып калган диварның бер кисәгендә борынгы грекча нәрсәдер язылган булса, икенче бер ташта гарәп шрифты укыла. Картада билгеләп куйган тагын берничә ноктабыз бар әле безнең. Алары шулай ук Измир провинциясендә, ләкин башка шәһәрләр. Автобуска утырабыз да ике сәгать ераклыктагы Чишмә шәһәрчегенә юл тотабыз. Кайнап торган Измирдан соң кечерәк кенә авылга килеп эләккән кебек. Бу якта күбесенчә хәллерәк төрекләр ял итә. Әле сезон башланмаган, шуңа күрә шәһәр буш диярлек. Авантюристларча эш итәргә булабыз: кунакханәне алдан белешмибез, килеп җитеп, бераз кояш баешын карагач, диңгез яры буйлап кунар урын эзләп китәбез. Бәхетебезгә, яр буендагы иң соңгы кунакханәдә диңгезгә карап торган якта бүлмә табыла.

Кичке ашка балык алабыз – монысы бәхәссез. Төрек кухнясы ит ризыклары белән данлыклы булса да, Эгей төбәгендә төп ризык – диңгез



Ышануларга караганда, Мәрьям Ана да соңгы көннәрен Эфеста үткәргән, биредә аның йорты да бар. Рәт-рәт булып тезелеп киткән колонналар арасыннан тарих китапларында сурәтләнгән борынгы греклар йә римлылар килеп чыгар төсле.







нигъмәтләре. Балыкны кул сузымында гына булган диңгездә тоталар, шунда ук рестораннарга саталар, ә анда җаның теләгәнен пешереп бирәләр. Башта, әлбәттә инде, төрекләргә хас булганча тәмләп, һәрберсенең тарихын сөйлиләр.

Иртәгесен кабат юлга кузгалабыз. Бу юлы – Эфес шәһәрчегенә. Борынгы Грециядәге иң әһәмиятле шәһәрләрнең берсе булган ул. Бүген хәрабәләр арасында йөргәндә моны күз алдына китерү кыенрак, әлбәттә. Биредә порт булган, сәүдә гөрләп барган. Тора-бара диңгез саеккач һәм чигенгәч («Википедия» мәгълүматына караганда, бүген Эфес диңгездән 10 км ераклыкта), шәһәр ташландык хәлгә килгән, ә җир тетрәүләр аны туфрак астына күмгән. Археологлар XIX гасырның 60 нчы елларында гына казып чыгарганнар. Хәзер Эфес – ачык һавадагы музей-шәһәр. Дөньядагы җиде могҗизаның берсе булган Артемида алиһә храмын да, борынгы заманның иң зур ике китапханәсенең берсе саналган Цельс китапханәсен дә өлешчә торгызганнар (кыйммәтле табылдыклар Вена һәм Британия музейларында саклана).

Борынгы Рим чорында төзелгән амфитеатр яныннан үтәбез. Миләүшәнең җырлыйсы килә. Һәм без заманында антик пьесалар уйналган, сәяси һәм фәлсәфи дискуссияләр алып барылган 24 мең тамашачы сыйдырышлы амфитеатрда татарча «Туган як» җырын җырлыйбыз. Алкышлар тавышы. Җырны аңлар өчен тел белү кирәкми, дип уйлап та бетермибез, нәкъ безнеңчә «Афәрин!» дигән тавыш ишетелә. Тавышның иясе – урта яшьләрдәге ир-ат, «сәхнә» уртасына чыгып, үзе дә җыр сузып җибәрә, аңарга өч юлдашы да кушыла. Тукта, чуашча түгелме соң бу?! Күршеләр икән ләбаса! Җырның сүзләрен белмибез, ләкин биеп торырга булдырабыз. Берән-сәрән «тамашачылар» – төрек, инглиз, испан телләрендә сөйләшүче туристлар алкышлый. «Казанга сәлам!» – ди «сәхнәдәшләр» саубуллашканда. «Чабаксарга сәлам!» – дибез үз чиратыбызда. Күтәренке күңел белән кайтырга кузгалабыз. Башта – Измирга, ә аннан Казаныбыз көтә.



Фото: pexels.com



Сорауларга Республика балалар клиник хастаханәсе педиатры Ләйсән НОТФУЛЛИНА җавап бирә

? Яңа туган кызым белән төнлә бергә йоклыйбыз. Ул еш уяна, ә мин урынымнан тормыйча гына аны имезә алам. Ирем борчыла, баланы төнлә ялгыш томалавың бар, ди. Бәләкәй бала белән бергә йоклау зарарлымы?

Әгәр сезгә шулай уңайлырак булса, бала белән бергә йокларга мөмкин. Ләкин куркынычсызлык кагыйдәләрен сакларга кирәген онытмагыз. Беренчедән, баланың өстен үзегезнең юрган белән япмагыз, аны мендәргә салмагыз. Урын җирен бала борыны белән төртелерлек әйберләрдән арындырыгыз. Табигый тукымалардан тегелгән, бауларсыз йокы күлмәге киегез. Матрас каты һәм тигез булса яхшы. Карават кырыена баланы тәгәрәп төшүдән саклый торган бортик урнаштырыгыз. Спиртлы эчемлек, тәмәке кулланган очракта, йоклата торган дарулар эчкәндә бала белән йоклау тыела. Авырлыгыгыз артык булса, шулай ук бала белән йокламаска тырышыгыз. Иң кулай вариант – бала караватын үзегезнекенә кушып кую. Бер яктан – бала сезнең белән йоклый, ә икенче яктан – аңа бернинди куркыныч та янамый.

? Бала тудыру йортында балаларның күбесе сары төшүдән авырды. Безгә бу кагылмады, ләкин өйгә кайткач, баланың тән тиресенең төсе үзгәрде, кучкылланды. Физиологик сары төшү микән бу? Моны ничек билгеләргә?

Физиологик сары төшү яңа туган балаларда еш күзәтелә. Ул баланың беренче көннәрендә, күбесенчә дүртенче-бишенче тәүлектә барлыкка килә. Баланың тәне, лайлалы катламнары, күзнең агы сары төскә керә, канда үт пигменты күләме – билирубин күтәрелә. Физиологик сары төшү гадәттә ике-өч атнада уза һәм дәвалау таләп итми. Бала да үзен начар хис итми, бәвел, тәрәт төсе дә үзгәрми. Сары төшү икәнен аңлар өчен билирубинга анализ бирергә яисә тән аша билгеле торган билирубинометрия дип аталучы ысул кулланырга мөмкин.

? Манту сынавын (проба) ясар алдыннан кайбер әниләрнең балага супрастин биргәнен ишеткән бар. Шулай иткәндә нәтиҗәсе яхшырак була, прививка урыны кызармый, диләр. Супрастин нәтиҗәгә йогынты ясыймы?

Антигистамин препаратлар куллану Манту сынавының нәтиҗәсенә бернинди йогынты да ясамый. Ә менә балада туберкулинга аллергия булса, сынау ялган уңай нәтиҗә күрсәтмәсен өчен, антигистамин препаратлар куллану ярдәм итәчәк.

Нәниләргә күчтәнәч!
Телефон камерасын QR-кодка якынайтып, аудиоформатта язылган әкиятне балагызга тыңлатыгыз.



Кадерле әниләр!
«Яшь әни» рубрикасына сездән сораулар кабул итәбез.
Җавап бирүче белгечләр: педиатр, гинеколог, стоматолог, невролог, хирург-ортопед, кардиолог, иммунолог-аллерголог, гастроэнтеролог, эндокринолог, офтальмолог һәм башкалар.

Балаларга кагылышлы сорауларыгызны – 8 (843) 2-22-09-77 телефоны аша, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт адресы буенча яисә ssuum@yandex.ru электрон адресына «Сорау–җавап» дип язып җибәрә аласыз.



Сорауларга Республика балалар клиник хастаханәсе табиб-отоларингологы Ләйсән АЗИЗОВА җавап бирә

? Диңгез суы белән чайкап аденоидлардан котылып буламы?

Борын-йоткылык бизләре (аденоидлар) – бала организмын саклаучы тукымалар. Алар зурайса, ялкынсынса, шешсә, димәк, боларны барлыкка китерүче сәбәп бар. Борынны диңгез суы белән юдыру – профилактик чара ул. Аның ярдәмендә борындагы лайланы, инфекция тудыручы вирусларны, бактерияләрне һәм аллергеннарны юдырып төшерәләр. Сулыш юлларын лайладан арындыру аденоид тукымасының ялкынсынуын киметергә ярдәм итә.

? Балабыз еш кына томау төшеп азаплана. Ингалятор сатып алдык. Ләкин томаулы килеш ингаляция ясаудан файда бармы икән?

Томау төшкән вакытта ингалятор кулланылмый.

? Баланың колагына су керер дип, куркып кына юындырам. Бәбинең колагына су кергәнен ничек аңларга һәм аңа ничек ярдәм итәргә?

Баланың колагында ялкынсыну булмаса, анда су керү куркыныч түгел. Кергән очракта да су тышкы ишетү юлларыннан эчкә үтә алмый, колак пәрдәсе (перепонка) артына да үтми. Инде су кергән очракта да мамык таякчыклар кулланырга, колакка өрергә, фен белән киптерергә ярамый. Бары тик табибка мөрәҗәгать итәргә генә кирәк.

? Колактагы сагыз бөкеләр (серная пробка) баланың колагын тулысынча диярлек томалап тора. Алар ишетү сәләтенә йогынты ясыймы? Алардан ничек арынырга?

Колакны томалап торучы сагыз бөкеләр ишетү сәләтенә йогынты ясарга мөмкин. Кайвакыт бала бөтенләй ишетми башлый. Мәсәлән, су кереп, коры сагыз бөке бүрткән вакытта. Сагыз бөкеләрне өй шартларында чистартырга ярамый. Баланың ишетү юлларына һәм колак пәрдәсенә зыян салырга мөмкинсез. Моның өчен табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Республика балалар клиник хастаханәсенең матбугат хезмәте җитәкчесе Зөһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.

СОРАУ–ҖАВАП

ЧӘЧЛӘРНЕ КОЯШТАН САКЛЫЙБЫЗ

Җәйге кояш шәп, әлбәттә, әмма чәчкә зыянлы. Бу ел фасылында чәчләрне тагын да ныграк тәрбияләргә кирәк. Агрессив ультрашәмәхә нурлардан сакланыр өчен башыгызга киеп йөрүдән битәр, төрле битлекләр, махсус шампуньнар алыгыз. Кояштан саклаучы махсус спрейлар да кулланыгыз. Ул, чәчләрдә пленка булдырып, аларны тагын да ялтыратып җибәрер. Өй шартларында махсус битлекләр дә ясарга иренмәгез. Җәй көне чәч очлары яргаланучан була, чөнки эссе һавадан алар корый. Бу эстетик яктан да матур түгел. Шуңа чәч очларын кисүдән курыкмагыз.

Чәчләрне кояштан саклау өчен

Беренче ысул:

- 1 аш кашыгы жожоба мае;
- 1 аш кашыгы шалкан мае;
- 2-3 тамчы лаванда, лимон, пачули эфир мае.

Әлеге кушылманы баш тиресенә сөртегез дә целлофан пакет киеп, башыгызга сөлге урап, 20 минут тотыгыз. Соңыннан җылымса су белән юып төшерегез. Чәчләрегез бик коры булса, чиста чәч очларына жожоба мае тидерергә дә ярый.

Икенче ысул:

- 2 аш кашыгы вакланган диңгез тозы;
- берәр аш кашыгы миндаль, зәйтүн, бодай үсентесе мае.

Бар ингредиентларны болгатып, 7–10 минутка калдырыгыз. Чәчләрне юар алдыннан төнәтмәне баш тиресен массажлый-массажлый сөртегез. Чеметтереп алуны тойганчы ышкыгыз да, шампунь белән юып төшерегез.

Чәчләрне чайкар өчен төнәтмә

- 1 аш кашыгы кипкән ромашка;
- 1 аш кашыгы мелисса;
- 1 аш кашыгы меңьяфрак.

Үләннәргә 400 мл кайнап торган су агызыгыз һәм 30 минут төнәтегез. Төнәтмәне сөзеп, тагын 150 мл су өстәгез, аннары шампунь белән юылган чиста чәчләрне чайкагыз.

Шевю
ДОМ ПАРИКОВ

ӨЛЕШЧӘ ЯКИ
БӨТЕНЛӘЙ ЧӘЧСЕЗ
КАЛГАНДА ПРОБЛЕМАНЫ
НӘЗАКӘТЛЕ ХӘЛ ИТҮ

РӘСМИ БУЛМАГАН ШАРТЛАРДА

АЕРЫМ ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮ

Казан, Себер тракты, 13
(843) 203-48-00 domparikov.ru

Реклама



ТЕЛЕГЕЗ ДӨРЕС ЯТАМЫ?

Телнең авыз куышлыгындагы дөрес торышы йөз матурлыгына тәэсир иткәнен беләидегезме? Бу чынлап та шулай. Игътибар итегез әле: аскы казналыгыгыз ничек тора? Ул киеренке халәттә булмасын, аскы һәм өске тешләр бер-берсенә тимәсен. Ә телегез ничегрәк ята? Авыз куышлыгында үзенә урын таба алмыйча буталып йөриме? Тешләргә тиеп торамы? Йә аскы аңкауда ятамы? Болар дөрес халәт түгел. Тамырыннан очына кадәр тел аңкауга «ябышып» торырга тиеш. Тел асты мускуллары чәйнәү мускуллары белән бергә аскы казналыкны тотып тора һәм йөзгә бик нык тәэсир итә. Әгәр тел дөрес ятмый икән, казналык йә өскә, йә аска күчә, йөз аска таба тартыла, «яшьлек почмагы» юкка чыга, ияк сәлперәеп, «күркә муен» барлыкка килә. Бу шулай ук сын-кыяфәткә дә, баш мие эшчәнлегенә дә тәэсир итә, чөнки безнең организмда бар нәрсә бер-берсенә бәйләнгән, ди белгечләр. Авыз куышлыгында телне дөрес тотарга өйрәнегез (ул «Н» авазын әйткәндәге кебек ятсын). Тел асты мускулын киеренкелектән чыгару өчен махсус күнегүләр дә бар. «Аларны көнгә биш минут эшләсәгез дә телегез урынына кайтыр», – ди матурлык экспертыбыз Ләйсән САБИТОВА.










- Тел белән өске аңкауны этәбез.
- Тел өске аңкауда килеш тәкерек йотабыз. Бу вакытта бары тик бугаз гына селкенергә тиеш.
- Авызны ачабыз да телне турайтып чыгарабыз һәм кертәбез.
- Тел өске аңкауны баса, бу вакытта аскы казналыкны аска төшерәбез.
- Авыз ябык. Тел белән эчке яктан әле бер як бит алмасын, әле икенчесен этәбез.
- Авыз ябылган килеш телне теш казнасы буйлап әле бер, әле икенче якка әйләндерәбез.
- Бу күнегүне башны әле – сул, әле уң якка борып, өскә күтәреп һәм аска төшереп тә эшләгез.

Бу күнегүләрне эшләгәндә телегез арыр, мускулларыгыз киеренкелектән авыртыр. Курыкмагыз. Бу – нормаль хәл. Матур булыгыз!

















QR-код аша кереп, массажны видеодан да карап ясый аласыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.

Тирамису



Бөтен дөньяга билгеле әлеге итальян десертын күпләрегезнең авыз иткәне бардыр, бәлки. Итальян теленнән турыдан-туры тәрҗемә иткәндә, «мине өскә күтәр» дигәнне аңлата ул. «Кәефемне күтәр, дип әйтү дөресрәк булыр», – дип шаярта укучыларыбызга яхшы таныш аш-су остасы Венера АРСЛАНОВА. Ярты ел дәвамында әлеге рубрикабызның хуҗабикәсе булды ул, тәмледән-тәмле рецептлары белән бүлеште. «Һәркем әзерли алсын, кирәкле азык-төлекне еректан эзләрлек булмасын, тәме бөтен кешегә ошасын», – дип, үз тәҗрибәсендәге иң затлы ризыкларны пешерү серләрен ачты. Венера ханым тәкъдим иткән бу десерт белән аның осталык дәресләре циклын әлегә төгәллибез. Кунак табынына да иң ахырдан чәй белән баллы тәм-том чыгаралар бит. Итальяннар ризыгы дисәк тә, тирамису бик җиңел әзерләнә икән. Әйдәгез әле, бергәләп әзерлик!

Кирәк (печенье өчен) / 120 г он / 100 г шикәр оны (пудра) / 4 йомырка / 1 кап ванилин / 1 стакан куе итеп пешерелгән кара кофе.

Крем өчен 4 йомырка / 500 г маскарпоне (аны куе авыл каймагына алыштырырга була) / 150 г шикәр оны / 20 г желатин (ансыз да әзерли аласыз).
Бизәр өчен шоколад вагы яки какао порошогы.

Эш барышы

■ Йомыркаларның агын сарысыннан аерабыз. Агына бер генә чеметем тоз кушып, миксер белән күпертәбез. Тизрәк күперсен өчен, моның үзенә күрә кечкенә генә сере бар. Беренчедән, йомыркалар салкын булырга тиеш. Икенчедән, савыт коры булсын. Өченчесе – башта акрын тизлектә күпертә башлап, бераздан тизлеген арттырабыз. Дүртенчесе – шикәр онын аз-азлап кына куша барабыз. Күбек кирәкле куелыкта булсын өчен, кимендә 5 минут күпертергә кирәк. Әзерлеген белү өчен савытны әйләндереп карагыз, күбек савыттан кубарга тиеш түгел.

■ Икенче савыттагы йомырка сарысын да агарганчы һәм күләме икеләтә артканчы миксер белән күпертәбез. Аннары онның өчтән бер өлешен кушып, төерләре калмаслык итеп кашык белән туглыйбыз. Күпертелгән йомырка агының да өчтән берен салып, сак кына болгатабыз. Он белән күбекне шулай өлешләп сала-сала, барысын да кушып бетерәбез, ванилин өстибез.

■ Таба төбенә пергамент кәгазе җәеп, җиңелчә генә майлыйбыз. Әзер камырны кондитер капчыгына салып, табага бармак калынлыгыннан чак кына киңрәк һәм бармак озынлыгында итеп тезеп чыгабыз. Кондитер капчыгы булмаса, гадәти целлофан капның бер почмагын кыйгачлап кисеп, камырны шуның белән дә кысып чыгара аласыз. Күбекле камыр тиз шиңә, шунлыктан табаны алдан әзерләп куярга кирәк.

■ Печеньены 180 градуска кадәр кызган мичтә 15 минут чамасы пешерәбез. Өсте алланганны көтәргә кирәкми, шырпы батырып карагач, коры чыкса, димәк, әзер. Печенье пешкән вакытта мичне ачмый торырга кирәк. Пешеп чыккач, табада килеш кенә өстенә шикәр оны сибеп, берәр тәлинкәгә тезәбез. Әлегә суына торсын. Тирамису өчен кибеттә махсус печенье да сатыла. «Савоярди» дип атала ул. Вакытыгыз чикле булса, шуннан да әзерләргә мөмкин.

■ Крем ясау өчен йомыркаларның агын сарысыннан аерабыз. Агын – аерым, сарысын аерым савытта күпертәбез. Сарысын күперткәндә шикәр онын кушабыз. Мөһим искәрмә: крем термик эшкәртү узмаганлыктан, йомыркаларны башта яхшылап юарга кирәк.

■ Желатинны кайнаган салкын суга салып җебетергә куябыз.

■ Маскарпоне сырын берәр савытка бушатып, кашык белән генә туглыйбыз, аннары күпертелгән йомырка сарысына өлешләп кенә кушабыз. Төерләре калмаслык итеп сак кына болгаткач, күпертелгән йомырка агын да өстибез.

■ Бүрткән желатинны микродулкынлы мичтә яки кайнар сулы савытка куеп, эретеп алабыз да әкренләп кенә кремга кушабыз.

■ Әзер кремны 20 минутка суыткычка тыгып торабыз.

■ Тирамисуны төрлечә җыярга була. Дүрткырлы пыяла стаканнарда яки тирән касәләрдә дә матур булачак. Без исә артык зур булмаган тирән пыяла савыт (форма) кулландык.

■ Форма төбенә бер-ике кашык крем ягып, бер кат итеп печеньеларны тезеп чыгабыз. Тезгән вакытта һәр печеньены аскы ягы белән кофега манып алабыз. Икенче кат итеп тагын крем ягыла. Өченче кат – кофега манылган печеньедан гыйбарәт. Иң өскә крем ягып, өстен тигезлибез, какао яки вак угычтан уылган шоколад сибәбез. Десертның өстен кремнан чәчәкләр ясап та бизәргә була.

■ Табынга куйганчы тирамисуны берничә сәгатькә суыткычка куеп торсаң, аның тәме тагын да яхшыра.

Ашларыгыз тәмле булсын, кадерле укучыларыбыз!






















Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.

Өйнең яме — гөлләрдә


Катарантус

Катарантус. Сортына карап, алсу, ак, кызыл төсле чәчәкләр атучы, флокска охшаган бик матур гөл ул. Артык талымлы түгел, ләкин дымга таләпчән. Һаваның корылыгын авыр кичерә, дымлылык 60 проценттан кимрәк булганда, ясалма дымландырыруга мохтаҗ. Суны даими сибеп торуны сорый. Дым җитмәсә, яфракларын бөгәрләп, үзе үк хәбәр сала. Шулай да туфрагы артык юеш тә булырга тиеш түгел, югыйсә чирләргә мөмкин. Кояш туры карамаган тәрәзә төпләрендә – көнчыгыш яки көнбатыш тарафларда яхшырак үсә. Көньяк тәрәзә төбендә үстерергә уйласагыз, көндез күләгәләргә туры киләчәк. Бүлмәдә җылылык 20 градустан 25 градуска кадәр булганны ярата. Кышын исә температура 15 градус булган урын кулай. Җәй көне катарантусны савыты белән верандага, балконга яки бакчага да чыгарып утыртырга була. Үтәли җил йөри торган һәм көндез кояш кыздыра торган урын гына булмасын ул. Даими чәчәк ата торган гөл булганлыктан, әледән-әле тукландырып торуга мохтаҗ. Әгәр дә гөлегезне күпьеллык итеп үстерергә уйласагыз, ашламаларны ике атнага бер кулланырга кирәк. Бер генә ел үстереп, киләсе сезонда яшь тармактан тамырландырырасы булсагыз, атна саен да ашларга мөмкин. Катарантусны ел саен күчерәләр. Ул тиз үсә, чүлмәк сайлаганда моңа игътибар итегез. Савыт төбенә калын итеп дренаж салып калдырырга онытмагыз. Гөлегезне күпьеллык итеп үстерсәгез, язга чыккач аны кыскартып кисеп, формалаштырырга кирәк булачак. Иртә язда башкарылган бу эш гөлне яшәртеп җибәрә. Формасын югалтмасын дисәгез, озынаеп үсеп киткән тармакларын җәй дәвамында да өзгәләп торырга кирәк. Тагын бер мөһим мәгълүмат: катарантус агулы гөл, сабый балаларыгыз, эт-мәчеләрегезнең буе җитмәслек булсын.

Цикламен – эфемероид үсемлекләрдән. Ягъни салкын вакытта чәчәк ата. Бүлмәдә үстергәндә озын сабаклардагы чәчәк бөреләре кыш башында ук ачыла. Аны бүлмә гөле буларак үстерүе кыен түгел, ләкин бер генә ягы бар – салкынча һаваны ярата. Хәер, селекционерлар тарафыннан хәзер инде җылыга чыдам сортлары да чыгарылган. Җәен температура 20–25 градус, кышын 10–14 градус җылы булса кулай. Һаваның һәм туфракның дымлылыгына сизгер, чәчәк аткан чорда туфрагы гел дымлы торырга тиеш. Чәчәк бөреләре күренә башлагач, өстенә су бөркегәнне ярата. Май-июнь аенда цикламенның тынлык чоры башлана, яфраклары кибеп коела. Бу вакытта су сибүне киметә барып, туфрагы тәмам кипкәч кенә сугаралар. Гөлне исә савыты белән караңгырак урынга күчерәләр яки каплап ук куялар. Августта яки сентябрь башында кабаттан якты урынга чыгаралар. Яңа яфраклары күренә башлагач, айга бер тапкыр комплекслы ашламалар белән тукландырырга кирәк. Чәчәк бөреләре формалашканда ашламаның чәчәкле гөлләр өчен булганын кулланалар. Яңа туфракка күчерүне дә гөл уянган чорда – августта башкаралар. Киңрәк савытта яхшырак үсә. Туфрак белән күмдергәндә бүлбесенең яртысы яки өчтән бер өлеше өскә чыгып калырга тиеш, шулай булганда гына чәчәкне күп итеп ата ул.


Цикламен


Маранта

Марантаны чуар төстәге яфраклары өчен яратып үстерәләр. Аның төрләре бик күп: кайберләренең яфраклары овал формасында, кайберләре очлы. Яшел яфраклары өстендә төрле формадагы бизәкләре була. Сортына карап, алар ике, өч төсле дә була ала. Өйдә үстергәндә маранта чәчәк атмый диярлек. Аткан очракта да, вак кына ак чәчәкләре купшылыгы белән аерылмый. Марантаны әле гыйбадәт гөле дип тә атыйлар. Тәрбия шартларын ошатмаса, ул яфракларын өскә таба күтәреп, «торып баса». Уңай шартларда яфраклары җәелә. Аның тамырларыннан диетик ризык өчен он әзерлиләр, ә үзе ул өйдәге начар энергияне чистартучы, гаиләдәге татулыкны саклаучы гөл булып санала. Яктылыкка һәм дымга мохтаҗ. Кояш туры карамаган якты тәрәзә төпләрендә яхшы үсә. Бүлмә почмагына куйсагыз, кимендә 16 сәгать ясалма яктыртырга кирәк булачак. Җәйге һәм язгы чорда су еш һәм мулрак сибелә, кышын исә су сибүне киметәләр. Һаваның дымлылыгына сизгер. Һава коры булса, гөлнең яфракларына су бөркергә кирәк, югыйсә аларның читләре корып көя башлый. Декоративлыгын югалтмасын өчен, марантаны ел дәвамында һәр ике атна саен тукландыралар. Ике елга бер тапкыр яз башында туфрагын алыштырып, икенче савытка күчереп утыртырга кирәк. Күчергәндә чүлмәкнең элеккегесеннән чак кына зуррак булганын алыгыз. Әчелеге ким булган туфракларда һәм саерак савытларда әйбәтрәк үсә. Марантаны гадәттә тамырдан бүлеп үрчетәләр. Май-июнь аенда ике-өч яфраклы яшь тармакларын тамырландырырга да мөмкин.

Фото: www.pixabay.com


Башка гөлләр үстерү турында да укыгыз.

тест: сез үпкәчелме?

Әлеге тест сезнең чынлап та үпкәчелме, түгелме икәнлеген ачыкларга ярдәм итәр. Син үпкәчел, дип, танышларыгыз бәлки юкка гына әйтәдер. Сорауларга «әйе» яки «юк» дип җавап бирегез. Икеләнгән очраклар өчен – «белмим, төрлечә була».

1. Сезнең кәефне кыруы җиңелме?
2. Үпкәләүне озак саклыйсызмы?
3. Вак-төяк өчен озак борчылып йөрисезме (мәсәлән, кемдер сүзе белән төрттереп куйса, яратмыйчарак караса, киемегез буялса)?
4. Беркем белән сөйләшәсе килмәгән вакыт озак дәвам итәме?
5. Башкаларның сөйләшкәне, ят тавышлар игътибарыгызны тиз аламы?
6. Үз хисләрегезне, борчуларыгызны, эшләгән гамәлләрегезне озаклап анализлап йөрисезме?
7. Бер минутлык кәефкә ияреп эшләнгән гамәлләрегез бармы?
8. Куркыныч төшләр керәме сезгә?
9. Кай җирегез беләндер кемнәндер ким дигән уй сезне еш борчыймы?
10. Кәефегез еш үзгәрәме?
11. Кем беләндер бәхәсләшкәндә тавышыгызның тембры үзгәреп, үзегезгә ят булган югары яки түбән тоннарда сөйләшкән чакларыгыз буламы?
12. Сезне чыгырдан чыгаруы җиңелме?
13. Кырылган кәефегезне хәтта тәмле ризык та күтәрә алмыймы?
14. Сезне аңламасалар, чыгырыгыздан еш чыгасызмы?

«Әйе» дигән һәр җавап өчен 0 балл куегыз, «белмим, төрлечә була» өчен – 1 балл, «юк» дип җавап биргән һәр җавапка 2 балл куегыз.

23 баллдан – 28 баллга кадәр. Сезне үпкәчел кеше дип әйтеп булмый. Рухи халәтегез тотрыклы һәм ул вазгыятькә карап кына сирәк үзгәрә. Кемдер сезне «тиресе калын» кеше дип саныйдыр. Сездән кайчак көнләшәләр, сезне сөйлиләрдер – моңа игътибар итмәгез.

17 баллдан – 22 баллга кадәр. Сез үпкәчелрәк кеше. Холкыгыздагы бу сыйфат тормышыгызның бераз ямен ала. Сез тиз кызып китәргә, үзегезне үпкәләтүчегә тупас итеп җавап бирергә мөмкин. Шул сәбәпле өйдә һәм эштә еш кына низаглар да чыгып тора. «Үпкәләгән ишәк су ташырга яхшы» дигән халык мәкален онытмагыз.

0 баллдан 1–6 баллга кадәр. Сез үпкәчел, үч саклый торган кеше. Кәефегез тиз үзгәрә, башкаларның сезгә кырын каравын бик авыр кичерәсез. Бу – холкыгыздагы шактый зур кимчелек. Тиз арада үз-үзегезне тәрбияләү белән шөгыльләнә башларга вакыт. Балларыгыз никадәр кимрәк булса, моңа шуның кадәр тизрәк керешегез.

йолдызнамә июль

Кучкар. Ыгы-зыгылы вакыт. Эш белән өй мәшәкатьләре арасында бүленергә туры килер. Мөгаен, беренчесе алгы планга чыгар, чөнки яңа идеяләр туар, яңа мөмкинлекләр ачылыр. Зур акчалар белән эш итәргә туры килүе бар.

Үгезбозау. Тирә-юнегездәгеләрне тырышлык һәм максатчанлык белән шаккаттырачаксыз. Каршыгыздагы киртәләрне җиңәр өчен көтелмәгән мөмкинлек килеп чыгар. Ай уңышлы узар.

Игезәкләр. Үткәннәр үткәндә кала, алда исә яңа перспективалар, яңа эшләр көтелә. Сезнең бурыч – үзегезгә файдалысын аерып алу. Эшчәнлегегез бераз сүлпәнләнсә дә, финанс ягын яхшырту өчен кулай чор.

Кысла. Язмыш уңыш байрагын сезгә тапшырырга ниятли. Яшәү көчегез арта, күп нәрсәләргә җиңел генә ирешә аласыз. Ниндидер бер очрашу тормышыгызга яңалык алып килергә мөмкин. Яңа эшкә керешү отышлы булачак.

Арыслан. Ай башында көтелмәгән проблемаларны хәл итәргә туры килүе ихтимал. Барысын да ныклап уйларга, дөрес юнәлешне сайларга кирәк булыр. Көчегезнең кимүен тоярсыз. Бу – вакытлыча, ай ахырына яңа сулышыгыз ачылыр.

Сөмбелә. Уңыш тормышка никадәр тизрәк яраклаша алуыгызга бәйле. Төп игътибарны эшлекле танышлар даирәсен киңәйтүгә багышласагыз, отарсыз. Перспективалы чор. Һөнәри сәләтегез ачылып, үзегезгә лаек бәя алырсыз.

Бизмән. Максатларыгызга ирешү өчен язмыш сезгә әллә никадәр мөмкинлек бирә. Ай уңышлы һәм матур вакыйгаларга бай булыр. Рухи күтәрелеш көтелә. Уртак проектларга алынырсыз, тик партнерыгызга юл куярга кирәк булыр.

Чаян. Һөнәри күтәрелеш һәм уңышка ирешү чоры. Элек башлап та, ахырына җиткермәгән эшләрне төгәлләрсез. Финанс ягын яхшырту өчен әйбәт форсат чыгар. Офыкларыгыз киңәеп, яңа идеяләр белән рухланырсыз.

Укчы. Җәйнең икенче ае оптимистик рухта башланачак. Эштән бераз арынып, хыялларыгызга бирелеп алырсыз. Һөнәри өлкәне чак кына этәреп, шәхси эшләрегез белән шөгыльләнергә туры килер.

Кәҗәмөгез. Күңелсезләнергә туры килмәс. Күңелдә йөрткән максатка ирешү өчен, «үгезне мөгезеннән алырсыз». Хыялларны чын итәр чор – уңыш сезнең якта. Үзегезгә файда китерердәй яңа танышлар барлыкка килер.

Сукояр. Көчегезнең сүлпәнләнгән мәле. Киләчәккә озак вакытлы планнар кору, хезмәттәшлек урнаштыру, проектлар башлау өчен яхшы вакыт. Бу чорда керешкән эшләр уңышлы булачак, нәтиҗәсе сезгә озак вакыт файда китерәчәк.

Балыклар. Сез иҗади дулкында. Нәрсәгә тотынсагыз да, үзгә бер җиңеллек белән башкарачаксыз. Хәтта иң яратмаган эшләрегез дә күңелегезгә рәхәтлек бирер. Позитив ай, бу айда танышкан кешеләрегез дусларыгызга әверелер.

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА, Лилия ГӘРӘЕВА, Алсу ШАКИРОВА әзерләде.





НАДИЯНЕҢ САБЫРЛЫК КАСӘСЕ

Рәссам, керамика остасы Надия Миңнеәхмәтова Чаллы шәһәрендә туган. «Кечкенә чагымда укытучылар булган дәү әнием Сәкинә һәм дәү әтием Нурулла янында, Кукмарада үстем. Аннары әнием Рузия белән Түбән Камага киттек. Үз мәдәниятебезне, татар орнаментларыбызны бик яратам», – ди ул. Надия ханым Кунгур сынлы сәнгать-сәнәгать лицеен, Санкт-Петербургтагы А. Л. Штиглиц исемендәге сынлы сәнгать-сәнәгать дәүләт академиясен уңышлы тәмамлаган. Ленинград өлкәсендәге Стрельна бистәсендә яшәп иҗат итә. Ул – өч кечкенә кыз бала әнисе дә! Иҗат темалары шундый: үзле балчыктан әвәләнгән вазалар, кошлар, боланнар, чәчәкләр, төрледән-төрле үсемлекләр... «Моннан кала, зәвыклы картиналарда, катлаулы бизәкле келәмнәрдә яисә матур чигешләрдә яшеренгән уй-фикерләргә, шифрланган тәҗрибәләргә яисә төрле хиссиятле хезмәтләргә охшаш булган, диварга элеп куярлык интерьер әсәрләрен дә ясыйм, – ди рәссам.

Оста корама, сырган юрган темасына игътибарлы.

– Сырган юрган ул – әйтерсең лә хатын-кыз тормышының асылын күрсәтеп бирә. Бер зурлыктагы, әмма төрле төстәге тукыма кисәкләре – ул көннәр. Алар ак та, алтын да, соры да, җете дә, вак-төяк мәшәкатьләр белән тулган чуар да булалар, һәм барысы бергә тупланып, бик матур бизәк хасил итәләр, – ди Надия ханым. – Кайчак шул хакта да уйланам: иҗат ир-атныкы яисә хатын-кызныкы дигән төрләргә бүленә аламы? Тарих буенча, хатын-кыз һәрчак өйдә, балалары янында булган, тормыш тәгәрмәчен туктатмыйча әйләндерергә булышучы көндәлек эшләрен башкарган. Шуңа күрә хатын-кыз иҗатының нигезен уникальлек түгел, ә кабатлау тәшкил итә. Ритмга, биюгә, җырга әйләнүче кабатлау. Гади, төгәл, җете образлар һәм аларның кабатлануы – ул орнамент. Хатын-кыз сәнгате еш кына транска ия. Сакраль образлар һәм аларның кабатланулары, ритмнар, символларга ышаныч – болар барысы да чигүләрдә, төрле бизәмнәрдә тәкъдим ителгән. Һәр чигешле эшләмә яисә тукылган келәм яки рәсемле бизәк – ул хатын-кыз көндәлеге, аның үзенчәлекле ритмы, язу рәвеше, алар традиция буенча эшләнсә дә, барысында да аларның үз күзаллавы. Бу «текст»ны бары тик йөрәк аша укып була.

«Төнге күктәге йолдызлар» хезмәте дә – күк йөзе илаһилыгын искә төшерү... Гомумән, бу керамика остасы гаҗәеп фантазиягә ия! «Йолдызлар минем өчен күк җисемнәре генә түгел, алар – инсаннарның хыяллары, максатка ирешүләре, мәхәббәт символлары... Һәр кешенең дә алга таба өндәүче, караңгы, шомлы дәверләрдә дә аңа юл күрсәтүче йолдызы була! Ул аңа һәрчак өмет өсти, – дип аңлатты әңгәмәдәшем. – Иҗатымда һәрчак шундый йолдызлар минем. Менә «Сабырлык касәсе» дип аталган тагын бер хезмәтем... Кайчак сабыр касәсе тулды, диләр. Һәр көн – кечкенә касә, ә сабырлык – кешелек эшчәнлегенең бар өлкәләрендә дә кирәкле асыл сыйфат. Шулай ук ана булу да – космик берәмлеккә якынлашкан җитди сыйфат. Һәр көн саен аш-су әзерлисең, балаларны укырга озатасың, каршы аласың, гаиләңне сыйлыйсың, рәссам иреңне мактыйсың, әле керамика белән шөгыльләнергә, иҗатка да вакыт калдырырга кирәк, ә инде көн узып та бара... Әлеге панно – үзем хакында». Надия Миңнеәхмәтованың иҗади идеяләре төрле. Әйтик, менә бу, күннәребездә кабатланучы милли аппликацияләребез белән капланган керамик диванны Казансу ярына яисә башкаладагы берәр үзәк паркка урнаштырырга өмет итә ул. Чит илләрдә андый арт-объектлар бик күп. «Чит илләр... Ә сез анда яшәр идегезме?» дигән соравыма, җавап төгәл булды: «Чит илләр – төзек, әмма алар минем аңымда шулкадәр дә кызыксыз, сагыш тудыручы илләр булып истә кала. Кайсы дәүләттә генә булсам да, өченче көнгә үк инде, тамырларым кире тарта башлый. Мин үз Ватаныбызда гына яши алам. Мин – шушы җирнең агачы!»

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА











НАДИЯ МИҢНЕӘХМӘТОВА




«БӘКЕР» ШИФАХАНӘСЕНӘ ИКЕ КЕШЕЛЕК ЮЛЛАМА

«ТАТМЕДИА» ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫНА ЯЗЫЛГАН ӨЧЕН ТЕЛЕВИЗОР, ЭЛЕКТР ИТТАРТКЫЧ, РОБОТ-ПЫЛЕСОС ҺӘМ БАШКА БҮЛӘКЛӘР ОТ




1 ЯЗЫЛ

2022 елның 15 августына кадәр «ТАТМЕДИА» АҖнең бер газета һәм бер журналына язылып (акциядә катнашучы басмалар белән tatmedia.ru сайтында танышып була)

2 ҖИБӘР

«Акция» билгесен куеп, язылу квитанцияләренең копиясен безгә җибәр (телефон номерыгызны язарга онытмагыз). Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 ОТ

телевизор, электр иттарткыч, робот-пылесос һәм башка бүләкләр от. Иң зур бүләк – «Бәкер» шифаханәсенә ике кешелек юллама.



Акциянең срогы 2022 елның 16 маеннан 2022 елның 20 сентябренә кадәр. Заявкалар 2022 елның 15 августына кадәр кабул ителә. Оештыручы: «ТАТМЕДИА» АҖ. Реклама 16+.
Товарлар рәсемдә тәкъдим ителгән белән тәңгәл килмәскә мөмкин.